**Казан федераль университеты**
**Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге**

**Казан муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе**

# Федераль дәүләт белем стандартлары кысаларында дәрестән тыш эшчәнлекне программалар белән тәэмин итү

**VI кисәк**

**(милли мәгариф)**

**Казан шәһәре**
**2020**

**Казан федераль университеты**
**Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге**

**Казан муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе**

# Федераль дәүләт белем стандартлары кысаларында дәрестән тыш эшчәнлекне программалар белән тәэмин итү

## VI кисәк

## (милли мәгариф)

**Казан шәһәре**
**2020**

УДК 372.8
ББК 74.26

**Казан муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсенең фәнни-методик советы карары белән басылды.**

**Фәнни җитәкчесе:**

**Җамалетдинова З.И.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты

**Рецензентлары:**

**Шәмсетдинова Р.Р.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты

**Кадирова Э.Х.,** Казан федераль университеты Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, филология фәннәре кандидаты

**Антонова Л.М**., Совет районы Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәгенең милли белем һәм тәрбия бүлеге мөдире

**Төзүчесе:**

**Зиннәтуллин Р.К.,** Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы

**Компьютерда биткә салучы:**

**Потанина М.А.,** Казан шәһәре мәгариф идарәсенең белем процессын ресурслар белән тәэмин итү бүлекчәсе методисты

**Бачуров В.А**., инженер - программист

**Федераль дәүләт белем стандартлары кысаларында дәрестән тыш эшчәнлекне программалар белән тәэмин итү (милли мәгариф). VI кисәк: методик җыентык. -** Казан, Казан шәһәре мәгариф идарәсе, 2020 – 116 бит.

Методик җыентыкта дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру өчен эш программалары бәян ителгән. Җыентык гомуми белем оешмаларында эшләүче укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары өчен тәкъдим ителә.

© Управление образования ИКМО г.Казани, 2020

# Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру

*Җамалетдинова Зәлфирә Исхак кызы, “Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты”өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты*

Дәрестән тыш эшчәнлек гомуми белем бирү программасы нигезендә укучыларны тәрбияләү, социальләштерү, кызыксынучанлыкларын арттыру, дәрестә үзләштергән белемне мәктәптән тыш урынлы кулланырга өйрәтү, универсаль уку гамәлләрен формалаштыру бурычларын хәл иткән эш төрләрен берләштерүче эшчәнлек буларак белем бирү процессының аерылгысыз өлеше булды.

Дәрес эшчәнлеге белән дәрестән тыш эшчәнлек бербөтен белем бирү процессын тәшкил итәләр. Ул федераль дәүләт белем стандарты таләпләрен тормышка ашыруга тулаем юнәлтелгән.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең төп үзенчәлеге – укучыларга мөмкин кадәр киң ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен дәресләр төрлелеге булдыру, белем бирү оешмаларының дәрестән тыш эшчәнлекнең эчтәлеген максатчан мөстәкыйль планлаштыру. Иң мөһиме дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру укучыларга дәрестән тыш вакытны акыл белән файдалы итеп үткәрергә ярдәм итә.

Шулай ук дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру укучының интеллектуаль үсешен тәэмин итү, социаль яктан активлашу, иҗади, җаваплы, тормышта мөстәкыйль үз ихтыяҗларын канәгатьләндерә ала торган шәхес формалашуга тәрбияви даирә төзү мөмкинлеге бирә.

Дәрестән тыш эшчәнлекне планлаштырганда дәрестән аермалы икәнлеге, дәрестә алган белем, темаларның киңәйтелгәне, үсеш алганы күрсәтелергә тиеш. Хәзерге заманда укучыны төрле яклы эшчәнлеккә тарту белем бирү процессының төп бурычы булып тора.

Моңа дәрестән тыш эшчәнлекне биш юнәлештә планлаштыру ярдәм итә. Федераль дәүләт белем стандартында дәрестән тыш эшчәнлекнең **рухи-әхлакый, физик тәрбия һәм спорт, социаль, гомуминтеллектуаль, гомуммәдәни** юнәлешләре билгеләнгән. Һәр юнәлешнең үз бурычлары бар.

Рухи-әхлакый юнәлеш дөньяви һәм ил күләмендәге рухи кыйммәтләрне үзләштерү, укучыларны тормышта әхлак нормаларын дөрес мөстәкыйль сайлауга әзерләү, дөньяга гуманлы караш формалаштыру, гамәлдә милли кыйммәтләрне камилләштерү һәм тормышка ашыруны чагылдыра.

Менә бу күрсәткечләр дөрес итеп рухи әхлакый үсеш һәм тәрбия концепциясендә ныклы итеп ачылган. Дәрестән тыш эшчәнлекнең эчтәлеген концепциядә аерып күрсәтелгән милли, рухи кыйммәтләрне өйрәнерлек биремнәр сайлап планлаштыру уңай нәтиҗә бирә.

Физик тәрбия һәм спорт юнәлеше укучыларның физик һәм психик үсешен тәэмин итү өчен тулы шартлар булдыру, гигиена таләпләрен үтәү, сәламәт тормыш

алып барырга омтылу, чыныгу һәм физик күнегүләр белән шөгыльләнү теләге формалаштыруны күздә тота.

Социаль юнәлеш укучыларда хезмәт, уен, сәнгать эшчәнлеге ысулларын үзләштерү, иҗади хәрәкәтләнү, социаль активлыкларын үстерү, иҗади мөстәкыйльлеккә омтылыш булдыруга юнәлтелгән.

Гомуминтеллектуаль юнәлешнең эчтәлеген танып-белү эшчәнлегенең төрле гомуми ысулларын үзләштерү, укучыларның кызыксынучанлыкларын һәм активлыкларын үстерүне тәшкил итә.

Гомуммәдәни юнәлеш дөньяга уңай, сак, кайгыртучан караш, актив тормыш позициясен формалаштыру, лидерлык сыйфатлары, оештыру осталыгы булдыруга ориентлаша.

Дәрестән тыш эшчәнлекне планлаштырганда оештыру формалары да зур роль уйный. Оештыру формалары федераль дәүләт белем стандартында билгеләнгән.

Мәсәлән, урта звенода 5-9 нчы сыйныф укучылары өчен түбәндәге формалар уңышлы дип тәкъдим ителә: түгәрәк, клуб, студия, туган якны өйрәнү эшчәнлеге, фәнни оешмалар, фәнни-гамәли конференция, олимпиада, фәнни-эзләнү тикшеренү эшчәнлеге, җәмгыятькә файдалы хезмәт, сугышчан-патриотик тәрбия бирү эшчәнлеге һәм башкалар.

Тема, эчтәлек сайлаганда һичшиксез дәрестән тыш эшчәнлекнең юнәлеше һәм формасы төп ориентир булып тора.

Дәрестән тыш эшчәнлек метапредмет һәм шәхескә кагылышлы планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итәргә тиеш.

Метапредмет нәтиҗәләре унверсаль уку гамәлләре һәм предметара төшенчәләр формалашуны күздә тота. Башлангыч мәктәптә предметара нәтиҗәләр уку, текст, мәгълүмат белән эшне, урта звенода уку компетенциясе нигезләре, мәгълүмат белән эшли белү компетенциясе, проект эшчәнлеге тәҗрибәсе, ә инде өлкән сыйныфларда дәрестә алган белемнәрне танып-белү һәм иҗтимагый практикада куллану сәләте, укыту эшчәнлеген планлаштыруда һәм тормышка ашыруда мөстәкыйльлек, укытучылар һәм яшьтәшләр белән мәгариф хезмәттәшлеген оештыру, индивидуаль белем юлын булдыру сәләте, мәгариф, фәнни-тикшеренү, дизайн һәм иҗтимагый эшчәнлек күнекмәләрен формалаштыруны үз эченә ала.

Укучылар эшчәнлеген оештыруда планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүдә эшчәнлек төрләре зур роль уйный. Укучылар эшчәнлеген оештыруның 9 төре тәкъдим ителә: уен эшчәнлеге, танып-белү эшчәнлеге, проблемалы-кыйммәти аралашу, вакытны дөрес кулланып, укучыларның буш вакытын мавыктыргыч оештыру, әдәби иҗади эшчәнлек, социаль юнәлештәге (тормыштагы рольләргә керү), хезмәт эшчәнлеге, спорт-сәламәтләндерү, туган якны өйрәнү һәм туризм.

Эш төрләрен, биремнәр сайлаганда укучыларның төрле үсеш дәрәҗәсен күздә тотып сайлау кирәк. Биремнәрнең кайсы нәтиҗәгә ирешүне күздә тотуы да бик мөһим.

Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүнең өч дәрәҗәсе бар. Һәр дәрәҗәнең үз күрсәткечләре аерып күрсәтелгән.

1 нче дәрәҗә: укучы иҗтимагый тормышны белә һәм аңлый. Монда укучы белән укытучы арасында мөнәсәбәт барлыкка килә.

2 нче дәрәҗә: укучы иҗтимагый тормышны кадерли, саклый. Бу дәрәҗә укучының башка балалар белән мөнәсәбәткә керүен күрсәтә.

3 нче дәрәҗә: укучы ачык даирәдә башкалар белән мөстәкыйль рәвештә мөнәсәбәткә керә.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең планлаштылган нәтиҗәләргә ирешүдән тыш төп аермасы аның эффектлы булуы. Ул укучыда тәрбияви һәм социаль сыйфатлар – коммуникатив, әхлакый һәм гражданлык компетентлылыгы формалашу.

Бу сыйфатларның формалашуын контрольдә тоту күргәзмәләр, спектакльләр, концерт, ярышлар, турнир, конференцияләр, портфолиода тупланган күрсәткечләр, күзәтүләр һәм башка чаралар аша бара.

Төрле әңгәмә, проект яклау, гомуми нәтиҗә ясау, күзәтү битләре, диагностик карталар аша дәрестән тыш эшчәнлекне бәяләүне оештырырга мөмкин.

Ә инде планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне күрсәткән диагностиканы алып барганда өч юнәлештә алып бару уңышлы була. Алар – укучы шәхесе, укучылар коллективы, укытучының укучы үсешенә карата позициясе. Мондый диагностика дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның нәтиҗәлелеген тулаем күзаллау мөмкинлеге бирә.

Гомумән, белем бирү процессында укучының шәхес буларак үсешендә дәрестән тыш эшчәнлекнең әһәмияте гаять зур. Бу мөмкинлектән, һичшиксез, дөрес файдалану гына кирәк.

**Кулланылган әдәбият**

1. Башлангыч гомуми белемнең федераль дәүләт белем стандарты: текст үзгәртелде. һәм өстәргә. 2011 ел өчен. / Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы. Федерация. - М.: Мәгариф, 2011.

2. Башлангыч гомуми белем өчен якынча төп белем бирү программасы (гомуми белем бирү өчен федераль мәгариф-методик берләшмә карары белән расланган - 2015 елның 8 апрелендәге 1/15 карары) 297-299 б.

3. Д.В. Григорьев, П.В.Степанов. Мәктәп балаларының дәрестән тыш чаралары. Методик конструктор: укытучы өчен кулланма. М., 2010.

## Дәрестән тыш эшчәнлекне гамәлгә ашыру

*Зиннәтуллин Раиф Кәримулла улы, Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты,*
*Татарстан Республикасының атказанган укытучысы,*
*Кол Гали исемендәге халыкара бүләк иясе*

Дәрестән тыш эшчәнлек эш программалары нигезендә тормышка ашырыла. Ул гомуми белем бирү оешмасының төп белем бирү программасы, башка укыту программалары белән беррәттән, мәҗбүри аерылгыз өлеше булып тора. Дәрестән тыш эшчәнлекнең эш программалары,тиешле үрнәк төп белем бирү программаларын исәпкә алып, гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартлары таләпләре нигезендә белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә эшләнә.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең эш программалары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- дәрестән тыш эшчәнлекнең планлаштырылган нәтиҗәләре;
- дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру формаларын һәм төрләрен үз эченә алган эчтәлек;
- тематик планлаштыру.

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлектә катнашуы мәҗбүри санала.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларында, гомуми белем дәрәҗәсенә карап, дәрестән тыш эшчәнлекнең мөмкин булган сәгатьләр саны түбәндәгечә билгеләнде:

- башлангыч гомуми белем дәрәҗәсендә белем бирүнең дүрт елы өчен 1350 сәгатькә кадәр;
- төп гомуми белем дәрәҗәсендә белем бирүнең биш елы өчен 1750 сәгатькә кадәр;
- урта гомуми белем дәрәҗәсендә белем бирүнең ике елы өчен 700 сәгатькә кадәр.

Дәрестән тыш эшчәнлек сәгатьләре саны белем бирү программасы белән билгеләнә, ул гаилә ихтыяҗларын, укучыларның мәнфәгатьләрен һәм гомуми белем бирү оешмасының мөмкинлекләрен исәпкә алып, мәгариф оешмасы тарафыннан раслана.

Дәрестән тыш эшчәнлек программалары модульле принцип буенча төзелергә һәм челтәр формасын кулланып, электрон укытылырга, шулай ук дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Дәрестән тыш эшчәнлек белем бирү оешмасының укыту планына кертелми, аның өчен бирелгән сәгатьләр саны аудитор йөкләнеш сәгатьләрендә билгеләнми.

Гомуми белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыру кысаларында белем бирү процессын оештыру рәвешләрен, укыту һәм дәрестән тыш эшчәнлекне чиратлаштыруны белем бирү оешмасы билгели.

Дәрестән тыш эшчәнлек дәресләренең дәвамлылыгы һәм атналык сәгатьләр саны гомуми белем оешмасы боерыгы белән билгеләнә.

Дәрестән тыш эшчәнлекне гамәлгә ашыруда,челтәр формасыннан файдаланып белем бирә торган оешмалар, фәнни оешмалар, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәдәният, физик культура, спорт оешмалары һәм ресурсларга ия булган башка оешмалар катнаша ала.

Белем бирү программаларын гамәлгә ашыруның челтәр рәвеше мәгариф оешмалары арасында төзелгән шартнамә рәвешендә тормышка ашырыла.

Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларының бер өлешен, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" Федераль законның (№273-ФЗ, 29.12.2012 ел) 15 нче статьясында күрсәтелгәнчә, өстәмә белем бирү оешмасы базасында да оештырырга мөмкин. "Россия Федерациясендә мәгариф турында" гы Законында өстәмә белем бирү оешмалары тарафыннан төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру каралмаган. Шул ук вакытта дәрестән тыш эшчәнлекне оештырганда өстәмә белем бирү оешмалары ресурсларыннан (биналар, җиһазлар, шулай ук кадрлар) файдаланырга. аерым дәресләр (занятие), мастер-класслар, практикумнар һ.б. үткәрергә мөмкин.

Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның нәтиҗәле формасы булып проект эшчәнлеге (уку проекты) санала.

Проект, бер яки берничә өйрәнелә торган уку предметы, курслар кысаларында, сайланган тема буенча мөстәкыйль рәвештә, эшчәнлекнең теләсә кайсы сайланган юнәлешендә (рухи-әхлакый, физик тәрбия һәм спорт, социаль, гомуминтеллектуаль, гомуммәдәни) үткәрелә. Әлбәттә, бу эш педагогик хезмәткәр җитәкчелегендә башкарыла. Проект җитәкчесе (челтәр рәвеше кысаларында) итеп өстәмә белем бирү, һөнәри урта һәм югары белем бирү оешмалары педагоглары ( шул исәптән студентлар), мәдәният, спорт оешмалары, предприятие белгечләре җәлеп ителергә мөмкин. Аларның катнашу тәртибе үзара челтәрле хезмәттәшлек турындагы шартнамә белән билгеләнә.

Укучылар тарафыннан проект төп белем бирү программасына бирелгән уку вакыты кысаларында башкарыла һәм төгәлләнгән уку-тикшеренү эше яисә объект рәвешендә (мәгълүмат, иҗади, социаль, инновацион, констукторлык, инженерлык һ.б.) тапшырыла.

Проектны үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләрне чагылдырырга тиеш:

- коммуникатив, уку-тикшеренү эшчәнлеге күнекмәләре, критик фикерләүнең нисбәтлелеге;
- инновация, аналитик, иҗади, интеллектуаль эшчәнлеккә сәләтлелек;
- проект эшчәнлеге күнекмәләре, шулай ук төрле бурычларны хәл итәр өчен бер яки берничә уку предметы яки предметлы өлкәләрдән алынган белемнәрне һәм гамәлләр ысулларын мөстәкыйль рәвештә куллана алуы;
- тикшеренү гипотезасын кую һәм формалаштыру, эшне планлаштыру, кирәкле мәгълүматны сайлап алу һәм интерпретацияләү, җыелган мәгълүматлар нигезендә тикшерү нәтиҗәләрен структуралаштыру, нәтиҗәләрне презентацияләү сәләте.

Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләре федераль дәүләт белем стандартлары таләпләре нигезендә төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәләренең бер өлеше булып тора.

Эш программаларында дәрестән тыш эшчәнлекнең планлаштырылган нәтиҗәләре төгәлләштерелә һәм алар төп гомуми белем бирү программасын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләренә туры килергә тиеш.

Гомуми белем бирү оешмасы үзе билгеләгән тәртиптә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларда, шул исәптән өстәмә белем бирү оешмаларында белем алучыларның белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләрен исәпкә алырга мөмкин.

Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы өстәмә белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләрен, дәрестән тыш эшчәнлекнең эш программаларын үзләштерү нәтиҗәләре буларак, исәпкә алу тәртибен мөстәкыйль билгели һәм локаль акт белән раслый.

Шулай итеп, дәрестән тыш эшчәнлек бик күп мөһим бурычларны хәл итәргә:

- укучыларның уку йөкләнешен (нагрузка) оптимальләштерергә;
- баланың үсеше өчен шартларны яхшыртырга;
- укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алырга мөмкинлек бирә.

Дөрес оештырылган дәрестән тыш эшчәнлек системасы һәркемнең танып белү ихтыяҗларын һәм сәләтен максималь дәрәҗәдә үстерергә яки формалаштырырга,

ирекле шәхес тәрбияләргә мөмкинлек бирә. Баланы тәрбияләү эшчәнлеге теләсә кайсы вакытта башкарыла. Дәрестән тыш эшчәнлек алып барганда, баланың шәхесен индивидуаль сәләте нигезендә үстерү өчен шартлар тудырыла, шәхеснең танып белү активлыгы, шәхеснең әхлакый сыйфатлары, коммуникатив күнекмәләр формалаша, баланы, җәмгыятьнең интеллектуаль һәм гармонияле үсеш алган әгъзасы буларак, дөньяда адаптацияләү өчен нигез салына.

Дәрестән тыш эшчәнлектә балалар һәм педагогларның эмоциональ яктан үзенчәлекле иҗади мохите тудырыла.

**Кулланылган әдәбият**

1. Федеральный Закон от 29.12.2012 № 273-ФЗ (в действующей редакции) “Об образовании в Российской Федерации”.

2. Федеральный государственный образовательный стандарт начального общего образования (Приказ РФ от 6 октября 2009 г. № 373).

3. Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования (Приказ РФ от 17 декабря 2010 г. № 1897).

4. Федеральный государственный образовательный стандарт среднего общего образования (Приказ РФ от 17 мая 2012 г. № 413 ).

5. Примерная основная образовательная программа начального общего образования (решение федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол от 8 апреля 2015 г.№1/15).

6. Примерная основная образовательная программа основного общего образования (решение федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол от 8.04.2015 №1/15 (в редакции протокола №1/20 от 04.02.2020).

7. Примерная основная образовательная программа среднего общего образования (решение федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол от 12 мая 2016 г.№2/16).

8. Письмо Департамента государственной политики в сфере воспитания детей и молодежи Минобрнауки России от 18.08.2017 N 09-1672 «Методические рекомендации по уточнению понятия и содержания внеурочной деятельности в рамках реализации основных общеобразовательных программ, в том числе в части проектной деятельности».

9. Д.В. Григорьев, П.В.Степанов. Мәктәп балаларының дәрестән тыш чаралары. Методик конструктор: укытучы өчен кулланма. М., 2010.

## Бердәмлектә көч!
## (Дәрестән тыш эшчәнлекнең бер формасы буларак түгәрәк эше)
## (башлангыч сыйныф укучылары өчен)

*Газизова Алсу Наил кызы, Муктат Флера Ислам кызы,*
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 62 нче урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары*

Укучылар һәм ата-аналар белән бердәм эшчәнлекне оештыру уку-укыту процессының төп юнәлешләреннән берсе булып тора. Гаилә белән тату хезмәттәшлек алып бару – бүгенге көннең бик мөһим ихтыяҗы. Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Көндәшлеккә сәләтле, заман шартларына яраклашкан, рухи һәм физик яктан камил булган иҗади шәхес тәрбияләү, укучыларга мөстәкыйльлек һәм иҗади активлык күрсәтү өчен дә зур мөмкинлекләр тудыра. Күп очракта нәкъ дәрестән тыш эшчәнлектә укучылар үзләрен ныграк таныталар,

Белем бирү барышын, шәхеснең үсешен һәм аның тәрбияви якларын исәптә тотарга кирәк. Шуңа күрә дә дәрестән тыш эшчәнлек уку процессы белән үрелеп тә бара.

Соңгы елларда безнең мәктәптә башлангыч сыйныф укучыларының рус төркемнәрендә “Казаным – гомер бишегем” дип аталган фәнни-тикшеренү берләшмәсе эшләп килә. Төп акцент укучыларда гражданлык хисе тәрбияләүгә юнәлдерелә. Башлангыч сыйныф укучылары беренчел тикшеренү күнекмәләре алалар. Кешегә, үзләренә бәя бирү, тирә-як мохитны күзәтә алу, үзгәрешләрне сиземләү укучыларда кирәкле алшартларны үстерергә ярдәм итә.

Түгәрәктә балаларга гадәти булган күренешләрне, предметларны, әкиятләрне һәм шигырьләрне яңача бәяләргә тәкъдим ителә. Эш тәртибе җиңелдән катлаулыга үстерелеп, этаплап алып барыла.

Эшнең беренче этабы укучыларның Г. Тукай, А. Алиш һәм М. Җәлил музейларына сәяхәтләре белән башланып китә. Шулай ук язучыларның әсәрләрен һәм иҗат юлларын өйрәнү, шагыйрьләр Ш. Галеев һәм Р. Миңнуллин әсәрләре белән танышу да түгәрәк эшендә карала.

Эшнең икенче этабында укучылар үзләренә охшаган әсәрләрнең эчтәлекләрен сөйлиләр. Саф татар телендә шигырьләрен яттан укыйлар һәм әсәрләргә иллюстрация ясыйлар.

Ә инде эшнең өченче этабында башка типтагы бирем тәкъдим ителә – табарга, эзләргә һәм чагыштырырга. Укучылар әлеге әдипләрнең әсәрләрен рус әдәбияты язучылары белән чагыштырып, алардагы аермаларны, охшашлыкларны күрсәтергә тиеш булалар.

Кыска гына вакыт эчендә укучылар зур күләмле эш башкарып чыгалар. Әлеге эшнең нәтиҗәләре “Сабантуй” газетасы һәм һәм “Сабыйга” журналында басылып чыга.

Дәрестән тыш эш чаралары шәхес тәрбияләүдә зур роль уйный. Ул укыту процессын тулыландыра, дәвамчанлылыкны саклый. Коммуникатив, төрле милләт мәдәнияты белән якыннан таныш аңлы шәхес тәрбияли.

Яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләгәндә укучылар үзләренә тиешле мәгълүматны бик тиз алалар. Тикшеренү-тикшерү эшенең төп фәнни нигезләренә төшенәләр. Үзара матур итеп аралашырга, кылган гамәлләре өчен җавап бирергә дә өйрәнәләр.

Тирә-як мохиткә сакчыл караш һәм җаваплылык хисе дә тәрбияләнә. Шуның нәтиҗәсендә алар бу дөньяга да яңача карый һәм тагын да кызыксыныбрак күзәтә башлыйлар.

Дәрестән тыш эшчәнлек ата-аналар һәм сыйныф җитәкчеләре белән тыгыз элемтәдә алып барыла. Шуны да истә тотарга кирәк: хәзерге яшәеш, социаль-икътисади киеренкелек шартларында укучыларда төрле милләт халыкларының традицияләренә мәхәббәт тәрбияләү, саклап калу төп бурычларның берсе булып тора.

Түгәрәк эшебезнең иң төп этабында укучылар күп кенә мөһим сорауларга җавап эзләп табарга тиешләр. Мисал өчен: киләчәк буын кешесе түбәтәй, калфак, такыя, киез итек, читек һәм башкаларның нәрсә икәнен белерме?

Дәрес (чара) барышында бирелгән сорау: “Нәрсә ул түбәтәй?” – күп кенә укучыларны аптырашта калдыра. Түбәтәй нинди була? Калфакны, кафтанны кем киеп йөргән? Башлык нәрсәдән тегелгән? Һәм башка шундый сораулар түгәрәк эшендә карала. Укучылар үз чиратында куелган сорауларга җавап та эзли башлыйлар. Бу эшчәнлектә укучыларның ата-аналары да актив катнашалар. Күп кенә сорауларга җавапны бары тик мәктәптә, түгәрәк эшләрендә генә таба алырга мөмкин икәнлеге ачыклана.

Кыска гына вакыт эчендә укучылар тарафыннан зур күләмле эш башкарыла, күп кенә сорауларга җаваплар да табыла. Түбәтәй, такыя, камчат бүрек, кәләпүш, башлык һәм калфак кебек милли баш киемнәренең тарихы турында мәгълүмат алына.

Татарстан Республикасының дәүләт музеена барып кайту да укучылар өчен ярдәм һәм эмоциональ күтәрелеш була.

Укучыларны түбәтәйләрнең 100 ләп булуы бик тә хисләндерә. 100 дән артык түбәтәй милли музейның горурлыгы булып тора һәм анда саклана.

Шулай ук музейда укучылар хатын-кыз өчен аерым һәм ир-ат өчен башка түбәтәйләр бар икәнен күрәләр. Үзбәк, казах, таҗик һәм башка милләт кешеләрендә дә бу баш киеменең бик тә таралган булуы ачыклана. Алынган мәгълүмат укучыларны түбәндәге сорауларга җавап эзләргә этәрә: нинди түбәтәйләр була? Ир-ат һәм хатын-кыз татар кешеләренә хас түбәтәйдән кала тагын нинди баш киеме киеп йөргәннәр? “Түбәтәй” сүзе бөтен җирдә дә бер үк мәгънәдәме?

Укучыларның иҗади эшләре реферат, фотографияләр, проектлар һәм презентацияләр формасында эшләнелә.

Эшнең киләсе этабында укучылар үзләренең башкарган эшләрен бергә туплап, төрле кызыклы ачышларны, күзәтүләрне барлап, схемалар төзеп проект эшен яклыйлар.

Этаплап уздырылган эшләрдән соң “Түбәтәй нәрсә ул?”- дигән сорауга укучылар төгәл һәм дөрес җавап бирә алачак. “Киләчәк буын кешесе түбәтәйнең нәрсә икәнен онытмасмы?” – дигән сорауга да, инанып, “Юк, онытмас,”- дип әйтә алабыз.

Түгәрәк эше уку-укыту планына нигезләнеп төзелә. Әлеге түгәрәк планы 10-12 яшьлек (рус төркеменә йөрүче) балалар өчен каралган. Программа бер елга исәпләнеп языла. Төркемнәрдә 15 баладан да күп булмаган укучылар шөгыльләнә. Түгәрәк эше

атнага бер тапкыр, 1 сәг. 30 мин. үткәрелә (индивидуаль эш төрләре дә була). Шулай ук түгәрәктә төрле эш формаларын кулланырга мөмкин: практик, лекция, әңгәмә, экскурсия, сәяхәт, ачык дәрес һ.б.

Тематик планның эчтәлеге:

1. Кереш дәрес. (Балаларны яңа уку елы планы белән таныштыру, инструктаж үткәрү).
2. Бу минем Казаным. (Казан шәһәренең үткәне һәм киләчәге, башка шәһәрләрдән аермалы яклары, шәһәрнең символлары белән танышу).
3. Бөек Болгар дәүләте. (Бөек Болгар дәүләте турында мәгълүмат алу, фильмнар карау).
4. Алтын Урда чорында Казан шәһәре. (Казан сүзенең ясалышы, килеп чыгышы, казан сүзенең мәгънәсен ачыклау, сүзлекләр белән эшләү).
5. Казан ханлыгы. (Казан ханлыгы чорына караган тарихи шәхесләр белән танышу).
6. Казан Рәсәй шәһәре. (Казан шәһәренең Рәсәй составына керүе, Рәсәй халыклары бердәмлеге турында мәгълүмат бирү).
7. Казан дуслык шәһәре.( Казан шәһәрендә яшәүче төрле милләт халкының дус-тату яшәве хакында сөйләшү, милли гореф-гадәтләр белән танышу).
8. Данлыклы шәхесләр. (Казан шәһәре белән бәйле булган күренекле шәхесләр белән танышу).
9. Мәдәни Казан. (Казан шәһәрендә үткәрелә торган төрле мәдәни, спорт чаралары турында сөйләшү).
10. Бүгенге Казан. (Борынгы һәм бүгенге Казан шәһәрен чагыштыру. Казан шәһәренең үсеше, яңа төзелеш объектлары, метро станцияләре, спорт сарайлары турында мәгълүмат алу).
11. Йомгаклау. (Чакырылган ата-аналар өчен ачык чара үткәрү).

Дәресләрдән тыш эшчәнлек – балаларга төп белем бирүнең, аларны шәхес буларак үстерүнең аерылгысыз бер өлеше. Сәләтле укучыларны даими рәвештә конкурсларда катнаштыру аларның үзләренең дә мөмкинлекләрен, белемнәрен ачыклауга ярдәм итә, уңышлар яулауга этәрә. Югарыда санап кителгән эшләрнең барысы да укучыларны иҗади актив шәхес итеп тәрбияләргә мөмкинлек бирә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Гилязов И.А., Пискарев В.И., Султанбеков Б.Ф., Хузин Ф.Ш. Казаневедение. Учебное пособие для начальной школы. - Казань: Тамга, 2006. - 192 с.
2.Әхмәтьянов Р.Г.Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. Т.1- Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Т.1: А – В. – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – 712 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Т.2: Г – Й. – Казан: ТӘҺСИ, 2016. – 748 б.

# «Татар халкы мәдәнияте» дәрестән тыш эшчәнлек программасы
# (Укучыны рухи-әхлакый яктан үстерү юнәлеше)
# 5-6 сыйныф укучылары өчен

*Макарова Ирина Александр кызы, Корманова Айсылу Шәүкәт кызы,*
*Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең югары квалификацион категорияле һәм беренче квалификацион категорияле туган тел укытучылары*

**Аңлатма язуы**

Халыкларның традицион мәдәнияте - милләтнең үзтәңгәллеген саклау нигезе ул. Нәкъ менә шуңа күрә дә безнең инануыбызча, туган илен яраткан чын гражданинны тәрбияләү процессында тамырларыбызга, телебезгә, мәдәниятебезгә таянырга кирәк. Милли мәдәниятне, телне өйрәнү үз халкыңның тарихын тирәнрәк аңларга гына ярдәм итеп калмыйча, балаларда милли үзаңны формалаштыруда да зур роль уйный. Гореф-гадәтләрдә, мәкальләрдә, әйтемнәрдә, җыр-биюләрдә һәм бәйрәмнәрдә чагылыш тапкан милли әхлак нигезләре булачак гражданинга әхлакый тәрбия бирүнең ышанычлы программасы булып хезмәт итә.

Борынгы бабаларыбызның үзенчәлекле мәдәниятен өйрәнү үсеп килүче буынга әхлакый, патриотик һәм эстетик тәрбия бирү бурычларын үтәү дә зур әһәмияткә ия.

**Программаның актуальлеге.** Бүгенге халыкларның милли үзаңы үсеше белән генә түгел, милләтара мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе белән дә сыйфатлана торган чорда җәмгыять тарафыннан күп еллар дәвамында белем бирүнең халыкчанлыгы ягыннан югалтылган, җуелган кыйммәтләрне яңадан торгызу һәм аңлау зарур. Һәм бүген, ата-бабаларыбызның үзенчәлекле мәдәниятенә кагылган саен, без генетик хәтерне уятабыз, яшь буынның акылында һәм йөрәгендә туган тамырларга, Ватанга, гаиләгә мәхәббәт, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбиялибез, башка халыкларның мәдәниятен аңлауга, янәшәдәге кешеләр белән гармониядә, татулыкта яшәргә кирәклеген төшендерүгә нигез салабыз.

«Татар халкы мәдәнияте» дип аталган дәрестән тыш эшчәнлек программасы 5-6 нчы сыйныф укучылары белән эшләү өчен төзелгән һәм танып-белү эшчәнлегенә юнәлдерелгән. Урта гомуми белем баскычында укучыларны рухи-әхлакый үстерү һәм тәрбияләү программасының норматив-хокукый һәм документлар нигезе булып Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Законы, Россия гражданины шәхесен рухи-әхлакый үстерү һәм тәрбияләү концепциясе, федераль дәүләт белем бирү стандарты тора.

«Татар халкы мәдәнияте» программасы буенча курс - мәктәптә милли белем бирү системасын булдыруга, балаларны үз халкының тирән традицион мирасыбелән кызыксындыруга юнәлдерелгән эшнең состав өлеше.Әлеге курс киләчәктә музыка, сынлы сәнгать, хореография, хезмәт, физик тәрбия кебек халык мәдәниятен үзләштерүне дә күз уңында тоткан дисциплиналар комплексы өчен дә нигез булырга мөмкин.

**Курсның максатлары:**

1.Укучыларда гражданлык үзаңын үстерүгә ярдәм итү;
2. Укучыларны халыкның тарихи хәтеренә аңлауга тарту;
3. Балаларны татар теленең һәм сөйләм культурасының үзенчәлекләре белән таныштыру;
4. Татар халык мәдәниятенең үзенчәлеген һәм кабатланмаслыгын күрсәтү;
5. Укучыларны алга таба төрле типтагы мәдәниятләрне үзләштерүгә әзерләү: дөньякүләм мәдәни-тарихи процессның состав өлеше буларак, үзләренең милли мәдәниятен һәм башка милли мәдәниятләрне, хөрмәтләү.

Курс 2 елга исәпләнгән. Ике ел дәвамында балалар алдында тарихи, фольклор һәм этнография материалларында гасырлар дәвамында татар халкы тарафыннан тупланган дөньяны аңлау системасы ачыла, шуңа күрә программада түбәндәге сораулар карала:

1. Курсны өйрәнгәндә укучылар татар халкының төрле иҗади эшчәнлеге төрләре белән танышалар.

2. Дәресләрдә укучылар гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр белән танышу аркылы милли мәдәниятне өйрәнәләр.

3. Татар теленең үзенчәлекләрен, аның сөйләм телен, сөйләм культурасын өйрәнәләр.

Бу курста «халык мәдәниятендә кеше һәм гаилә» мәсьәләләре мөһим белем-тәрбия бирү әһәмиятенә ия. Программада «Аулак өй», «Бергә уйныйк» бәйрәмнәре рәвешендәге йомгаклау дәресе каралган, анда башка милләт балалары, шулай ук үз халкының тарихын һәм мәдәниятен факультатив рәвешендә өйрәнүчеләр дә катнаша.

**Курсның бурычлары**

**Белем бирү бурычлары:**

• татар халкының мәдәнияте турында белем алу;
• укучыларда туган телен өйрәнүдә мөстәкыйль эшләргә ихтыяҗ тудыру;
• татар телен һәм мәдәниятен өйрәнүгә кызыксынуны үстерү;
• иҗадилыкны үстерү һәм сүзлек запасын баету;
• укучыларның гомуми тел үсешен камилләштерү;
• әдәби тел турында белемнәрне һәм күзаллауларны тирәнәйтү һәм киңәйтү.

**Тәрбияви бурычлар:**

• китап белән эшләү культурасын үстерү;
• укучыларның төрле яклы кызыксынуларын, фикерләү культураларын формалаштыру һәм үстерү;
• төрле милләт халыклары арасында дуслык тәрбияләү, әхлакый нормаларны үстерү һәм укучыларның рухи дөньясын баету, татар халкының сөйләм этикеты белән таныштыру.

**Үстерелешле бурычлар:**

- укучыларның тапкырлыгын һәм зирәклеген үстерү;
- укучыларны мөстәкыйль эзләнү-тикшеренү эшенә җәлеп итү;
- төрле сүзлекләрдән файдалана белүне үстерү;
- шәхси һәм коллектив эшчәнлектә китап белән эшләргә өйрәтү.

Укучыларның дәрестәге эшчәнлеген оештыру түбәндәге принципларга нигезләнә:

- кызыксындыру уяту;
- фәннилек;

- аңлылык һәм активлык;
- күрсәтмәлелек;
- аңлаешлылык;
- теория белән практиканың үзара бәйләнеше;
- укучыларга шәхси якынкилү.

Дәрестән тыш эшчәнлек һәр укучыга шәхси якын килүне, аның сәләтен исәпкә алып, әлеге сәләтне аеруча уңышлы кулланырга, укучыларның танып белүдәге һәм тормыш-көнкүрештәге мәнфәгатьләрен тулырак канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә. Сыйныф, предмет дәресләреннән аермалы буларак, дәрестән тыш эшчәнлек сәгатьләрендә бик аз язалар һәм күп сөйлиләр.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең формалары:**

- түгәрәк;
- эшлекле уеннар һәм уен элементлары;
- индивидуаль эш;
- төркемнәрдә эш;
- проект эшчәнлеге;
- фәнни-эзләнү тикшеренү эшчәнлеге;
- экскурсияләр. Практика.

**Төп метод һәм технологияләр:**

- төрле югарылыктагы укыту технологиясе;
- үстерелешле укыту;
- хезмәттәшлектә укыту технологиясе;
- коммуникатив технология.

Технологияләрне һәм методикаларны сайлап алу укучының универсаль уку гамәлләрен һәм шәхси сыйфатларын үстерү максатларында укуны дифференциацияләү һәм индивидуальләштерү зарурлыгына бәйле.

**Укучылар эшчәнлеген оештыруның төрләре**: уен эшчәнлеге, танып-белү эшчәнлеге, проблемалы- кыйммәти аралашу, вакытны дөрес кулланып, укучыларның буш вакытын мавыктыргыч оештыру, әдәби иҗади эшчәнлек.

**Курсның уку планындагы урынын билгеләү (тасвирлау):**

Программа 2 елга исәпләнгән. Дәресләр атнага бер тапкыр 5-6 нчы сыйныфларда 40 минут үткәрелә. Программаны өйрәнү курсы 5-6 нчы сыйныф укучыларына исәпләнгән.

## Планлаштырылган нәтиҗәләр
## 5 нче сыйныф

**Шәхескә юнәлтелгән нәтиҗәләр:**

- кешеләр тормышында туган тел һәм сөйләмнең мөһим роль уйнавына төшенә алу;
- текстны эмоциональ кичерешләр белән укый алу, үз хисеңне чагылдыра белү;
- башкаларның хисләрен аңлый алу, аларның хәленә керә белү, уртаклашу;
- укылган әсәр геройлары һәм аларның эш-адымнарына үзбәя бирү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

*Регулятив УУГ:*

- укытучы ярдәмендә эшчәнлекнең максатын билгели һәм формалаштыра алу;
- материал белән эшләү вакытында үз фаразыңны әйтергә өйрәнү;
- укытучы тәкъдим иткән план буенча эшләргә өйрәнү.

*Танып белү УУГ:*

- сорауларга җавапларны текстлардан, рәсемнәрдән таба алу;
- сыйныф һәм укытучының уртак эшчәнлегенә йомгак ясап, нәтиҗә чыгара белү.

*Коммуникатив УУГ:*

- үз фикерләреңне язып һәм телдән сөйләп (җөмләләр яки зур булмаган текст ярдәмендә) бирә белү;
- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый алу;
- парларда һәм төркемнәрдә эшләргә өйрәнү;
- төрле рольгә (лидер, башкаручы һәм башка рольләр) керә белү.

**6 нчы сыйныф**

**Шәхескә юнәлтелгән нәтиҗәләр:**

- кешеләр тормышында туган телнең һәм сөйләмнең мөһим роль уйнавына төшенә алу;
- текстны эмоциональ кичерешләр белән укый алу, үз хисеңне чагылдыра белү;
- башкаларның хисләрен аңлый алу, аларның хәленә керә белү, уртаклашу;
- башка кешеләрнең телдән һәм язмача әйтелгән сөйләм үзенчәлекләренә (сөйләм интонацисе, темпы, тоны; сүзләр һәм тыныш билгеләрен сайлау үзенчәлеге: нокта яки күпнокта, нокта яки өндәү билгесе) игътибар итә белү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

*Регулятив УУГ:*

- укытучы ярдәмендә эшчәнлекнең максатын билгели һәм формалаштыра алу;
- материал белән эшләү вакытында үз фаразыңны әйтергә өйрәнү;
- укытучы тәкъдим иткән план буенча эшләргә өйрәнү.

*Танып белү УУГ:*

- сорауларга җавапларны текстлардан, рәсемнәрдән таба алу;
- сыйныф һәм укытучының уртак эшчәнлегенә йомгак ясап, нәтиҗә чыгара алу;
- хәбәрне бер формадан икенче формага үзгәртә алу: зур булмаган текстларны җентекләп сөйли белү.

*Коммуникатив УУГ:*

- үз фикерләреңне язып һәм телдән сөйләп (җөмләләр яки зур булмаган текст ярдәмендә) бирә белү;
- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый алу; тыңлау алымнарын куллану: тема һәм төп сүзләрне теркәү;
- текстны сәнгатьле уку һәм сөйләү;
- укытучы ярдәмендә классташларың янында үз-үзеңне тоту белү һәм аралаша алу кагыйдәләрен үзләштерү, бәяләү һәм үзбәя бирү турында килешә алу һәм аларны үтәү;
- парларда һәм төркемнәрдә эшләргә өйрәнү; төрле рольгә (лидер, башкаручы һәм башкарольләр) керә белү.

**5 сыйныф өчен оештыру формалары һәм эшчәнлек төрләре күрсәтелгән дәрестән тыш эшчәнлекнең эчтәлеге**

**1 бүлек. Халык авыз иҗаты (6 сәг.)**

**1 тема.** *Халык авыз иҗаты жанрлары. (1 сәг.)*

Халык авыз иҗаты буларак фольклор турында төшенчә. Халык авазы иҗаты жанрлары белән танышу (мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар. мәзәкләр, бишек җырлары). Табышмаклар чишү.

**2-3 темалар**. Мәкальләр һәм әйтемнәр. *(2сәг.)*

Ата-бабаларыбызның рухи дөньясы, идеаллары белән танышу. Укучыларның сүзлек запасын киңәйтергә ярдәм итү. Тема буенча мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар туплау. «Теләгеңне тормышка ашыру өчен - тырышлык куй» дигән класс альбомы төзү һәм аны балаларның рәсемнәре белән бизәү.

**4 тема.** *Җырлар. Бишек җырлары. (1 сәг.)*

Татар халык җырлары белән танышу, өйрәнү, сәхнәләштерү. Фольклор бәйрәмнәренә бару, җырлар тыңлау. Татар җырчылары И.Шакиров, С. Фәтхетдинов иҗаты белән танышу. Татар халык хорларының чыгышларын тыңлау.

**5-6 темалар.** *Татар халык әкиятләре. (2 сәг.)*

Татар халык әкиятләре белән танышу аркылы, без татар теленең матурлыгын аңлату.Татар теленең байлыгын, күркәмлеген һәм сихри көчен күрсәтү.

Укучыларның үзләренә дә әкиятләр иҗат итәргә булышу. Аларны «Минем беренче әкиятләрем»дип исемләнгән гомуми сыйныф әкиятләр китабына туплау. Өйрәнгән әкиятләр буенча рәсемнәр, кул эшләре конкурслары үткәрү. «Таңбатыр» әкиятен сәхнәләштерү.

Ата-бабаларыбызның рухи дөньясы, идеаллары белән танышу. Укучыларның сүзлек запасын киңәйтергә ярдәм итү.

**2 бүлек. Татар халкының көнкүреш үзенчәлекләре.**

**7-8 темалар.***Татар йорты интерьеры. (2сәг.)*

Укучыларны борынгы татар йортын төзекләндерү үзенчәлекләрен өйрәтү. Борынгы җиһазлар, аны әзерләү серләре белән таныштыру.

Мәктәп музеенда булу.

«Татар йорты» рәсемнәр конкурсы.

**3 бүлек. Декоратив-гамәли сәнгать төре буларак татар костюмы.**

**9 тема.** *Татар милли киеменең үсеш тарихы. Костюм элементлары.*

Татар халык костюмы элементлары белән танышу (калфак, читек, күлмәк, түбәтәй). «Татар халкының мирасы» дигән альбом төзү.

**10 тема.** *Орнамент-татар костюмының структур элементы.*

Татар халык орнаменты белән танышу. Орнаментны сәнгати һәм мәдәни-тарихи үзенчәлек буларак өйрәнү.

**4 бүлек. Милли кухня.**

**11 тема.** *Татар кухнясының үзенчәлекләре.*

Татар ашларының үзенчәлекләре белән танышу. Гади ризык әзерләү рецептлары белән өйрәнү.

**12 тема.** *Чәкчәк һәм өчпочмак әзерләү рецептлары.*

Татар ашларының үзенчәлекләре белән таныштыру. «Татар халык ашлары» темасына презентация төзү.

**5 бүлек. Халык биюләре. (2 сәг.)**

**13 тема.** *Татар халык биюенең үзенчәлекләре.*

Татар биюенең традицион хореографиясе белән танышу. Татар биюенең төрләре. «Каз канаты» татар халык биюе турында видеофильм карау.

**14 тема.** *Татар халык биюе «Әпипә»*

Әпипә бию композициясе белән танышу. Биюдә төп хореография хәрәкәтләрен ачыклау.

**6 бүлек. Татар халкының традицияләре һәм гореф-гадәтләре. (3 сәг.)**

**15 тема.** *Дини бәйрәмнәр: Корбан бәйрәме, Ураза бәйрәме.*

Татар халкының традицион дини бәйрәмнәре белән танышу. Бу бәйрәмнең характерлы үзенчәлекләре, татар халкы өчен тарихи әһәмияте. “Татар халык бәйрәмнәре» темасына презентация карау.

**16-17 темалар.** «*Аулак өй», «Каз өмәсе» - татар халкының йола бәйрәмнәре. «Аулак өй» бәйрәмен сәхнәләштерү.*

Татар халкының көнкүреш бәйрәмнәре белән танышу. «Аулак өй» видеофильмын карау. «Татар бәйрәмнәре һәм йолалары» темасына альбом төзү. Рәсем конкурсы үткәрү.

**7 бүлек. Туган тел серләре.(18 сәг.)**

**18 тема.** *Татар теленең алфавиты.*

Татар теле алфавитын өйрәнү: хәрефләрнең дөрес атамасы, әйтелеше, аларның эзлеклелеге. Рус һәм татар алфавитының аермасы.Татар халкының рухи һәм сүз байлыгы турында әңгәмә: «Туганлык буенча кемнең кем булуы», «Кем күбрәк?», «Сүзләр чылбыры».

**20 тема.** *Авазларның классификациясе***.** *Сузык авазлар.*

Сөйләм авазлары. Сүздәге авазлар составының берлеген һәм аның мәгънәсен билгеләү. Сүздә авазларның санын һәм эзлеклелеген билгеләү. Бер яки берничә аваз белән аерыла торган сүзләрне чагыштыру.«Дөрес яз», «Бары тик яхшы» уеннары. Игътибар һәм чисталык конкурсы. Яхшы сүзләр парады. Сузык авазларны кабатлау.

**21-22 темалар.** *Тартык авазлар***.**

Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру, яңгыраулык һәм саңгыраулык буенча парлы һәм парсыз авазларны билгеләү.

Авазларның сыйфат характеристикасын билгеләү: парлы — парсыз, яңгырау-саңгырау тартыклар.

**23-24 темалар.** Фонетик анализ тәртибе.

Фонетик анализ тәртибе белән танышу. Табышмаклар чишү. Авазларның әйтелеше буенча күнегүләр эшләү. «Өч кыз» татар халык әкияте..

**25-26 темалар.** *Лексика. Сүзнең сүзлек составы.*

Татар теле лексикасының «яхшы сүзләргә» бай булуы турында әңгәмә. Роберт Миңнуллинның «Әни, мин көчек күрдем» шигыре өстендә эшләү.«Исәнләшә беләсезме?» уены. Әлеге темага караган текстлар белән эшләү.

**27-28 темалар.** *Синонимнар, антонимнар, омонимнар.*

Синоним сүзләр белән танышу. «Синонимнар нәрсәне белдерә?» – әңгәмә. Синоним сүзләрне тексттан табу.

Антоним сүзләр белән танышу. Татар телендә антонимнар куллану очраклары. «Хәерче һәм ике бай» дип аталган татар халык әкиятендәге антонимнарны билгеләү. «Кирәкле сүзләрне сайла» уены. Антоним сүзләрне сайлау өстендә эш. Укытучының татар телендә антонимнарның роле турында сөйләве.

**29 тема.** *Морфология. Сүз төркемнәренең классификациясе.*

Сүз төркемнәренең классификациясе турында белемнәрне тирәнәйтү һәм киңәйтү. «Морфология». «Исем». Орфоэпик нормаларны үтәп, сүзләрнең дөрес әйтелешенә өйрәтү.

**30 тема.** *Сүз төркеме буларак исем.*

Исем сүз төркеме турында төшенчә. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Исемнәрнең нинди сорауларга җавап бирүен; исемнәрнең морфологик билгеләрен кабатлау.

**31 тема.** *Сүз төркеме буларак сыйфат.*

Мөстәкыйль сүз төркеме буларак сыйфатлар белән танышу, аңа хас үзенчәлекләр. Сыйфатларның ясалышы белән таныштыру. Сөйләм культурасы үсеше. Орфоэпия һәм фонетика.

**32-33 темалар.** *Сүз төркеме буларак фигыль***.**

Татар теленең морфологиясе белән танышуны дәвам итү. Сүз төркеме буларак фигыль белән танышу. Төрле аңлатмалы сүзлекләр белән эшләү, татар телендә яңа сүзләр барлыкка килү тарихы белән танышу.

**34 тема.** *Йомгаклау дәресе***.** *Белемлеләр конкурсы.*«Бәхетле очрак» интеллектуаль уены.

**5 нче сыйныф өчен тематик план**

| **Эшчәнлекнең (дәрес) тәртип саны** | **Тема** | **Сәгать саны** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Барлыгы** | **Теория** | **Практика** |
| **1 нче бүлек. Халык авыз иҗаты– 6 сәгать** | | | | |
| 1 | Халык авыз иҗатының жанр төрләре. | 1 | 1 | |
| 2 | Мәкальләр | 1 | | 1 |
| 3 | Әйтемнәр. | 1 | | 1 |
| 4 | Җырлар. Бишек җырлары. | 1 | | 1 |
| 5 | Татар халык әкиятләре. | 1 | 1 | |
| 6 | Татар халык әкиятләре. | 1 | | 1 |
| **2 нче бүлек. Татарларның көнкүреш үзенчәлекләре – 2 сәгать** | | | | |
| 7 | Татар ызбасының (өенең) җиһазлары. (Интерьер) | 1 | 1 | |
| 8 | Татар ызбасының (өенең) бизәлеше. | 1 | | 1 |
| **3 нче бүлек. Декоратив-гамәли сәнгатьнең бер төре буларак татар костюмы – 2 сәгать.** | | | | |
| 9 | Татар милли костюмының үсеш тарихы. Костюмның өлешләре (элементлары). | 1 | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Татар костюмының аерылгысыз (структур) өлеше буларак орнамент. | 1 | | 1 |
| **4 нчебүлек. Милли ризыклар– 2 сәгать** | | | | |
| 11 | Татар милли ашларының үзенчәлеге. | 1 | 1 | |
| 12 | «Чәкчәк», «Өчпочмак» кебек ризыкларны әзерләү рецепты. | 1 | | 1 |
| **5 нче бүлек. Халык биюләре - 2 сәгать** | | | | |
| 13 | Татар халык биюенең үзенчәлеге. | 1 | 1 | |
| 14 | Татар халык биюе «Әпипә». | 1 | | 1 |
| **6 нчы бүлек. Татар халкының традицияләре һәм гореф-гадәтләре – 3 сәгать** | | | | |
| 15 | «Корбан» һәм «Ураза» дини бәйрәмнәре. | 1 | 1 | |
| 16 | «Аулак өй», «Каз өмәсе» - татар халкының гореф-гадәтләре. | 1 | | 1 |
| 17 | «Аулак өй» бәйрәмен сәхнәләштерү. | 1 | | 1 |
| **7 нче бүлек.Туган телнең серләре – 17 сәгать** | | | | |
| 18 | Татар алфавитының серле яклары. | 1 | 1 | |
| 19 | Үз авазларыбыз! | 1 | | 1 |
| 20 | Әй, бу кызык сузык авазлар! | 1 | | 1 |
| 21 | Тартыламы, сузыламы тартык авазлар? | 1 | | 1 |
| 22 | Тартык, тартык аваз дибез... | 1 | | 1 |
| 23 | Авазларны фонетик яктан тикшерү ничек була? | 1 | 1 | |
| 24 | Сүз төзелеше. Кушабызмы, ялгыйбызмы, аерабызмы? | 1 | | 1 |
| 25 | Лексика - сүзләрме ул? | 1 | | 1 |
| 26 | Сүзлекләр. | 1 | 1 | |
| 27 | Әһә, белдем синоним һәм антонимнарны! | 1 | | 1 |
| 28 | Омонимнар – «омон» белән бәйләнгәнме әллә? | 1 | | 1 |
| 29 | Морфологиянең нәрсә икәненә төшенәсезме? | 1 | 1 | |
| 30 | Сүз төркеме буларак исем ничек була ул? | 1 | | 1 |
| 31 | Сыйфат – ул кеше сыйфатымы? Әллә... | 1 | | 1 |
| 32 | Фигыльме, «фигель»ме? | 1 | | 1 |
| 33 | Фигыль сүз төркеменең нинди кызык яклары була икән?! | 1 | | 1 |
| 34 | Йомгаклау. Белемлеләр конкурсы. | 1 | | 1 |
| **Барлыгы:** | | **34** | **11** | **23** |

**6 нчы сыйныф өчен дәрестән тыш эшчәнлек курсының эшчәнлек төрләре һәм оештыру формалары күрсәтелгән эчтәлеге**

**1нче бүлек. Татар халкының милли традицияләре – 10 сәгать**

Халык традицияләре, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары, халык уеннары, милли кием үзенчәлекләре.

Танып белү эшчәнлеге белән бәйле темалар түбәндәге юллар белән чишелә:
- балаларга этнографик характердагы мәгълүмат бирү: үзенчәлекле милли исемнәр, милли кием, милли ризыклар, халык бәйрәмнәре, халык уеннары;
- халык традицияләренә карата үз мөнәсәбәтен белдерә алу өчен практик рәвештә сынлы сәнгать материалларын үзләштерү.

**2 нче бүлек. Халык иҗаты – 15 сәгать**

Иҗади эшчәнлек белән бәйле темалар түбәндәге юллар белән чишелә:
- балаларга халык геройлары, милли шагыйрьләр, язучылар, спортчылар, гореф-гадәтләр, йолалар турында мәгълүмат бирү;
- балаларның фольклорны: әкиятләр, мәкальләр, әйтемнәр, бишек һәм юату җырлары практик рәвештә үзләштерүләре, өйрәнүләре.

Халык авыз иҗаты турында гомуми төшенчә. Фольклор жанрлары белән танышу. Әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар. Аларда халык акылы һәм күзәтүчәнлегенең чагылышы.

Табышмак, мәкаль һәм әйтемнәрнең сәнгать үзенчәлеге.

Мәкаль һәм әйтемнәрдә халык зирәклеге чагылышы: туган җиргә мәхәббәт; хыянәт, битарафлык, ялган һәм ялкаулыкны фаш итү. Мәкальләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе. Татар халкының табышмак, мәкаль һәм әйтемнәре, аларны рус вариантлары белән чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын ачыклау.

**3 нче бүлек. Туган телдә аралашу – 9 сәгать**

Татар халкының тарихи үсеше. Түбәндәге бүлек - йомгаклау бүлеге булып тора һәм барлык үткән материалны ныгытуны күздә тота.

Коммуникатив эшчәнлек белән бәйле темалар түбәндәге юл белән чишелә:
- татар халкының барлыкка килү тарихы, архитектура, тарихи, экологик истәлекләр, тарихи шәхесләр, күренекле әһелләр, халык геройлары турында күзаллауны киңәйтү;
- татар халкының төп һәм традицион хезмәт төрләре үзенчәлекләрен мөстәкыйль рәвештә тикшерүләре: халык кәсепләре һәм һөнәрләре, көнкүреше, гаиләдәге хуҗалык эшләре. Бу эшкә ата-аналар да җәлеп ителә. Алар балаларына чын тарихи фактлар таныргa, таныштыру өчен материал җыярга ярдәм итәләр, йорт хуҗалыгында төрле эш йөклиләр, хезмәткә өйрәтәләр.

**6 нчы сыйныф өчен тематик план**

| Эшчәнлекнең (дәрес) тәртип саны | Тема | Сәгать саны | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика |
| **1 бүлек. Татар халкының милли традицияләре – 10 сәг.** | | | | |
| 1 | Идел буе татарлары. Татар телендә сәламләү сүзләре. | 1 | 1 | |
| 2 | Татар милли киеме. Рәсемнәр, модельләштерү. | 1 | | 1 |
| 3 | Халык бәйрәмнәре һәм халык традицияләре. Татар халык бәйрәме-Сабантуй. Бәйрәмнең барлыкка килү тарихы. | 1 | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Нәүрүз, Сөмбелә, Нардуган милли бәйрәмнәре | 1 | | 1 |
| 5 | Декоратив-гамәли сәнгать. Татарларның зәркән бизәнү әйберләре. Баш һәм муен-күкрәк бизәнү әйберләре | 1 | 1 | |
| 6-7 | Татар орнаменты үрнәкләре. Татар чигүе. Сөлге, җәймә, эскәтерләр чигү. Чигү техникасы. | 2 | 1 | 1 |
| 8 | Татар милли кухнясы: традицияләр һәм гореф-гадәтләр. Татар ашларының үзенчәлекле яклары, үзенчәлекләре. | 1 | 1 | |
| 9-10 | Күрше халыкларның гореф-гадәтләрен үстерүгә йогынтысы. Татлы визит карточкасы, чәкчәк - иң яхшы сувенир. | 2 | 1 | 1 |
| **2 бүлек. Халык иҗаты – 15 сәгать** | | | | |
| 11 | Шигъри иҗат төрләре һәм жанрлары. Йола фольклоры. | 1 | 1 | |
| 12 | Татар бишек җырлары. Татар музыкасы. | 1 | | 1 |
| 13 | Балалар китаплары, газеталар, журналлар белән татар телендә танышу. Җыр иҗаты. Халык уены кагыйдәләре белән танышу. | 1 | | 1 |
| 14-16 | М. Җәлил әсәрләре белән танышу. | 3 | 1 | 2 |
| 17-19 | Г. Тукай әсәрләре белән танышу. | 3 | 1 | 2 |
| 20-21 | Музыкаль мәдәният. Иң киң таралган музыка кораллары-быргы, сорнай, курай. | 2 | 1 | 1 |
| 22-25 | Татар композиторлары Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова, Салих Сәйдәшев, Луиза Батыр-Болгари. | 4 | 2 | 2 |
| **3 бүлек. Туган телдә аралашу – 9 сәгать** | | | | |
| 26 | Алфавиттан шигырь төзеп буламы? | 1 | 1 | |
| 27 | Авазларны сузып җырлап карыйбыз. | 1 | | 1 |
| 28 | Тартык авазларның әйтелешендәге үзенчәлекләрне хәтерлисеңме? | 1 | | 1 |
| 29 | Татар теле морфологиясе руснықыннан аерыламы? | 1 | 1 | |
| 30 | Исем сүз төркеме– кеше исемнәреме ул? | 1 | | 1 |
| 31 | Нигә сыйфат дип кушканнар? | 1 | | 1 |
| 32 | Фигыльләрдәге кызык-мызыклар. | 1 | | 1 |
| 33 | Алмашлык алмашка! | 1 | | 1 |
| 34 | Тел белеменең бер бүлеге буларак синтаксис. | 1 | 1 | |
| **Барлыгы:** | | **34** | **15** | **19** |

## Дәрестән тыш эшчәнлек программасының методик яктан тәэмин ителеше

Программа түбәндәге алымнарны кулланып эш итүне күздә тота:

- сүз белән (хикәя, әңгәмә, аңлату, бастырылган чыганак белән эш);
- күрсәтмә (плакатлар, таблицалар, схемалар, рәсемнәр, презентацияләр);
- практик (телдән, язмача, график күнегүләр);

- проблемалы-эзләнүле (эвристик һәм проблемалы- эзләнүле әңгәмәләр);
- мөстәкыйль эш (күзәтү, проблема чишү, кирәкле алым һәм гамәлләрне ныгыту күнегүләре);
- уен (рольле, дидактик, үстерелешле уеннар, сәхнәләштерү һ.б.)

**Эшчәнлекнең нәтиҗәләрен тикшерү**

Нәтиҗәләрне тикшерү өчен түбәндәге формаларны куллану күздә тотыла:
- кереш (контроль), укучыларның шәхси үсешен ачыклау - ел башында һәм ел ахырында (Таблица 1);
- белем бирү программасын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү – 1 нче яртыеллык һәм 2 нчеяртыеллыкта (Таблица 2);
- йомгаклау – һәр бүлекне тәмамлаганнан соң (уен-конкурс, КВН, практик эш, презентация, концерт, сәхнәдә чаралар күрсәтү, конференцияләрдә катнашу һ.б.).

Программа белән эшләүнең нәтиҗәләре 3 дәрәҗәдә тикшерелә:

Нәтиҗәләрнең беренче дәрәҗәсе — укучының берләшмәдә иҗтимагый белемгә ия булуы (җәмгыятьтәге нормалар, аның төзелеше, анда үз-үзеңне тоту формалары турында беренчел күнекмәләр, берләшмәдә бирелгән материалны беренчел кабул итү, берләшмә эшләрендә актив катнашу).

Нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсе — укучы алган белемнәрне кулланып җәмгыять-нең төп кыймматләренә төшенә алуы (кеше, гаилә, Туган ил, табигать, тынычлык, белем, хезмәт, мәдәният), ул белемнәрне мәктәп күләмендә үткәрелгән чараларда катнашып,раслый алуы, димәк, социаль чынбарлыкка дөрес мөнәсәбәттә була алуга ирешүе.

Нәтиҗәнең өченче дәрәҗәсе — укучының җәмгыятьтә мөстәкыйль эш итү тәҗри-бәсенә ия булуы. (Район, шәһәр, республика күләмендә үткәрелгән чараларда катнаша алуы.)

**Кулланылган әдәбият**


1. Ал кирәк, гөл кирәк: Уеннар китабы.- Казан, 1995.
2. Әминов А. М. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. – Казан, 2002.
3. Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. – К., 1969.
4. Валеев Ф.Х. Татар керамика сәнгате. // Казан утлары, 1982, № 11.
5. Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. – Казань, 1995.
6. Гарипова В.А., Харисова Л.А. Родина моя Татарстан. – К., 1998.
7. Гулова Ф.Ф. Татарская национальная обувь. – К., 1969.
8. Гумилёв Л.Л. Древняя Русь и Великая степь. – М., 1988.
9. Жиганшина М. Музыка. – К., 1987.
10. Ибраһимова Менъеллыкка – мең теләк! // Сөембикә, 2002, № 12.
11. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. – Яр Чаллы, 2001.
12. Кенеман А.В. Детские подвижные игры народов СССР. – М., 1988.
13. Латышин Д.И. По берегам Идели. – М., 1995.
14. Мәхмүтов Х.Ш., Надиров И.Н. Татар фольклорында социаль мотивлар. – К., 1986.
15. Очерки истории и культуры. – М., 1987.
16. Рахимова Р.К. Асалы паласлар.// Азат хатын, 1974, №3.
17. Татарский народный костюм // Сөембикә, 2000, № 1.
18. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм Әйтемнәр. – К., 2000.

19. Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан, 1988.
20. Татар халык иҗаты: Табышмаклар.- Казан, 1988.
21. Татар халык иҗаты: Мәкальләр. – Казан, 1987.
22. Татар халык әкиятләре. – Казан, 1989.
23.Уразман Р. Татар халкының йола һәм бәйрәмнәре.- Казан, 1992.
24. Фахретдинова Р.Г. Ташлар моны. – К., 2005.
25. Фахрутдинов Р.Г. История татарского народа и Татарстана. – К., 2012.
26. Школьникам о татарском декоративно-прикладном искусстве. – Казань, 1997.
27. “Ялкын” журналлары”, “Сабантуй” газеталары.

Интернет ресурслар

http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
http://www.mon.tatar.ru
http://. belem.ru
http://. suzlek.ruon- line русча сүзлеге
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар
**http://anatele.ef.com/**
**http://www.balarf.ru/**
Татар16.ru - презентацияләр
www.dores.tatar - татар грамматикасының кагыйдәләре
https://www.azatliq.org/eyde - видеодәресләр

**Баланың берләшмәдә шәхси үсешен исәпкә алу (ел башы)**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сыйфатлары | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Психофизик | | | | | | Оештыру-ихтыяри | | | | | | | | | Мотивация дәрәҗәсе | | | | | | Үз-үзен тотуы | | | | | |
| | | Физик активлыгы | | | Психик активлыгы | | | Түземлелеге | | | Ихтыяр көче | | | Үз-үзен контрольдә тотуы | | | Үзен ярату дәрәҗәсе | | | Белем алуга кызыксыну | | | Конфликт тудыра алу мөмкинлеге | | | Хезмәттәшлек итә алу сәләте | | |
| | | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 |
| | | Тышкы яктан кабынучан | Давыл куптаручан | Үз-үзен тота ала | Тышкы яктан кабынучан | Давыл куптаручан | Үз-үзен тота ала | Дәреснең яртысыннан | Дәреснең яртысыннан | Дәрес буе | Һәрвакыт тышкы көч | Кайвакыт эчке көч | Һәрвакыт эчке көч | Һәрвакыт тышкы контроль | Вакыт-вакыт үзе | Һәрвакыт үзе | Артык югары | Түбән | Норма | Читләр контроле белән | Кайвакыт үз теләге белән | Һәрвакыт мотивацияле | Үзе сәбәпче | Конфликтта катнашмый | Конфликтны җайларга | Коллектив эшләрдән | Кеше кушуы белән генә | Үзе башлап йөри |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

**Карточканы тутыру кагыйдәләре**

Һәр баланы күзәтеп, аның үз-үзенең тотышына анализ ясаганнан соң, балага туры килгән сыйфат критерийын сайлап алып, таблицаны тутырырга кирәк. Аңа туры килгән сыйфат турысына “+” тамгасы куярга кирәк.

Укытучының ФИО ________________________________

Берләшмәнең исеме _______________________________

1 – түбән дәрәҗә; 2 – урта дәрәҗә; 3 –югары дәрәҗә

**Белем бирү процессы нәтиҗәләре картасы**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Белем бирү программасын үзләштерү дәрәҗәсе | | | | | | | | | | | | | | | | Казанышлар | | | | | Гомуми балл |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Бәяләү критерийлары | | | | | | | | | | | | | | | | Федераль | Республика | Шәһәркүләм | Район | Берләшмә | |
| | | Теоретик белемнәр | | | | Гамәли күнекмәләр | | | | Шәхси үсеш дәрәҗәсе | | | | Коллективта бергәләп эш итә алуга сәләтлелек | | | | | | | | | |
| | | Бик югары | Югары | Уртача | Түбән | Бик югары | Югары | Уртача | Түбән | Бик югары | Югары | Уртача | Түбән | Бик югары | Югары | Уртача | Түбән | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | |
|---|---|---|
| Бик югары - 4 б | федераль казанышлар – 4 б | берләшмә – 0,5 б |
| Югары - 3 б | республика – 3 б | |
| Уртача – 2 б | шәһәркүләм– 2 б | |
| Түбән - 1 б | район – 1 б | |

## Белем бирү процессы

Берләшмә исеме ________________________________________________________________________
Укытучының ФИО ______________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
Үткәрү вакыты_________________________________________________________________________
Уткәрелү урыны________________________________________________________________________
Үткәрү формасы_______________________________________________________________________
Кайсы сыйныф_________________________________________________________________________
Уку елы________________________________________________________________________________
Берләшмәдәге бала саны:_________________________________________________________________
Диагностика үткәрү вакытында катнашучыларның саны; _____________________
Диагностика нәтиҗәләре буенча:
Бик югары БОК (ЗУН) (13-16 балл)___________________________(балалар саны)______
Югары БОК (ЗУН) (9-12 балл)_________________________________( балалар саны)______
Уртача БОК (ЗУН) (6-8 балл)___________________________________ (балалар саны )_____
Түбән БОК (ЗУН) (4-5 балл)_____________________________________( балалар саны)____
Мониторинг ________________________________________
Алардан: _________________________________________
Авыру сәбәпле:_________________________________________________________________________
Китүчеләр:_____________________________________________________________________________
Укытучы: _______________________________________

## “Халкыбызның күңел җәүһәрләре”
## дәрестән тыш эшчәнлек программасы
## (гомуммәдәни юнәлеш)
## 5 нче сыйныф

*Фәхриева Лилия Госмановна, Казан шәһәре Совет районы“108 нче төп гомуми белем мәктәбе”гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Аңлатма язуы**

Программа юнәлеше: гомуммәдәни
Укучыларның яше: 11 яшь
Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру формасы: түгәрәк

Төп гомуми белем бирүнең ФДББС шартларында дәрестән тыш эшчәнлек түбәндәге норматив документлар һәм материалларга нигезләнеп оештырыла:

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларын керткәндә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру турында» хаты, 12 май 2011 ел, №03- 296;

– СанПиН 2.4.2.2821-10 «Гомуми белем бирү оешмаларында укыту шартларына һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр»;

– СанПиН 2.4.4.1251-03 «Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр»;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасының юнәлеше турында» хаты, 13 май 2013 ел, № ИР-352/09;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасын тормышка ашыруда чаралар исемлеген формалаштыру буенча тәкъдимнәр турында» хаты, 12 июль 2013 ел, № 09-879;

– РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының методик хаты № 09-1672, 18.08.2017 ел.

Бүгенге көндә Россия белем бирү системасының төп максаты булып тирән белемле укучылар тәрбияләп үстерү генә түгел, ә бар яктан да камил шәхес тәрбияләү тора. Укучы шәхесе педагогиканың игътибар үзәгенә куела. Бу максатны тормышка ашыру өчен баланы һәрьяклап үстерүгә юнәлдерелгән “Дәрестән тыш эшчәнлек” бүлеген үз эченә алган яңа буын федераль дәүләт белем стандарты булдырылды. Балага рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирүнең төп документаль нигезен “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы Законы, ФДББС, Россия гражданинына рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирү Концепциясе тәшкил итә. Стандартта мондый юллар бар: “Гомуми белем бирүнең башлангыч баскычында рухи-әхлакый яктан үстерү һәм тәрбия бирүнең төп максаты булып Ватан язмышын үз язмышы итеп кабул итүче, үз иленең бүгенгесе һәм киләчәге өчен җаваплылыгын аңлаучы, күпмилләтле Россия Федерациясе халыкларының рухи һәм мәдәни гореф-гадәтләре үрнәгендә тәрбияләнгән югары әхлаклы, иҗади, белемле Россия гражданины тәрбияләү тора.”

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары укучыларның аралаша белү осталыгына, билгеле күләмдә тел байлыгына ия булуына, эзлекле фикерли белү сәләтенә, сөйләм күнекмәләренә ия булуын таләп итә.

Бу таләпләрне тормышка ашыруда тел һәм әдәбият дәресләре генә түгел, ә дәрестән тыш эшчәнлек тә зур файда китерә. Әлеге укыту формасы белем бирү процессының бер өлеше булып тора. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары да бу эшчәнлекне тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Дәрестән тыш чараларның төп максаты – дәрестә каралган теоретик материалларны тирәнтен өйрәнү генә түгел, алган белемнәрен стандарт булмаган мәсьәләләр чишүдә куллана белү күнекмәләрен үстерү дә. Шулай ук балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелергә һәм үткәрү формасы буенча дәрес системасыннан аермалы булырга тиеш. “Халкыбызның күңел җәүһәрләре” дәрестән тыш эшчәнлек программасы шуларны истә тотып төзелде.

Татар теле буенча оештырыла торган дәрестән тыш эшчәнлек – бөтен укыту-тәрбия процессының аерылгысыз бер өлеше. Дидактик, методик һәм гамәли яктан дөрес оештырылган эш укучыларның белемнәрен киңәйтә. Дәрестән тыш эшчәнлекнең педагогик яктан әһәмияте тагын шунда: укучылар тел буенча дәреслектә булмаган кызыклы материаллар белән танышалар, дәрестән тыш чараларда катнашу нәтиҗәсендә алган белемнәрен дәрестәге мөстәкыйль эш вакытында да файдалана алалар.

Һәр халык үзенә хас булган гореф-гадәтләргә бай. Соңгы вакытта туган телебезгә, шулай ук борынгыдан килгән йолаларга игътибар бик нык артты, чөнки татар халкының башка халыклар кебек үк тарихы, үткәне бик бай, йола-бәйрәмнәре һәм уеннары да күп төрле.

Дәрестән тыш эшчәнлек программасын төзегәндә, укучыларны шушы халык бәйрәмнәре һәм йолалары үрнәгендә тәрбияләү, җыр-биюләрне өйрәтү, шулар аша дуслык хисләре тәрбияләү, милли хисләр, туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияләү алгы планга куелды.

Укучыларны балалар шагыйрьләре, әсәрләре белән тирәнрәк таныштыру, аларның әсәрләрен күбрәк уку теләге уяту максатлары да күздә тотылды. Укучылар шулай ук үткән темалар ярдәмендә иҗади эш итеп шигырь, әдәби әсәр укырга өйрәнеп, сәхнәдә күрә белү, тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләрен үстерә ала. Укучылар югарыда күрсәтелгән белем һәм күнекмәләрне камилләштерергә тиеш.

Дәрестән тыш эшчәнлек татар теле, әдәбияты, рәсем, җыр сәнгате, уеннар һәм сәхнә әсәрләре бәйләнештә бирелә. Дәресләр халкыбызның гореф-гадәтләрен, әдәбиятын, мәдәниятын өйрәнүгә нигезләнә.

Укучыларның активлыгын, иҗади эшчәнлеген, кызыксынучанлыгын үстерүгә күнекмәләр формалаштыруга төрле иҗади биремнәр, күнегүләр бирелә, эзләнү методы кулланыла. Программа бер елга исәпләнгән.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең максаты:**

- татар халкының бай әдәбияты үрнәкләре аша татар теленең бөеклегенә инандыру, телне өйрәнү мохитен тудыру, татар телендә аралашырга, үз фикерен белдерергә өйрәтү.
- татар халкының рухи әхлакый сыйфатларын ныклап үзләштерү;

- туган якның тарихы һәм мәдәнияте белән танышу, традицияләрне һәм милли бәйрәмнәрне өйрәнү;
- укучыларда милли үзаң тәрбияләү – халкыбыз тарихын яхшы белүче, милләте белән горурланучы шәхесләр тәрбияләү.
- укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру.

**Бурычлары:**

- укучыларның сүзлек хәзинәсен баету, аралаша белү күнекмәләрен камилләштерү, үзара дустанә хезмәттәшлек булдыру;
- танып-белү эшчәнлеген, иҗади фикерләү сәләтен камилләштерү;
- төркем эчендә эшли, фикерләрне тыңлый белү;
- укучыларны эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә тарту, нәтиҗә ясарга юнәлеш бирү.
- чыгыш ясау, аралашуга өйрәтү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

**Эшчәнлек төрләре:**

- уен эшчәнлеге;
- танып –белү эшчәнлеге;
- әдәби-иҗади эшчәнлек.

**Планлаштырган нәтиҗәләр:**

- татар халык авыз иҗатының жанр төрлелеге белән танышып бару;
- туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү, җырлар, шигъри әсәрләрне өйрәнү;
- сәхнәдә үзеңне иркен тоту, фикереңне әйтә белүне формалаштыру;
- яшьтәшләре, үзләреннән кечеләр, өлкәннәр белән әхлак кагыйдәләренә туры килерлек итеп аралашу;
- әти-әниләргә, өлкәннәргә, үзеңнән кечкенәләргә карата кайгыртучан булу.

Программаны тормышка ашыру барышында укучылар бер-берсе белән аралашырга, төрле мәгълүмат белән эшләргә өйрәнергә, тикшеренү эшләре алып барырга, туган як, татар халкы мәдәнияты, традицияләре турында күбрәк мәгълүмат тупларга тиешләр.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
– «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалаштыру.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Телгә өйрәтү укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар, презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлекнең тәрбияви нәтиҗәләре өч дәрәҗә буенча бүленә.

Нәтиҗәләрнең беренче дәрәҗәсе — укучыларның социаль белем алулары (иҗтимагый нормалар, җәмгыятьнең төзелеше, җәмгыятьтә социаль яктан кабул ителә һәм кабул ителми торган үз-үзеңне тоту формалары һ.б.), социаль чынбарлыкны һәм көндәлек тормышны аңлау.

Нәтиҗәләрнең әлеге дәрәҗәсенә ирешү өчен укучының (аның өчен мөһим булган) уңай социаль белем һәм көндәлек тәҗрибә чыганагы булган шәхесләр — укытучылары белән үзара бәйләнеше зур әһәмияткә ия (нигездә, өстәмә белем бирүдә).

Нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсе — укучының җәмгыятьнең база кыйммәтләренә карата булган борчылуларын һәм позитив мөнәсәбәтләрен (кеше, гаилә, Ватан, табигать, дөнья, белем, хезмәт, мәдәният) алуы.

Нәтиҗәләрнең әлеге дәрәҗәсенә ирешү өчен укучыларның сыйныф, мәктәп дәрәҗәсендә, ягъни дустанә просоциаль тирәлектә аралашулары зур әһәмияткә ия. Нәкъ менә шундый социаль тирәлектә бала үзендә булдырылган социаль белемнәрен практик яктан раслый, аларның кадерен белә башлый.

Нәтиҗәләрнең өченче дәрәҗәсе — укучының мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр тәҗрибәсен алуы. Бары тик мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр вакытында гына, ачык социумдагы эшчәнлегендә, мәктәпнең дустанә тирәлегеннән читтә генә яшь кеше, чынлыкта, социаль хезмәткәр, гражданин, ирекле кеше була ала. Нәкъ менә шундый мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый

гамәлләр нигезендә генә алардан башка гражданинның һәм гражданлык җәмгыятенең яшәешен күз алдына китереп булмаган батырлык, лаеклы эш-гамәлләргә әзер булу кебек тормышта бик кирәкле тәҗрибә алып була.

Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләренең өч дәрәҗәсенә дә ирешү балаларда тәрбия һәм социальләшү эффектлары барлыкка килү мөмкинлеген арттыра.

**Дәрестән тыш эшчәнлек дәрәҗәләре:**

1 нче дәрәҗә: укучы иҗтимагый тормышны белә, аңлый.

2 нче дәрәҗә: укучы иҗтимагый тормышны югары бәяли.

3 нче дәрәҗә: укучы иҗтимагый тормышта мөстәкыйль эшли белә.

**Көтелгән нәтиҗәләрне исәпкә алу формасы:**

- уен эшчәнлеге ( конкурс, викторина);
- әңгәмә ( индивидуаль һәм төркемнәрдә);
- тест үткәрү;
- иҗади эшләр презентациясе.

Сәгатьләр бүленеше.

| № | Тема | Сәг. саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Программа белән таныштыру. | 1 |
| 2 | ***Халкыбызның күңел җәүһәрләре***<br>Балалар фольклоры. | 5 |
| 3 | ***Җырсыз кеше — канатсыз кош.***<br>Татар җырлары | 1 |
| 4 | **Без – яшь артистлар**<br>Сәхнә серләренә өйрәнү | 11 |
| 5 | **Татар халык ашлары** | 1 |
| 6 | Татарча балалар журналларына күзәтү. | 2 |
| 7 | Татар халкының милли бәйрәмнәре | 4 |
| 8 | **Г.Тукайның сәхнә әсәрләре** | 3 |
| 9 | **Татар телевидениесе** | 2 |
| 10 | Иҗади эшләргә корылган дәресләр | 5 |
| 11 | Йомгаклау | 1 |
| | Барлыгы | 35 |

**Программаның эчтәлеге**

Кереш дәрес. Программа белән таныштыру.

Балалар фольклоры.

Балалар фольклоры турында төшенчә бирү. Тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар, мәзәкләр, әкиятләр.

Татар җырлары.

Татар җырлары белән танышу. Җырлар өйрәнү.

Без - яшь артистлар. Сәхнә серләренә өйрәнү. Әсәрләрне сәхнәләштерү.

Татар халкының милли ашлары.

Татар халкының милли ашлары турында әңгәмә оештыру. Табын әдәпләре. Кунак чакыру, кунакка бару.
Татар халык бәйрәмнәре.
Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү.“Нәүрүз”, “Сабантуй”, “Карга бәйрәме” бәйрәмнәре.
Татар халык биюләре.
Татар халкының биюләре белән таныштыру.
Татарча балалар журналларына күзәтү.
“Ялкын”, “Салават күпере” һ.б. журналлар белән таныштыру. Әсәрләр уку.
Татар телевидениесе.
Татар телевидениесе турында әңгәмә оештыру. Татарча тапшырулар турында мәгълүмат бирү. Иҗади эшләргә корылган дәресләр бәйрәмнәр үткәрүгә, яисә эзләнү, тикшеренү эшен оештыруга бирелә.

**Календарь – тематик план**

| № | Тема | Сәг. саны | Уку эшчәнлеген оештыру формалары һәм төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | план | факт |
| 1 | Кереш дәрес. Программа белән таныштыру. | 1 | Лекция, әңгәмә | | |
| 2-5 | **Балалар фольклоры.** Табышмаклар. Санамышлар. Тизәйткечләр. Мәзәкләр. “Елмайыйк, көлик әле!” | 4 | Презентация, аудиоязмалар тыңлау. Санамышлар, табышмаклар, балалар уеннары җыю, рәсемле китапчык ясау, “Халык авыз иҗаты” уен-ярышын үткәрү | | |
| 6 | Татар халык әкиятләре. “Әкият сөйлим, тыңлагыз!” | 1 | Аудиоязмалар тыңлау, әңгәмә | | |
| 7 | Без җырлар яратабыз. “Җырлап ачыла күңел!” Балалар өчен җырлар. | 1 | Җырлар тыңлау, кушылып җырлау, сүзләрне өйрәнү | | |
| 8 | **Сәхнә серләре.** Видеоязмалар карау. | 1 | Видеоязмалар карау, сәхнәләштерү серләрен аңлату | | |
| 9-10 | Г.Гыйльман “Шүрәлеләр ни атлы?” пьесасын сәхнәләштерү | 2 | Видеоязмалар карау . Рольләргә бүлеп уку. | | |
| 11-12 | Г.Гыйльман “Шүрәлеләр ни атлы?” пьесасын сәхнәләштерү | 2 | Сүзләрне өйрәнү | | |
| 13-14 | Г.Гыйльман “Шүрәлеләр ни атлы?” пьесасын сәхнәләштерү | 2 | Спектакльне кабатлау. Музыка сайлау.Декорация, киемнәр әзерләү. Чыгыш ясау | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Курчак театрына виртуаль сәяхәт. | 1 | Презентация, әңгәмә | | |
| 16-17 | Татар халык биюе (кызлар өчен). Татар халык биюе (малайлар өчен). | 2 | Бию элементларын кабатлау, көйгә басу | | |
| 18 | Татар халкының милли ашлары. “Ашыгыз тәмле булсын!” | 1 | Презентация, милли ризык-лар белән танышу. Милли ризыклар белән чәй эчү | | |
| 19-20 | Татарча балалар журналларына күзәтү (“Ялкын”, “Салават күпере”). | 2 | Әңгәмә, сорау -җавап “Татмедиа” тарафыннан оештырылган чарада катнашу | | |
| 21 | “Тамчы – шоу”уены | 1 | Презентация, чыгыш ясау | | |
| 22 | Татар халкының милли бәйрәмнәре | 1 | Презентация, әңгәмә | | |
| 23-24 | “Нәүрүз” , “Карга боткасы”, “Сабантуй” бәйрәмнәре. | 2 | Бәйрәмнәр турында мәгълүмат бирү | | |
| 25 | “Җиде буын бабаңны бел” | 1 | Шәҗәрә турында мәгълүмат бирү | | |
| 26 | Дәрес-проект. Шәҗәрә төзү | 1 | Чыгыш ясау | | |
| 27-28 | Габдулла Тукай әкиятләре һәм шигырьләрен сәхнә-ләштерү (“Сабыйга”, ”Бала белән күбәләк”, “Шүрәле”, “Су анасы”һ.б.) | 2 | Укучылар үзләре сайлап алган әкиятне, шигырьне сәхнәләштерергә әзерләнә. | | |
| 29 | Г.Тукайның тормыш юлы, иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрү | 1 | Г.Тукайның шигырьләрен сөйләү, җырларын башкару, сәхнәләштерү | | |
| 30 -31 | Бүгенге көн телевидение-се. Татарча тапшырулар | 2 | “Шаян ТВ” тапшырулары турында әңгәмә | | |
| 32-33 | Проектлар яклау. Рефератлар, докладлар белән чыгыш ясау. | 2 | Чыгыш ясау | | |
| 34 | Викторина “Татар теле дөньясында” | 1 | Презентация, сорау-җавап | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 35 | Йомгаклау дәресе. | 1 | Әңгәмә , табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре Милли ризыклар белән чәй эчү | | |

## “Татар халкының җырлы – уенлы иҗаты”
## Дәрестән тыш эшчәнлек программасы
## (1нче сыйныф өчен)

*Бикмөхәмәтова Ләйлә Зөлфәтовна, Казан шәһәре Идел буе районы «6 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Совет районы мәгариф бүлегенең милли мәсьәләләр методисты*

### Аңлатма язуы

“Татар халкының җырлы – уенлы иҗаты ” рухи –әхлакый һәм эстетик – сәнгать юнәлешләрен исәпкә алган дәрестән тыш эшчәнлек программасы булып тора. Дәрестән тыш эшчәнлек гомумдидактик принципларга нигезләнеп оештырыла: максатчанлык, фәннилек, системалылык, эзлеклелек, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләре, балаларның мөстәкыйльлелеге һәм иҗади активлыгы, тормыш белән бәйлелек саклана.

Балага рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирүнең төп документаль нигезен Россия Федерациясенең “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Законы, федераль дәүләт белем стандартлары, Россия гражданинына рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирү Концепциясе тәшкил итә. Стандартта мондый юллар бар: “Гомуми белем бирүнең башлангыч баскычында рухи-әхлакый яктан үстерү һәм тәрбия бирүнең төп максаты булып Ватан язмышын үз язмышы итеп кабул итүче, үз иленең бүгенгесе һәм киләчәге өчен җаваплылыгын аңлаучы, күпмилләтле Россия Федерациясе халыкларының рухи һәм мәдәни гореф-гадәтләре үрнәгендә тәрбияләнгән югары әхлаклы, иҗади, белемле Россия гражданинын тәрбияләү тора.” Стандарт таләпләренә туры китереп, рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирү Программасы һәм Концепция, башлангыч гомуми белем бирүнең барлык бүлекләрен формалаштыруда төп юнәлеш булып тора.

1 нче сыйныф өчен дәрестән тыш эш программасы татар халык авыз иҗаты төрләрен, аларның яшь үзенчәлегенә туры килерлек үрнәкләрен үз эченә ала. Бу темалар балаларның телне үзләштерү дәрәҗәсенә туры килерлек итеп, метапредмет бәйләнешләрне, уку процессындагы логик эзлеклелекне искә алып сайланган һәм сәгатьләргә бүленгән. Программа атнага 1 сәгать исәбеннән елга 30 сәгать каралган.

Халык авыз иҗаты баланы сәнгать дөньясына җәлеп итү, халыкның традицияләре белән таныштыру өчен иң кулай материал булып кына калмый, үз үзеңне җәмгыятьтә әдәпле, әхлаклы тоту нормалары да, эстетик кыйммәтләргә уңай караш тудыруда да зур ярдәм итә. Туган халык авыз иҗаты әсәрләре баланы бишектән алып озатып килсә, күрше халык иҗаты үрнәкләре аңа дөньяны танып белергә, толерант шәхес булып формалашырга зур ярдәм итә.

Белем бирү процессын халыкның күпьеллык традицияләренә нигезләнеп кору бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрдән санала, чөнки халык җырлары, экиятләре, уеннары, мәкаль һәм әйтемнәре баланың рухи-эстетик үсешендә төп рольне уйный, тормышны аңлауда һәм аңа яраклашуда зур ярдәм итә. Курсның актуальлеге һәм социаль әһәмияте шунда – ул үсеп баручы яшь буынга кешеләр арасында үзара дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыруны аңлап, үз-үзеңне тәрбияләү һәм үсеш юлларын эзләүгә юнәлтелгән. Курс иҗади процесска укучыларны, әти-әниләрне, укытучы һәм тәрбиячеләрне катнаштыруны күз алдында тота.

Бирелгән курсның практик әһәмияте шунда – әйләнә-тирә чынбарлыкка дөрес караш укытучы һәм укучының уртак эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә, ә әхлаклылык нормалары 1 нче сыйныфтан үстерелә башлый.

**Программаның максаты**: халык авыз иҗаты әсәрләре, җырлы - уенлы үрнәкләрен өйрәнеп, укучыларның интеллект дәрәҗәсен үстерү, тормышка яраклашкан (социальләшкән) шәхес тәрбияләү.

Бу максатка бәйле рәвештә түбәндәге **бурычлар** куелды:
татар халык авыз иҗаты тарихы, жанрлары, халыкның милли киемнәре белән танышу; халык традицияләренә, костюмына, милли мирасына кызыксыну хисләре, хөрмәт уяту; балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

Программаны тормышка ашыру барышында парларда, төркемдә һәм коллективта эшләү формалары кулланыла. Бу формалар аралашу сәләтен үстерү өчен файдалы.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең төп юнәлешләре:**

- гомуминтеллектуаль;
- гомумимәдәни;
- рухи-әхлакый.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең эш төре:**

- уен.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең эш формасы:**

- түгәрәк.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең планлаштырылган нәтиҗәләре:**

- халык акылы, тормыш яме, яшәү көче чыганагы булган халык авыз иҗаты турында мәгълүматлы булу;
- әсәрләрнең жанрын аера белү;
- экият, легендаларның эчтәлеген сөйли белү;
- халык җырларын, биюләре элементларын белү;
- сөйләмдә мәкаль-әйтемнәр кулланырга өйрәнү;
- халык уеннарын өйрәнү.
- татар телендә кечкенә әсәрләрне сәхнәләштерү.
- төркемдә партнер белән эшли белү

**Планлаштырылган нәтиҗәләрнең дәрәҗәсе**

**1 нче дәрәҗә**: мәктәп укучысы тарафыннан социаль белемне алу, социаль чынбарлыкны һәм көндәлек тормышны аңлау.

**2 нче дәрәҗә**: мәктәпнең, җәмгыятьнең төп кыйммәтләренә (кеше, гаилә, Ватан, табигать, дөнья, белем, хезмәт, мәдәният), тулаем чынбарлыкка карата тирән уйлану һәм уңай караш тәҗрибәсен алу.

**3 нче дәрәҗә**: мәктәп укучысы мөстәкыйль рәвештә иҗтимагый эш тәҗрибәсен үзе куллана белүе.

Эш барышында 1нче сыйныф балаларының яшь үзенчәлекләренә туры килә торган төрләргә зуррак урын бирү күздә тотылды. Бу – уеннар, җырлар элементлары белән танышу, рәсемнәрен ясау, табышмаклар өйрәнү, иҗат итү.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата хөрмәт карашы булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый-тәрбия кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- текстлардагы төрле тормыш вакыйгаларына һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек», «игелеклелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата сабырлылык, кайгыртучанлык», «якын кешенең кадерен белү» кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Урта белем бирү баскычында телгә өйрәтү, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда информацион җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләрне булдыру. Укучылар, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәтү.

***Танып белү нәтиҗәләре***:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

***Регулятив нәтиҗәләр***:

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, укуэшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.

***Коммуникатив нәтиҗәләр***:

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;

- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Курсның предмет нәтиҗәләре**

**Тыңлап аңлау:**

- төрле жанрдагы халык авыз иҗаты әсәрләрен тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;
- сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;
- зур булмаган адаптацияләнгән халык авыз иҗаты әсәрләреннән өзекләрне, тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;
- сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

**Диалогик сөйләм:**

- сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;
- парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау бирееп, сөйләм барышын ачыклый белү.

**Монологик сөйләм:**

- халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәгендә экиятләр,табышмаклар һ.б. төзи алу һәм аның эчтәлеген сөйли белү;
- конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү.

**Календарь – тематик план**

| № | Өйрәнелә торган бүлек, укыту материалы темасы | Сәгать-ләр саны | Үткәрү вакы-ты | Факт вакыт | Укучының эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дәрестән тыш чара “ Бу кем? \ Син кем?” җыры. | 1 | | | Татар телендә авазлар , җыр сүз-ләре белән башкару, “Бастыру машинкасы” уены (рухи –әхла-кый юнәлеш) |
| 2-4 | Татар халык уенлы җыры ”Кәрия-Зәкәрия”. Сөмбелә бәйрәме | 3 | | | Җырлы уенны бергәләп җырлау. Рәсем ясау. Табышмаклар әйтешү. Парларда эшләү. Түгәрәк әйләнү уены |
| 5-6 | Кечкенә музыкаль әсәрне сәхнәләштерү “Бер, ике, өч...” җыры | 2 | | | Җырны бергәләп, парларда җыр-лау. Образга кереп җырлау. “Бастыру машинкасы” уены |
| 7-8 | Татар халык авыз иҗаты. “Бармак” уены “Хәзер мин аю...”җыры. | 2 | | | Җырны хәрәкәтләр белән башка-ру. Парларда,төркемнәрдә эшләү, образга кереп, жестлар белән җыр-лау. (гомуми мәдәни юнәлеш) |
| 9-11 | Татар халык уеннары Уен дәресе “Исәнләшү” җыры. | 3 | | | Диалогик сөйләм оештыру, рәсем буенча эш, әңгәмә.“Бастыру машинкасы” уены |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12-14 | Хәрәкәтле уен “Туп белән куышу”. Уенлы – җыр “Чыршы”. Әхмәт Ерикәй | 1 | | | Диалогик сөйләм оештыру, рәсем буенча эш, әңгәмә. Шигырьне сәнгатьле уку.(гомуми мәдәни юнәлеш) |
| 15-16 | Шигырь конкурсы “Безнең бакча” шигыре. Резеда Валиева. | 2 | | | Шигырьне сәнгатьле уку. Тыңлау, әңгәмә, үрнәк буенча эш.(рухи - әхлакый юнәлеш) |
| 17-18 | “Күрсәт әле үскәнем” уен җырын өйрәнү. Башкорт халык уены “Буяу сатыш”. | 2 | | | Җырны төрле хәрәкәтләр белән башкару. Рәсемнәр буенча эшләү, парлап һәм төркемнәрдә эшләү. “Лото” һәм “Домино” уены (лексик уен) |
| 19-20 | Б. Рәхмәт “Ю,ю,ю” шигыре. Татар халык хәрәкәтле уены “Яшелчәләр”. | 2 | | | Шигырьне сәнгатьле уку, уен оештыру. |
| 21 | Иҗади эш “Әниемә булышам” җыры. Лиана Әмирханова | 1 | | | Рәсем буенча эш, үрнәк буенча сөйләү. (гомуми мәдәни юнәлеш) |
| 22-23 | Халык авыз иҗаты. Китапханәгә экскурсия. “Карга боткасына сый җыйганда”. | 2 | | | Тыңлау, рәсем буенча эш, виртуаль экскурсия (рухи - әхлакый юнәлеш) |
| 24 | Шагыйрьләрнең шигырьләренә рәсем конкурсы “Зарядкага бас” шигыре.Гөлфия Юнысова“Яратам” шигыре. | 1 | | | Төрле зарядка күнегүләре белән уен оештыру. “Бастыру машинкасы” уены (сәламәтләндерү юнәлеше) |
| 25-27 | Татар халык әкиятен, рольләргә бүлү, сәхнәләштерү.“Төлке белән торна”. | 3 | | | Әкиятне рольләп уйнау, сәхнәләштерү (гомуми мәдәни юнәлеш) |
| 28 | Тәрбия сәгате “Бер әби” тексты. | 1 | | | Үрнәк буенча сөйләү, рольләргә бүленеп сәнгатьле образга кереп уку. |
| 29-30 | Нәүрүз бәйрәме күренешен оештыру. Татар халык уены “Очты, очты...” | 2 | | | Парлап эшләү. Җырны төрле хәрәкәтләр белән башкару “Бармак уены”. Төркемдә эшләү. Яз көненә багышланган уеннар. |

**Дәрестән тыш эшчәнлек курсын үткән укучының**
**метапредмет нәтиҗәләреннән чыгып аналитик анализ бирү картасы**
**Ф.И.__________________, ________сыйныф укучысы**
**(1 балл билгеләнә)**

| Метапредмет нәтиҗәләре | Әйе | Юк |
|---|---|---|
| Укучының югары мотивациясе булу. | | |
| Максатына ирешүгә омтыла. | | |
| Күзәтүчәнлек алымын куллана. | | |
| Бәяләмә бирә белә. | | |
| Укытучы белән төрле мәсьәләрне чишә. | | |
| Эш дәверендә үзен башка укучылар арасында ярдәмчеллек, хөрмәт итү сыйфатлары белән аерыла. | | |
| Үзенең эшен башка укучы нәтиҗәләре белән чагыштыра белә. | | |
| Узенең эшчәнлегендәге уңышлы һәм уңышсыз сәбәпләрен аңлый белә. | | |
| Коллективта үзен иркен һәм кыю тота белә. | | |
| Сәнгатьле әсәрләрдән үзенең хис - кичерешләрен аңлата белә. | | |
| Әңгәмә – диалогларда катнаша. | | |

**Әгәр дә укучының балл саны:**

- 10-11 балл - аның метапредмет нәтиҗәләре иң югары дәрәҗәдә.
- 7-8 балл – уртача дәрәҗәдә. Эш барышында бу укучыга игътибарны күбрәк җәлеп итәргә кирәк.
- 5-6 балл – түбән дәрәҗәдә. Укытучыга бу укучының нәтиҗәләрен югары күтәрү өчен икенче елга индивидуаль эш төрен уйларга кирәк булачак.

**Ирешелгән нәтиҗәләр.**

Берничә ел рәттән гимназия укучыларының халык иҗатының аз мәгълүматлы булуларын, аларның тәртибен, бер-берсенә мөнәсәбәтен, үзара сөйләшүләрен күзәткәннән соң, программаның бик кирәк булуына инандым. Бер караганда, гимназиядә татар балалары да укый. Ә татар гаиләләрендә тәрбия мәсәләсе төрлечә куелган. Балаларны тәрбияләүдә, гореф – гадәтләрне өйрәтүдә әби-бабайларның да өлеше зур. Шулай да, хезмәткә тәрбия, иптәшләреңә ярдәмчеллек, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү кебек сыйфатларны мәктәп тә үз өстенә алырга тиеш дип саныйм. Программа 1 нче сыйныф укучыларына эстетик зәвык, интеллект өлкәсендә иң мөһим кагыйдәләр белән танышырга һәм тормышта кулланырга мөмкинлек бирде.

Программаның иң отышлы якларыннан берсе – җырлы - уен формасында оештырылган булуы. Теоретик характердагы барлык информация балалар теманың сорауларына үзләре җаваплар эзләп табарлык уен формасында бирелә. Балалар үзләштерергә тиешле җырлы - уеннарның асылында зурларның тормышы, көнкүреше һәм хезмәтенең бер чагылышы булып тора. Димәк, балалар уены дигәндә, кешелек җәмгыятенә физик һәм мораль-эстетик яктан тәрбияле, киләчәк тормышка әзерләү функциясен үтәүче күңелле һәм мавыктыргыч чаралар системасын оештырдым.

Чараларда эш парлап һәм төркемнәргә бүленеп оештырылды. Төркем эчендә бала үзен иркен тота, уйлаганын әйтергә кыенсынмый. Җавабының дөреслеген, иптәшләренеке белән чагыштыргач белә. Хаталанудан да курыкмый ул, чөнки моның өчен аны беркем дә "хөкем" итми. Бер-береңне кимсетү, үзеңне башкалардан өстен кую турында укытучы тарафыннан беренче дәрестә үк аңлатыла. Төркемдә эшләгәндә ул үз фикерен башлап иптәшләре алдында әйтә ала. Төркемнәрдә эшләп, балалар игътибарлы, ихтирамлы булырга, бер-берсен тыңларга, юл куя белергә, үз-үзләрен хөрмәт итәргә өйрәнәләр.

Программаны үзләштергән укучылар рухи – әхлакый, эстетик якларны гына түгел, мораль нормаларын һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, гаилә әгъзалары, өлкән буын вәкилләре арасында булырга тиешле нормаларны да үзләштерделәр. Татар халкының җырлы – уенлы чараларында алган күнекмәләр шәхеснең үсешенә уңай йогынты ясый, аны тормышка әзерли. Кешенең тормышы мәктәп белән генә чикләнми. Аңа урамда, кунакта, театр-кичәләрдә һәм башка урыннарда булырга туры килә. Җәмәгать урыннарында, кешеләр белән аралашканда һәм, гомумән, тормышта әлеге программа балаларга зур ярдәмче булыр дип ышанам.

**Кулланылган әдәбият**

*Укытучы өчен:*

1. Косачева, И.П. Нравственное развитие младшего школьника в процессе обучения и воспитания / И.П.Косачева. – М.: Издательство АРКТИ, 2005.–62с.

2. Савинов Е.С. Стандарт второго поколения. Примерная основная образовательная программа образовательного учреждения. Начальная школа. – М.: Просвещение, 2011.

3. Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. Мәгърифәт-мәңгелек юлдаш (гыйлем-тәрбиядәресләре) / Хуҗиәхмәтов Ә.Н.- К: ТаРих, 2002.

4. Казыйханов В.С. Әхлак дәресләре / В.С.Казыйханов.- Яр Чаллы:1998. – 240 б.

*Укучыларга:*

1. Лихачева Л.С. Уроки этикета в рассказах, картинках и задачках/ Л. С. Лихачева . – Екатеринбург : Уральское изд-во, 2011 . – 318 с.

2. С. Сәүбанова. Өр – яңа экиятләр. – Казан: "Гыйлем" нәшрияты, 2016. – 232 б.

3. Т.Шакирова. Тукай иленә сәяхәт-Путешествие в мир Тукая/ Т.Шакирова, Г.Хәйдарова. – Казан: Татар. кит. нәшр.; 2012. – 127 б.

4. Зарипова К.М. Балалар риторикасы/К.М.Зарипова. - Казан. "Мәгариф" нәшрияты.2005.–80 б.

**Интернет-ресурслар:**

1. Сайт Министерства образования и науки Республики Татарстан http://mon. tatar. Ru
2. http://www. km. ru – портал компании «Кирилл и Мефодий».
3. Детский портал «Солнышко» http://www. solnet. ee/
4. Сайт http://balarf.ru/
5. Сайт https://belem.ru/
6. Сайт «Учительской газеты» http://www. ug. ru/
7. Сайт «Все о детях и семье» http://www.7ya. ru/
8. Фестиваль педагогических идей «Открытый урок» http://festival.1september. ru/

# «Музей фәннәре мәктәбе»
# дәрестән тыш эшчәнлек буенча эш программасы (5-9 нчы сыйныфлар)

*Фәттахова Гөлшат Шәйхетдин кызы, Әхмәтгалиева Алсу Әсхадулла кызы,*
*Казан шәһәре Совет районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 171 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе»нең туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## Аңлатма язуы

«Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлегенең эш программасы 5-9 нчы сыйныф укучыларының укыту процессы белән идарә итү, планлаштыру, оештыру, коррекцияләү максаты белән төзелгән.

Әлеге программа стандарт таләпләренә туры китереп, рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирү программасы һәм концепция, төп гомуми белем бирүнең барлык бүлекләрен формалаштыруда төп юнәлеш булып тора.

«Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлек курсы буенча әлеге эш программасы укучыларда музей эшчәнлегенә кызыксыну формалаштыру; музей дөньясына сәяхәт аркылы танып-белүгә шартлар тудыру; укучыларның иҗади үсешенә һәм эстетик зәвыгын формалаштыруга ярдәм итү. Бу максатка бәйле рәвештә түбәндәге бурычлар куелды:

– төрле типтагы музейларга карата танып-белү кызыксынуын формалаштыру, сәяхәткә, музейга даими йөрүгә ихтыяҗ тудыру;

– төрле коллекцияләрне һәм аларны җыю ысулларын чагыштыру сәләтен формалаштыру;

- укучыларның фәнни-тикшеренү потенциалын үстерү;

- музей, музей экспонаты, уку кирәк-яракларын мәгълүмат чыганагы буларак күзаллауларны киңәйтү;

- алга куелган бурычлар һәм аларны тормышка ашыру шартлары нигезендә мәгълүмат белән эшләүнең төрле ысулларын куллану һәм танып-белү универсаль уку гамәлләрен үстерерү;

– матди һәм рухи кыйммәтләргә сакчыл караш тәрбияләү;

- музей этикасын формалаштыру.

Программаны эшләү һәм белем бирү процессына кертү кирәклеген нигезләү

Музей – үткән белән бүгенгене бәйләгән, киләчәккә юл салган, тарихи һәйкәлләрне саклаган изге урын, рухи азык биргән мәдәни учак ул. Анда тупланган экспонатлар, материаллар үткәннәрнең истәлеген саклый. Музей эшчәнлеге тарихны һәм халыкның йөзен, яшәешен чагылдырган экспонатларны җыю, саклау һәм мирас итеп киләсе буыннарга тапшырудан тора да инде.

"Музей фәннәре мәктәбе" эш программасының актуальлеге түбәндәге функцияләргә бәйле:

– балалар җитди һөнәри юнәлеш бирүче белем алачак;

– без тарих өчен документлар, мөһим әйберләр саклап кала алачакбыз. Кайбер әйберләр бик начар саклана һәм никадәр тизрәк алар музей хезмәткәрләренең кулына

эләксә - шулкадәр яхшырак. Бу проект ярдәмендә һәвәскәрләр дәрәҗәсендәге балалар көче белән без кайбер предметларның тарих өчен сакланып калачагын төгәл беләбез;
– балаларның тарих белән кызыксыну дәрәҗәсен арттырачак, бу аларның өлгерешенә уңай йогынты ясаячак.

**«Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлек курсының уку планында урыны**

Әлеге программа 5-9 сыйныфларда тормышка ашыру өчен атнага 1 сәгать исәбеннән билгеләнгән. Һәр сыйныфта сәгатьләрнең түбәндәге саны карала:
5 нче сыйныфта 35 атна исәбеннән (атнага 1 сәгать) 35 сәгать,
6 нчы сыйныфта 35 атна исәбеннән (атнага 1 сәгать) 35 сәгать,
7 нче сыйныфта 35 атна исәбеннән (атнага 1 сәгать) 35 сәгать,
8 нче сыйныфта 35 атна исәбеннән (атнага 1 сәгать) 35 сәгать,
9 нчы сыйныфта 34 атна исәбеннән (атнага 1 сәгать) 34 сәгать каралган.

Барысы: 174 сәгать.

**Эшчәнлек формасы:**

Түгәрәк яки клуб

**Укучылар эшчәнлеге төрләре:**

1. Танып- белү эшчәнлеге;
2. Туризм һәм туган якны өйрәнү эшчәнлеге

**Укыту методы һәм алымнары:**

1. Аңлату (телдән) – киләчәктә уку, өйрәнү өчен кирәкле мәгълүматларны тапшыру.
2. Күрсәтү-төрле видеофильмнар, презентацияләр, картиналар, экспозицияләр карау; музей күргәзмәләрендә, театрларда булу.
3. Эзләнү- бирелгән тема буенча мәгълүматлар җыю.
4. Тикшеренү- интеллектуаль, танып-белү эшчәнлеген үстерү максатыннан музей фондында тупланган документаль һәм башка шундый әйберләрнең тарихын өйрәнү, тикшерү.
5. Экскурсияләр методы.
6. ИКТ куллану.
7. Проектлар методы.

Әлеге эш программасы 5 ел дәвамында тормышка ашырылачак. Ул биш ел дәвамында теоретик һәм практик дәресләрне дә, мәктәп музее экспозицияләре буенча тематик һәм күзәтү экскурсияләрен дә, мәктәп музее базасында класстан тыш чаралар оештыруны да күздә тота.

Программа эзләү эшен оештыру, тикшеренү эшчәнлеге, аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм тәкъдим итү, ачык чыгышлар әзерләү буенча индивидуаль һәм төркем дәресләрен үз эченә ала.

Программаның эчтәлеге түбәндәгечә төзелгән:

- 5 сыйныф – «Исәнме, музей!»
- 6 сыйныф – «Минем гаиләм-минем Россия»
- 7 сыйныф – «Яшь музей хезмәткәрләре»
- 8 сыйныф – «Мин-экскурсовод»

– 9 сыйныф – «Чиксез музей»

Төркемгә җыелу ирекле. Төркемдә 10-15 укучы булырга мөмкин, чөнки нәтиҗәлелек яхшырак була. Белем бирү процессы балаларның яшь, психологик мөмкинлекләре һәм үзенчәлекләре нигезендә төзелә, бу исә дәресләрнең вакытын һәм режимын үзгәртүне күздә тота.

**Программаны тормышка ашыру шартлары.**

Программа балаларга бирелә торган белемнәрнең күләмен күзаллап, зур матди-техник база күздә тотыла; программа буенча нәтиҗәле эшчәнлек алып бару өчен кирәк:

Музейның төп һәм фәнни-ярдәмче фондлары;

Туган якны өйрәнү һәм тарихи әдәбият китапханәсе;

Экскурсияләр төзү өчен материаллар;

Вакытлы матбугат материаллары;

Аппаратура: магнитофон, видеомагнитофон, телевизор, диктофон, фотоаппарат, аудио һәм видеокассетлар.

Санитар-гигиена таләпләренә җавап бирүче бүлмә, җиһазлар.

**«Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлек курсы буенча эш программасы түбәндәге бүлекләрдән тора:**

– «Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлекне үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;

– «Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлек курсының эчтәлеге;

– тематик планлаштыру.

**«Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлекне үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

***Планлаштырылган нәтиҗәләр:***

-социаль, укыту - танып-белү һәм тышкы мотивларны үз эченә алган проект-иҗат эшчәнлегенең мотивацион нигезе ;

- гамәли иҗади эшнең яңа төрләре, үз-үзеңне күрсәтүнең яңа ысуллары белән кызыксыну;

- технологияләрне һәм материалларны өйрәнүнең яңа ысулларына кызыксыну уяту;

- иҗади эшчәнлекнең уңышлылыгы һәм уңышсызлыгы сәбәпләрен адекват аңлау.

***Укучы түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге ала:***

-укучының эчке позициясе иҗади эшчәнлекнең кирәклеген аңлау дәрәҗәсендә, социаль тормышта үз-үзләрен күрсәтү чараларының бер өлеше булып торуын аңлау;

- белемнең яңа ысулларын өйрәнүгә тотрыклы кызыксыну;

- иҗади эшчәнлекнең уңышлылыгы һәм уңышсызлыгы сәбәпләрен адекват аңлау.

**Регулятив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнә:**

- үзләштерелгән белән таныш булмаганны чагыштырып, хәл ителергә тиешле уку бурычын куярга;

- соңгы нәтиҗәне күз алдында тортып, ике арадагы максатларның эзлеклелеген билгеләргә;

- эш тәртибен билгеләргә;
- көтелгән нәтиҗәне сиземләргә;
- эшнең планын төзергә;
- йомгаклау һәм адымлы контроль ясарга;
- укытучының бәясен адекват кабул итәргә;
- көч һәм энергияне туплау, ихтыяр көче кую (дәлилләр бәрелеше булган очракта кирәклесен сайлау), каршылыкларны җиңеп чыгу сәләтенә ия булырга.

**Коммуникатив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнә:**

- төрле карашлар һәм куелган иҗади бурычны үтәүнең төрле вариантлары булуны кабул итәргә;
- төрле фикерләрне исәпкә алырга, күмәк эшләрне башкарганда координацияләргә омтылырга;
- үз фикереңне үз фикереңне һәм позицияңне тулы, төгәл итеп әйтә белергә;
- килешергә, уртак карарга килергә, конфликтларны чишәргә;
- информация эзләү, туплау өчен мөхим сораулар бирергә;
- укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлекне планлаштырырга;
- әңгәмәдәшнең тәртибенә җитәкчелек итәргә;

**Танып белүнең универсаль гамәлләре:**

**Укучы өйрәнә:**

- өстәмә әдәбиятны, компьютер чараларын кулланып, кирәкле информацияне эзләп табарга;
- танып белү максатын мөстәкыйль рәвештә аерып алу һәм әйтеп бирергә;
- белемнәрне структуралау, ягъни тәртипкә салырга;
- уй-фикерне сөйләмә һәм язма формада аңлап һәм ирекле оештырырга;
- бурычларны үтәүнең нәтиҗәле ысулларын сайларга;
- рефлексия – эш-хәрәкәтләрнең алымнарын һәм шартларын, эшчәнлекнең барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп барырга;
- текст укуның максатын аңлап һәм уку төрен шул максаттан чыгып сайлау нәтиҗәсендә аңлап укуга ирешергә;

Танып белүнең универсаль гамәлләре арасында аерым бер төркем – тамга-символик гамәлләр бар:

- модельләштерү;
- әзер модельне үзгәртү.

**Логик универсаль уку гамәлләре:**

- анализ – төп һәм мөһим булмаган билгеләрен аерып алу өчен, объектны тикшерү;
- синтез – аерым кисәкләрдән бер бөтен төзү, кирәк булганда, җитмәгән компонентлар өстәү;
- объектларны чагыштыру, төркемләү өчен нигез һәм критерийлар сайлый белү;
- төшенчәгә китереп җиткерү, нәтиҗә чыгару;
- сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләрне ачыклау;
- фикер йөртүнең логик чылбырын тезү;

- исбатлау;
- гипотеза әйтү һәм аны дәлилләү.

**Проблема кую һәм аны чишү:**

- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- иҗатка һәм эзләнүгә корылган проблемаларның чишелеш алымнарын мөстәкыйль табу.

**Тәкъдим ителгән программа буенча укучылар мөмкинлек алалар:**

- Образлы фикерләүне, акылны, фантазияне, техник фикерләүне, конструкторлык сәләтен үстерү, танып-белү мәнфәгатьләрен формалаштыру;
- Традицион һәм заманча материаллар турында белемнәрне һәм күзаллауларны киңәйтү;
- Материалның килеп чыгу тарихы, аның заманча төрләре һәм куллану өлкәләре белән танышу;
- Төрле материалларны эшкәртүнең яңа технологик алымнары белән танышу;
- Яңа комбинацияләрдә һәм бәйләнешләрдә элек өйрәнелгән алымнарны куллану;
- Коллективта хезмәт эшчәнлеге күнекмәләрен камилләштерү: яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралаша белү, башкаларга ярдәм итә белү, төрле рольләрне кабул итү, әйләнә-тирәдәгеләрнең һәм үзләренең эшчәнлеген бәяли белү;
- Универсаль уку гамәлләре системасын формалаштыру;
- Мәгълүмат белән эшләү күнекмәләрен формалаштыру.
- Һәр дәрәҗә өчен оптималь үсешкә ирешү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- Ватанга, Ватаныбызның мәдәни-тарихи мирасына, дәүләт символикасына, рус һәм туган телгә, халык традицияләренә карата хөрмәт уяту;
- ил тарихының иң әһәмиятле сәхифәләре һәм кече Ватаныбызның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру.

## «МУЗЕЙ ФӘННӘРЕ МӘКТӘБЕ»
## ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК КУРСЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

**5 сыйныф – «Исәнме, музей!» (35 сәгать)**

Музей турында төшенчә. Музей эше тарихы. Музейларның төре һәм профиле. Музейларның барлыкка килү сәбәпләре, формалашуы һәм музей эшен оештыру. Компьютер техникасы үсеше белән виртуаль музейлар барлыкка килүе. Минем шәһәрем Казан. Рәсем конкурсы. Туган шәһәр турында хикәяләр. Фотографияләр конкурсы. Татарстан башкаласы турында әңгәмә.

Казан шәһәренең иң танылган һәйкәлләре. Бөек Ватан сугышы геройларын искә алу мемориалы. Муса Җәлил Һәйкәле. Казан сакчыларына гыйбадәтханә. Габдулла Тукайга һәйкәл. Ф.И. Шаляпинга һәйкәл. Зилант. Казан мәчесе. Екатерина II каретасы. Казан шәһәре һәйкәлләре турында хикәяләр төзү. Казан шәһәре урамнарының исемнәре тарихы. Ваһапов, Сахаров, Глушко биографияләре. Казан шәһәренең архитектура һәйкәлләре. Казан шәһәренең истәлекле урыннары. Кремль-Казанның төп истәлекле урыны. Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете, Губернатор сарае, Благовещение соборы, Спас манарасы һәм башкалар.

Кол Шәриф мәчете Казанның төп дини урыны булып тора.

Юбилей аркасы (Кызыл капкалар) - Петров исемендәге парк ансамбленә керүче мемориаль корылма. Интернет белән эшләү, мәгълүмат эзләү. Казан буенча виртуаль экскурсия. Казан буенча экскурсия маршрутын төзү. Гамәли дәресләр.

Казанның күренекле кешеләре. Мәктәп музеенда. Музейда куркынычсызлык нигезләре. Х.М. Мөштәри мәктәп музей-кабинетына экскурсия. Р. Ваһапов исемендәге мәктәп музей-кабинетына экскурсия. Казан шәһәре музейлары. Уенчыклар музеена экскурсия. Мәскәү шәһәренең Дарвин музеена виртуаль экскурсия. Музей дәресе «Безнең як хайваннары». «Хайваннар дөньясында» фотографияләр конкурсы. Дөнья музейлары буенча читтән торып сәяхәт. Истәлекле әйберләр.

Иске фотографияләр белән эшләү. Җиңү паркына экскурсия.

**6 сыйныф – «Минем гаиләм-минем Россия» (35 сәгать)**

Нәрсә ул гаилә, нәсел? Укучыларның якын туганнары. Шәҗәрә. Гаилә традицияләре һәм бәйрәмнәре. Туганнарның яшәү географиясе. Гамәли дәресләр. Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү. Дуслары, әбиләре, бабайлары, башка туганнары турында хикәяләр язу. Әти-әниләре, дуслары, туганнары турында хикәя.

«Минем гаиләм», «Мин яши торган йорт», «Минем яраткан уенчыгым», «Минем өй хайваннарым» темаларына рәсем. Безнең гаилә альбомы. Гаиләдәге һөнәрләр һәм гаилә альбомын төзү турында әңгәмә. Әти-әниемнең, ата-бабаларымның һөнәре. Төрле һөнәрләр турында хикәяләр язу. Ничек һөнәр сайлыйлар. Профессиональ династияләр. Юкка чыккан яки югалу чигендә булган һөнәрләр. Борынгы һөнәр һәм заманча осталар. Видеопрезентацияләр булдыру.

Шәҗәрәне ничек төзергә. Буыннар, буыннар, ата-бабаларыбыз. «Буыннар», «нәсел» төшенчәләре белән танышу. Кем кемгә туры килә? Гаиләдә туганлык дәрәҗәсе. Ни өчен кешегә гаилә кирәк? Гаиләмнең шәҗәрәсе, шәҗәрә агачы. Шәҗәрәнең үткәндәге гамәли әһәмияте. Туганнар һәм танышлар арасында сораштыру. Гаилә архивларын өйрәнү. Минем гаиләм тарихында нинди вакыйгалар чагылды. Ата-аналар, әбиләр һәм бабайлар арасында сораштыру. Шәҗәрәнең өч баскычы. Туганлык элемтәләре. Яшәү урыны. Һөнәри дәресләр. Туганнарымның фотосурәтләре.

Минем гаиләдә реликвия (ядкарь). «Реликвия»сүзе төшенчәсен аңлату, гаилә ядкарьләре турында әңгәмә. Минем гаилә музее: гаилә реликвияләре (ядкарьләре).

Гаилә риваятьләре, легендалары, фольклоры.

Бөек Җиңү елъязмасында гаиләмнең өлеше. Проект яклау. Үз гаиләңнең тарихын өйрәнү. Бөек Ватан сугышында катнашучыларны ачыклау, минем йортымда медаль. Бөек Ватан сугышы тарихын өйрәнү. Бөек Ватан сугышында катнашкан туганнар турында материаллар җыю. «Безнең гаилә тарихында Ватан тарихы» проектын төзү һәм яклау. Музейлар белән танышу. Тематик күргәзмәләрдә катнашу.

Россия, Татарстанның Дәүләт символлары. Гимн, герб, Россия һәм Татарстан флагы тарихы белән танышу. Гимн, герб, Россия һәм Татарстан флагы тарихы белән танышу. Россия дәүләт бәйрәмнәре. Халык календаре. Халык календареның төп даталары белән танышу

Туган табигатьнең матурлыгы. Горький паркы буйлап экскурсия.

Төркем проектын яклау. Укуларга йомгак ясау. Презентация материалларын әзерләү. Дәрестән тыш эшчәнлекнең һәр катнашучысының эшенә уртак анализ. Демонстрация үз нәтиҗәләрен теләүчеләр.

**7 сыйныф – «Яшь музей хезмәткәрләре» (35 сәгать)**

Музей эшчәнлегендә төп төшенчәләр һәм терминнар. (музей, вернисаж, күргәзмә, фондлар, экскурсияләр, экспозиция һ.б.). Музей эшчәнлеге системасын булдыру һәм үстерү. Музейлар эшчәнлеге аркылы укучыларның туган якны өйрәнүенең уңышлы эш тәҗрибәсе. Нәрсә ул музей? Музей белеме-фәнни дисциплина. «Музей белеме» терминын заманча аңлау. Россиядә музей эшен җайга салучы закон актлары. Белем бирү учреждениесендә музей турында нигезләмә. Россиядә музейлар эшчәнлеген регламентлаучы төп закон актларын Интернет челтәрендә эзләү. Музейның кеше тормышында роле. Музейларның төп социаль функцияләре. Музейларның барлыкка килүе һәм аларның кеше тормышында роле. «Социаль институт» төшенчәсе. Музейларның төп социаль функцияләре. Экскурсия нәтиҗәләре буенча үз шәһәреңнең тарихын өйрәнү.

Чит илләрдә музей эше тарихы. Борынгы Греция: изге урыннар, храмнар, пинакотекалар. Борынгы Римның иҗтимагый һәм шәхси җыелышлары. Урта гасыр чоры (храмнар һәм аларның хәзинәләре).

Музейлар барлыкка килүнең тарихи шартлары. Яңарыш чоры (студиоло, антиквария, кунсткамерлар). 16-17 гасырларда фәнни кабинетлар. 17 гасырда сәнгать коллекциясе. Музей фәне барлыкка килү.

18 гасырда Көнбатыш Европа музейлары. Ачык музей концепциясен формалаштыру. Бөек Британия, Германия, Австрия, Италия, Франция музейлары һәм картиналар галереяләре.

Дөньяның танылган музейлары турында видеофильмнар карау; сайтлар эзләү һәм алар аша танылган чит ил музейлары белән танышу.

Россиядә беренче музейлар. Кабинетлар һәм галереяләр (17 гасыр ахыры – 18 гасырның беренче чиреге). Санкт-Петербургта Кунсткамера. Эрмитаж император музее. Уку һәм фәнни учреждениеләр кабинетлары. Иркутск музее. Россиядә 18-19 гасырның беренче яртысында экспонатлар туплау.

Музей челтәре һәм музейлар классификациясе. Россиядә музейларны классификацияләү принциплары. Җәмгать башлангычларында булдырылган шәхси музейлар. Дәүләт музейларының шәхси һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлеге.

«Музей фондлары», «музей предметы», «экспонат», «артефакт» һ.б. төшенчәләрен билгеләү. Музей фондларының составы һәм структурасы. Фондларны тулыландыру. Күргәзмә эшен оештыру һәм экскурсияләр үткәрү өчен фондларны куллану. Мәктәп музее фондлары белән танышу; мәктәп музее экспонатының хисап карточкасын төзү.

«Музей экспозициясе», «экспонат», «экспозицион материал», «тематик структура», «экспозицион комплекслар» һ.б төшенчәләр. экспозиция материаллары (музей әйберләре, күчермәләр, текстлар, фономментарийлар һ.б.)

Музейларның экспозицияләре үзенчәлекләре (тарихи Музейлар, туган якны өйрәнү музейларының тарихи бүлекләре, сәнгать музейлары, этнографик музейлар, музей - тыюлыклар, ачык һавада музейлар һ.б.).

Музейлар заманча фәнни һәм эзләнү-тикшеренү үзәкләре буларак эшли. Фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең төп юнәлешләре: музейның фәнни концепциясен эшләү; фондларны туплау; музей предметларын һәм коллекцияләрен өйрәнү; фондларны саклау; реставрацияләү, музей педагогикасы, социаль - психологик тикшеренүләр; тарих, музей эше теориясе һәм методикасы өлкәсендә тикшеренүләр.

Музейның күргәзмә эшчәнлеге. Музей экспонатларын классификацияләү һәм системалаштыру. Терминнар «күргәзмә» һәм «музейның күргәзмә эшчәнлеге». Күргәзмәләр классификациясе.

Х.М.Мөштәри һәм Р.Ваһапов музейларынңда тематик күргәзмә әзерләүдә катнашу.

Тарихи документ. Табигый тарихи чыганакларны саклау кагыйдәләре.

Музей эшендә экскурсовод роле. Экскурсияләр әзерләү методикасы. Интернет технологияләре куллану. Экскурсияне ничек үткәрергә. Чыганакларны өйрәнү һәм аның тарихны өйрәнүдә роле. Чыганаклар белән эшләүнең төп этаплары.

Музейның мәдәни-белем бирү эшчәнлеге һәм аның төп формалары. Музейның максатлары һәм бурычлары, мәдәни – белем бирү эшчәнлеге үзенчәлеге. Төп таләпләр: югары теоретик һәм методик дәрәҗә, актуальлек һәм кызыксынучанлык, катнашучыларның яшен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, экспозициягә таяну.

Экскурсияләр белем бирү эшчәнлегенең төп формасы - белем бирү экскурсияләре объектлары.

Музейга экскурсия барышында шәхси эзләнү-тикшеренү биремнәрен үтәү (экспозиция стендларында кызыксынучы проблема буенча мәгълүмат эзләү, экскурсовод өчен проблема буенча сораулар формалаштыру һ.б.)

**8 сыйныф – «Мин-экскурсовод» (35 сәгать)**

Мин-экскурсовод. Сөйләм культурасының әһәмияте. Аралашу кагыйдәләре, басым нормалары, сүз төркемнәрендә басым үзенчәлекләре. Дөрес сөйләмгә карата таләпләр. Интонация. Татар телендә интонация. Җөмләләрдә мөһим әйберләрне басым белән күрсәтү.

Экскурсия эше. Төп төшенчәләр: «экскурсия», «экскурсия методы», «экскурсовод». Экскурсияне әзерләү принциплары. Мәктәп музеенда экскурсияне әзерләү һәм аны үткәрүнең төп принциплары.

Чыганакларны өйрәнү һәм аның тарихны өйрәнүдә роле. Тарихи чыганаклар төрләре. Белешмә әдәбият куллану. Чыганаклар белән эшләүнең төп этаплары. Мәктәп музеенда практик эш.

Музей экспозициясе һәм күргәзмәсе. Экспозиция турында төшенчә. Тематик-экспозиция планын эшләү методикасы һәм принциплары. Музей фондлары. Экспозицияне проектлау. Музей предметлары. Төп фондта эш.

Музей комплексы нәрсә ул? Музей материаллары белән эшләүнең төп кагыйдәләре. Музей материалларын исәпкә алу һәм саклау.

Мәктәп музеенда күргәзмә яки экспозицияләр әзерләү. Әдәби һәм тарихи кунак бүлмәләр.

Музей экскурсияләре төрләре. Музей экскурсияләренең үзенчәлекләре. Музей экскурсияләре үткәрү методикасы.

Укучыларның иҗади эшләре күргәзмәсе.

**9 сыйныф – «Чиксез музей» (34 сәгать)**

Экскурсия үткәрү кагыйдәләрен кабатлау. Экскурсия үткәрү. Экскурсион алымнар (Теоретик дәрес, әңгәмә)

Экскурсоводның сөйләм культурасы. Сөйләм культурасының әһәмияте. Аралашу кагыйдәләре, басым нормалары, сүз төркемнәрендә басым үзенчәлекләре. Дөрес сөйләмгә карата таләпләр. Теоретик дәресләр, лекция, әңгәмә, гамәли дәресләр: сөйләм аппаратын әзерләү өчен күнегүләр. Халык алдында сөйләм ритмы. Яшь экскурсоводларга киңәшләр.

Сөйләм үсеше буенча практикум. Дикцияне һәм дөрес сөйләмне үстерү буенча күнегүләр эшләү. Шагыйрьләрнең туган як шәһәре, тарихы һәм табигате турында шигырьләре. (Шигырьләр сайлау)

Мәктәп музее буенча экскурсиягә әзерлек.

Экспозиция турында төшенчә. Мәктәп музее экспозициясе. Тематик-экспозиция планын эшләү методикасы һәм принциплары. Музей фондлары. (Теоретик дәрес, әңгәмә)

Экскурсия тексты. Әзер текст белән эшләү методикасы. Экскурсиянең өч өлеше. Экскурсиягә таләпләр. (Теоретик дәресләр, лекция, әңгәмә)

Экскурсия. Күрсәтү методикасы һәм алымнары. Экскурсия алымнары (хикәяләр, чагыштыру, реконструкция). (Теоретик дәресләр, лекция, әңгәмә) гамәли дәрес: сөйләмне, күрсәтү күнекмәләрен һәм хикәяләрне эшкәртү. Экскурсияләр үткәрү күнекмәләрен булдыру.

Мәктәп тарихы буенча экскурсия үткәрү. Мәктәп укучылары һәм кунаклар өчен экскурсияләр үткәрү.

Гамәли дәрес.

## Тематик планлаштыру

**5 сыйныф – «Исәнме, музей!»**

| № п/п | Теманың исеме | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Нәрсә ул музей? | 1 |
| 2 | Казан – минем шәһәрем. Рәсемнәр конкурсы. | 1 |
| 3 | Казан – минем шәһәрем. Фотографияләр конкурсы. | 2 |
| 4 | Казанның иң танылган һәйкәлләре. | 2 |
| 5 | Казан шәһәре урамнарының исемнәре тарихы. | 2 |
| 6 | Казан шәһәренең архитектура һәйкәлләре. | 2 |
| 7 | Казан шәһәренең истәлекле урыннары. | 2 |
| 8 | Читтән торып Казан шәһәре буенча экскурсия. | 1 |
| 9 | Казан шәһәре буенча экскурсия маршрутын төзү. | 1 |
| 10 | Казанның күренекле кешеләре. | 1 |
| 11 | Мәктәп музеенда, сыйныфта куркынычсызлык кагыйдәләре. | 1 |
| 12 | Х. М. Мөштәри мәктәп музей-кабинетына экскурсия. | 1 |
| 13 | Р.Ваһапов мәктәп музей-кабинетына экскурсия. | 1 |
| 14 | Казан шәһәре музейлары. | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| 15 | Уенчыклар музеена экскурсия. | 2 |
| 16 | Мәскәү шәһәренең Дарвин музеена читтән торып экскурсия. | 1 |
| 17 | Музей дәресе «Безнең якта яшәүче хайваннар». | 1 |
| 18 | Фотографияләр конкурсы «Хайваннар дөньясында». | 2 |
| 19 | Дөнья музейлары буенча читтән торып сәяхәт. | 3 |
| 20 | Гаилә реликвияләре. Истәлекле әйберләр. | 2 |
| 21 | Иске фотография сөйләде. | 2 |
| 22 | Җиңү паркына экскурсия. Йомгак ясау. | 2 |

**6 сыйныф – «Минем гаиләм-минем Россия»**

| № п/п | Теманың исеме | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. «Минем гаиләм-минем Россия» | 1 |
| 2 | Нәрсә ул гаилә, нәсел? | 2 |
| 3 | Минем шәҗәрәмдә һөнәрләр. Безнең гаилә альбомы. Гаиләдәге һөнәрләр һәм гаилә альбомын төзү турында әңгәмә. | 3 |
| 4 | Шәҗәрәне ничек төзергә. Шәҗәрә төзү. | 2 |
| 5 | Минем гаиләдә.<br>«Ядкарь» төшенчәсе аңлатмасы, әңгәмә. Гаилә ядкарьләре турында. | 3 |
| 6 | Җиңү елъязмасына гаиләмнең өлеше. Проект яклау. | 2 |
| 7 | Медаль минем йортымда. Проект яклау. | 5 |
| 8 | Музейлар белән танышу.<br>Тематик күргәзмәләрдә катнашу. | 3 |
| 9 | Россия, Татарстанның Дәүләт символлары.<br>Россия һәм Татарстан гимны, гербы, флагы тарихы белән танышу. | 4 |
| 10 | Россия дәүләт бәйрәмнәре.<br>Россия бәйрәмнәре белән танышу. | 3 |
| 11 | Халык календаре. Халык календареның төп даталары белән танышу. | 2 |
| 12 | Туган ягыбыз табигатенең матурлыгы.<br>Горький паркы буйлап экскурсия. | 2 |
| 13 | Йомгаклау гомумиләштерү.<br>Төркем проектын яклау. | 4 |

**7 сыйныф – «Яшь музей хезмәткәрләре»**

| № п/п | Теманың исеме | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Музейның төп төшенчәләре һәм терминнары | 2 |
| 2 | Музей белеме - фәнни дисциплина | 2 |
| 3 | Музейның кеше тормышында роле. Музейларның төп социаль функцияләре | 1 |
| 4 | Чит илләрдәге музейлар эше тарихы (18 гасырга кадәр).<br>Коллекцияләр туплау. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Россиядәге музейлар эше тарихы. Коллекцияләр туплау. (17 гасыр ахыры 19 гасырның яртысы) | 2 |
| 6 | Музей челтәре һәм музейлар классификациясе. | 1 |
| 7 | Музей фонды.Фондлар белән эшләү алымнары. | 3 |
| 8 | Музей экспозициясе һәм аның төрләре. | 2 |
| 9 | Музейларның фәнни-эзләнү һәм тикшеренү эшчәнлеге. | 2 |
| 10 | Музейның күргәзмә эшчәнлеге. Музей экспонатларын классификацияләү һәм системалаштыру. | 2 |
| 11 | Тарихи документлар.Тарихи чыганакларны саклау кагыйдәләре. | 2 |
| 12 | Музей эшчәнлегендә экскурсоводның роле. | 2 |
| 13 | Экскурсияләр әзерләү методикасы. Интернет – технологияләр куллану. | 2 |
| 14 | Экскурсияне ничек үткәрергә? Экскурсиягә әзерләнү һәм аны үткәрү методикасы. | 2 |
| 15 | Чыганакларны өйрәнү һәм аның тарихны өйрәнүдә роле. Чыганаклар белән эшләүнең төп этаплары | 3 |
| 16 | Тикшеренү эшчәнлеге формалары:интервью, сораулар, өлешчә-эзләнү, әңгәмә һ.б. | 2 |
| 17 | Чыганаклар белән эшләүнең төп этаплары. | 2 |
| 18 | Музейның мәдәни-белем бирү эшчәнлеге. Нәтиҗәләр ясау. | 1 |

## 8 сыйныф – «Мин-экскурсовод»

| № п/п | Теманың исеме | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Мин-экскурсовод. | 2 |
| 2 | Чыганакларны өйрәнү һәм аның тарихны өйрәнүдә роле . Мәктәп музеенда практик (гамәли) эш. | 2 |
| 3 | Чыганаклар белән эшләүнең төп этаплары. Мәктәп музеенда практик эш. | 2 |
| 4 | Музей экспозициясе һәм күргәзмәсе. Мәктәп музеенда практик эш. | 3 |
| 5 | Экспозицияне проектлау. Мәктәп музеенда практик эш. | 2 |
| 6 | Музей предметлары. Төп фондта эш. | 3 |
| 7 | Музей комплексы нәрсә ул? Лекция – презентацияләр. | 1 |
| 8 | Музей материаллары белән эшләүнең төп кагыйдәләре. Практик эш. | 2 |
| 9 | Музей материалларын исәпкә алу һәм саклау. Практик эш. | 3 |
| 10 | Мәктәп музеенда күргәзмә яки экспозицияләр әзерләү. (әдәби, тарихи) | 3 |
| 11 | Музей экскурсияләре төрләре. Практик эш. | 2 |
| 12 | Музей экскурсияләренең үзенчәлекләре. Музей экскурсияләре үткәрү методикасы. | 2 |
| 13 | Укучыларның иҗади эшләре күргәзмәсе. Практик эш. | 3 |
| 14 | Йомгаклау тикшеренү конференциясе. Практик эш. | 2 |
| 15 | Йомгаклау дәресе. Практик эш. | 2 |

## 9 сыйныф – «Чиксез музей»

| № п/п | Теманың исеме | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Экскурсия үткәрү кагыйдәләре. | 1 |
| 2 | Экскурсоводның сөйләм культурасы. | 2 |
| 3 | Сөйләм үсеше буенча практикум | 5 |
| 4 | Мәктәп музее буенча экскурсиягә әзерлек. | 4 |
| 5 | Мәктәп музее экспозициясе. | 2 |
| 6 | Экскурсия тексты. | 2 |
| 7 | Экскурсион күрсәтү (күрсәтү методикасы һәм алымнары) | 2 |
| 8 | Мәктәп тарихы буенча экскурсия үткәрү. | 5 |
| 9 | Практик эш. Виртуаль музейлар төзү һәм ИКТ кулланып аларны яңгырату. | 10 |
| 10 | Йомгаклау дәресе. Практик эш. | 2 |

### Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүнең дәрәҗәләре

**1 нче дәрәҗә:**(мәктәп укучысының социаль белемнәрен, социаль чынбарлыкны һәм көндәлек тормышын аңлау):

– туган як тарихы турында белемнәрен якын–тирәдәге кешеләр, истәлекле урыннарны өйрәнү аша үстерү;

– әйләнә-тирә дөньяга тулы караш формалаштырырга ярдәм итүче төшенчәләрен үстерү;

– музейларда, архивларда, уку залларында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән танышу;

– укучылар тарафыннан тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә, башка буын һәм социаль төркемнәргә караган белемнәр алу:

а) Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын искә алу традицияләре турында;

ә) конструктив төркем эше кагыйдәләре турында;

б) белешмә әдәбиятта мөстәкыйль эзләү һәм мәгълүмат табу ысуллары турында;

**2 нче дәрәҗә:** (укучының җәмгыятьнең төп кыйммәтләренә һәм тулаем алганда социаль чынбарлыкка уңай мөнәсәбәтен формалаштыру):

– укучының туган Ватанга, туган табигатькә һәм мәдәнияткә, хезмәткә, башка кешеләргә, үз сәламәтлекләренә һәм эчке дөньяга карата уңай мөнәсәбәтләрен үстерү;

– мәктәп укучысының туган як тарихына һәм туган якны өйрәнүгә, үз мәктәбенең үткәненә, эти-әниләренең мәктәп тәҗрибәсенә карата мөнәсәбәтләрен үстерү.

**3 нче дәрәҗә.** (мәктәп укучысының мөстәкыйль социаль эш тәҗрибәсе алу):

– укучы үз-үзенә хезмәт күрсәтү тәҗрибәсе;

– тарихны саклау һәм тарихи әйберләрне саклау эшчәнлеге тәҗрибәсе;

– тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау тәҗрибәсе;

– җәмәгатьчелек фикерен сораштыру һәм интервью бирү тәҗрибәсе;

– Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм шаһитлар белән аралашу тәҗрибәсе;

– хәйрия эшчәнлеге тәҗрибәсе;

– башка балалар белән уртак эшчәнлек оештыру һәм командада эшләү тәҗрибәсе ала;

– үз өстенә башка кешеләр өчен җаваплылык алу һәм алар белән идарә итү тәҗрибәсе.

**Тикшерү һәм мониторинг үткәрү формалары:**

1. экскурсияләр үткәрү;
2. күргәзмәләр оештыру;
3. конференцияләрдә катнашу;
4. мөстәкыйль эзләнү буенча проект яклау;
5. предмет атналыкларында катнашу;
6. портфолио;
7. иҗади отчет;
8. шәхес буларак үсү мониторингы.

**Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:**

1. иҗади эшчәнлеккә кызыксыну арту;
2. аудитория алдында чыгыш ясауга кызыксыну, мотивация уяну;
3. социаль активлыкны күтәрү;
4. мөстәкыйль иҗади эшчәнлек күнекмәләрен үстерү;
5. укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә тарту динамикасы.

Укучыларның белем эшчәнлеген бәяләү, укучы тарафыннан потенциаль мөмкинлекләрен белү-белмәү чикләрен, шулай ук, алда торган проблемалар дәрестән тыш эшчәнлек барышында хәл ителә.

## Кулланылган әдәбият


1. «Примерная основная образовательная программа основного общего образования» (одобрена решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол от 08.04.2015 N 1/15) (ред. от 04.02.2020)
2. «Примерные программы внеурочной деятельности. Начальное и основное образование» (Под редакцией В.А.Горского), -Москва «Просвещение»,2014.
3. А.Я.Данилюк, А. М. Кондаков, В. А. Тишков. Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России. 2009.
4. Д.В. Григорьев, П.В. Степанов. Внеурочная деятельность школьников. Методический конструктор. М.: Просвещение, 2010.
5. Гулевич И.И. Проектирование внеурочной деятельности // Методист.– №2, - 2013. – С.16-22.
6. Внеурочная деятельность: содержание и технологии реализации: Методическое пособие / науч. ред. И.В. Муштавинская и Т.С. Кузнецова. – Санкт- Петербург: КАРО, 2016. – 256 с.
7. Научно-методический журнал «Спутник классного руководителя», 2011 No25. Патриотическое воспитание: система работы, планирование, конспекты уроков, разработки занятий/ авт.-сост. И.А. Пашкович. –2-е изд., стереотип. –Волгоград: Учитель, 2008. –169с.
8. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек/төзүчеләр: А.Х.Мөхәммәтҗанова, Р.Б.Камаева, –Казан:ТРМҮИ,2015.–68.
9. Юхневич М.Ю. Я поведу тебя в музей. Учебное пособие по музейной педагогике./ Министерство культуры РФ. Рос. ин – т культурологии. – М.: 2001. – 224с.
10. Грицкевич В.П. История музеев мира: учеб.пособие для студентов "Музейное дело и охрана ист.-культур. наследия"/ В.П.Грицкевич, А.А.Гужаловский. -Минск: Изд-во Белорус. ун-та, 2003.

## 5-9 нчы сыйныфлар өчен гомуми интеллектуаль юнәлеш буенча “Без тарихта эзлебез” дигән дәрестән тыш эшчәнлек эш программасы

**Үтәү вакыты 5 ел**

*Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы, Казан шәһәре Яңа Савин районы 43 нче урта гомуми белем мәктәбенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

### Аңлатма язуы

Туган (татар) тел һәм әдәбияттан 5-9 нчы сыйныфларда дәрестән тыш эшчәнлек алып бару өчен төзелгән “Без тарихта эзлебез” дигән эш программасы укучыларның теләкләрен исәпкә алып, аларны татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре белән таныштыруны, төрле өлкәләрдә сәләтләрен ачуны һәм үстерүне күздә тота. Программа нигезендә эшчәнлек дәресләрдән соң расписание буенча уздырыла. Атнага 1 сәгать исәбеннән үткәрелә. 5 нче сыйныф – 35 сәгать, 6 нчы сыйныф – 35 сәгать, 7 нче сыйныф – 35 сәгать, 8 нче сыйныф – 35 сәгать, 9 нчы сыйныф – 34 сәгать. Барлыгы: 174 сәгать.

Курска татар халкының үсеш тарихын, аның бай мирасын өйрәнергә теләгән балалар йөри. Укучыларның әлеге курс буенча алынган белемнәренә билге куелмый. Өстәмә дәресләр кызыклы, мавыктыргыч булсын өчен уен, ярыш, сорау-җавап формалары кулланыла.

### Эш программасының эчтәлеге

***Программаның максаты:***

- укучыларның сәләтләрен һәръяклап ачу һәм үстерү өчен реаль шартлар булдыру;
- татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү;
- милли - төбәк компоненты материаллары белән танышу;
- дәрестә алган грамматик, орфографик, пунктуация, сөйләм теле һәм язу күнекмәләрен ныгыту һәм үстерү;
- иҗат эше белән шөгыльләнү һәм материалларны төрле басмаларга тәкъдим итү;
- төрле темаларга чыгышлар ясау;
- төрле һөнәр ияләре белән очрашулар үткәрү;
- халык авыз иҗаты әсәрләре белән танышу;
- балаларның татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынуларын үстерү, аңа мәхәббәт тәрбияләү;
- милли үзаңны үстерү.

***Бурычлары:***

Укучылар бу курста белергә тиешләр:

- дөрес һәм ачык итеп үз фикерләрен әйтә белергә;
- хәзерге татар әдәби теленең орфографик, орфоэпик, лексик, пунктуацион нормаларын төгәл белергә;
- эш кәгазьләрен дөрес язарга өйрәнергә;

- сөйләм этикеты белән таныш булырга;
- төрле сүзлекләрдән файдалана белергә.

***Метапредмет нәтиҗәләре*:**

*Шәхескә кагылышлы УУГ:*

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру:
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;
- актив, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртүче, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкара алырлык шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

*Танып-белү УУГ:*

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
- татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү юлы аша фразеологик берәмлекләрнең эчтәлегендәге фәлсәфәне үзләштерү.

*Коммуникатив УУГ:*

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау.

*Регулятив УУГ:*

- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

***Предмет нәтиҗәләре:***

- тел материалы белән логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- телнең сүзлек составын куллану өлкәсе, активлыгыннан чыгып урынлы файдалану;
- бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, кечкенә хикәяләр язу;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру.

## 5 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Эш төре, темасы | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | “Без тарихта эзлебез” дигән өстәмә дәрес турында мәгълүмат бирү.<br>“Үзем турында үзем”. Әңгәмә үткәрү. | 1 |
| 2 | Тел – иҗтимагый күренеш. | 1 |
| 3 | Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр. | 1 |
| 4 | Татар халык авыз иҗаты әсәрләре. | 1 |
| 5 | Татар халык әкиятләре. | 1 |
| 6 | “Газиздер бу туган җирем” туган як тарихы белән танышу. | 1 |
| 7 | Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары һәм милли бәйрәмнәре. | 1 |
| 8 | **Проект эше:** Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары һәм бәйрәмнәре. | 1 |
| 9 | “Әй, Идел-йорт, Идел-йорт” “Идегәй” дастаны | 1 |
| 10 | Татарстанның Милли музеена сәяхәт. | 1 |
| 11 | Татарстанның истәлекле урыннары. | 1 |
| 12 | Казаныбызның истәлекле урыннары. | 1 |
| 13 | Казан турындагы легендалар. | 1 |
| 14 | Казан турында хикәя язу һәм шушы укып күрсәтү. | 1 |
| 15 | Мәчетләр тарихы. | 1 |
| 16 | Мин һәм минем нәселем. | 1 |
| 17 | “Шәҗәрә - тәрбиянең асыл ташы” – **конкурс.** | 1 |
| 18 | Каюм Насыйри –татар халкының танылган шәхесе. | 1 |
| 19 | Каюм Насыйри музеена сәяхәт (презентация). | 1 |
| 20 | Шиһабеддин Мәрҗани. | 1 |
| 21 | Татар язучыларының юбилейлары. | 1 |
| 22 | Ач, шигърият, серләреңне. | 1 |
| 23 | Муса Җәлил –патриотик шагыйрь. | 1 |
| 24 | Салих Сәйдәшев – татар халкының танылган композиторы. | 1 |
| 25 | Бакый Урманче – танылган рәссамыбыз. | 1 |
| 26 | **Сочинениеләр** конкурсы “Татар халкының танылган шәхесләре”. | 1 |
| 27 | Әдәби әсәрләрдәге сурәтләү чаралары. | 1 |
| 28 | Сурәтләү чаралары кулланып ирекле темага **хикәя** язу. | 1 |
| 29 | Салих Сәйдәшев музеена сәяхәт. | 1 |
| 30 | Габдулла Тукай – шигъри чишмәбез. | 1 |
| 31 | Без - Тукай шәкертләре. Шигърият бәйрәмендә катнашу. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 32 | Телдәге “ матур” сүзләр. | 1 |
| 33 | Рефератлар, хикәяләр язабыз. | 1 |
| 34 | Укучыларның иҗат җимешләрен республика газета битләренә тәкъдим итү өчен әзерләү. | 1 |
| 35 | Еллык эшкә йомгак ясау. | 1 |

## 6 НЧЫ СЫЙНЫФ ӨЧЕН ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Эш төре, темасы | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | “Туган телем – иркә гөлем”. Әңгәмә үткәрү. | 1 |
| 2 | Төрки телләр. Гомумтөрки сүзләр. | 1 |
| 3 | Телебездәге алынма сүзләр. | 1 |
| 4 | Күп мәгънәле сүзләр. | 1 |
| 5 | Тыныш билгеләре һәм язма сөйләм. | 1 |
| 6 | Иҗат дөньясында (хикәяләр язу). | 1 |
| 7 | Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре белән танышу. | 1 |
| 8 | XVII - XVIII йөз әдәбияты белән танышу. | 1 |
| 9 | **Проект эше: Борынгы гасыр, XVII - XVIII йөз әдипләре.** | 1 |
| 10 | XIX йөз әдәбияты һәм әдипләре. | 1 |
| 11 | XX йөз башы әдәбияты һәм әдипләре. | 1 |
| 12 | XX йөз әдәбияты һәм әдипләре. | 1 |
| 13 | Сугыш чоры әдәбияты. | 1 |
| 14 | **Проект эше: XIX - XX йөз әдипләре.** | 1 |
| 15 | Сугыш чоры әдипләренең иҗаты турында **сочинение** язу. | 1 |
| 16 | Бөек Ватан сугышы музеена сәяхәт. | 1 |
| 17 | Казаныбызның истәлекле урыннары. Казан мәчетләре. | 1 |
| 18 | Казанның югары уку йортлары. | 1 |
| 19 | Казан урамнары. | 1 |
| 20 | **Проект эше: Казан – башкалам.** | 1 |
| 21 | Казан турында легенда уйлау һәм шушы сөйләп күрсәтү. | 1 |
| 22 | Мин һәм минем нәселем. | 1 |
| 23 | “Минем гаиләм” – реферат язу. | 1 |
| 24 | Муса Җәлил – патриотик шагыйрь. | 1 |
| 25 | Шигырь укучылар бәйгесе үткәрү. | 1 |
| 26 | Җәүдәт Фәйзи – татар халкының танылган композиторы. | 1 |
| 27 | Харис Якупов – танылган рәссамыбыз. | 1 |
| 28 | Илһам Шакиров – татар халкының танылган артисты. | 1 |
| 29 | Театр яктылыкка, нурга илтә. | 1 |
| 30 | Әкиятләр язабыз. | 1 |
| 31 | Тукай - шигъри чишмәбез. Шигърият бәйрәмендә катнашу. | 1 |
| 32 | Шигырь язучылар бәйгесе. | 1 |
| 33 | Ирекле темага сочинениеләр бәйгесе. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 34 | Укучыларның иҗат җимешләрен республика газета битләренә тәкъдим итү өчен әзерләү. | 1 |
| 35 | Еллык эшкә йомгак ясау. | 1 |

## 7 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Эш төре, дәрес темасы | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | Тел – күңелең көзгесе. | 1 |
| 2 | Легендалар һәм риваятьләр. | 1 |
| 3 | Казан турында легенда һәм риваятьләр. | 1 |
| 4 | Казанның тарихи урамнары. | 1 |
| 5 | Халык җырлары. | 1 |
| 6 | Мөнәҗәтләр. | 1 |
| 7 | Бәетләр. | 1 |
| 8 | **Проект эше: Татар халык авыз иҗаты.** | 1 |
| 9 | Дәрдемәнд (Закир Рәмиев). | 1 |
| 10 | Ф. Әмирханның “Фәтхулла хәзрәт” әсәре. | 1 |
| 11 | Һ. Такташ әсәрләре | 1 |
| 12 | Г. Ибраһимов хикәяләре. | 1 |
| 13 | **Проект эше: Яраткан язучым.** | 1 |
| 14 | Г. Тукай – татар халкының яраткан шагыйре. | 1 |
| 15 | Г. Тукай сәнгатьтә. | 1 |
| 16 | Ф. Кәрим поэмалары. | 1 |
| 17 | М. Җәлил – патриот шагыйрь. | 1 |
| 18 | Г. Кутуйның “Рөстәм маҗаралары” әсәре. | 1 |
| 19 | **Проект эше: Рөстәм.** | 1 |
| 20 | Ә. Еникинең “Туган туфрак” әсәре. | 1 |
| 21 | Исемең матур, кемнәр куйган? | 1 |
| 22 | Сөйләшү серләре. | 1 |
| 23 | Кушаматлар. | 1 |
| 24 | Казан тарихы. | 1 |
| 25 | Авыллар тарихы. | 1 |
| 26 | Китап – сердәшең. | 1 |
| 27 | **Проект эше: Минем шәҗәрәм.** | 1 |
| 28 | Хатлар яздым мин утырып... | 1 |
| 29 | Хикәяләр яздым әле... | 1 |
| 30 | Г. Тукай музеена сәяхәт. | 1 |
| 31 | Табигатькә сәяхәт. | 1 |
| 32 | **Проект эше: Туган ягымның иң гүзәл почмагы.** | 1 |
| 33 | Бүгенге көн шагыйрьләре. | 1 |
| 34 | Эш кәгазьләре. | 1 |
| 35 | Еллык эшкә йомгак ясау. | 1 |

# 8 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Эш төре, дәрес темасы | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | Телләр белгән - илләр белгән. | 1 |
| 2 | Бәетләр. | 1 |
| 3 | Бүгенге көндә чыккан бәетләр. | 1 |
| 4 | Казанда Г. Тукай булган урыннар. | 1 |
| 5 | Г. Тукай әсәрләренә сәяхәт. | 1 |
| 6 | **Проект эше: Г. Тукай – шигъри чишмәбез.** | 1 |
| 7 | Татар халкының гореф-гадәтләре. | 1 |
| 8 | Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. | 1 |
| 9 | Сабантуй һәм җыен. “Сабан туе” җырын өйрәнү. | 1 |
| 10 | Г. Тукайның “Исемдә калганнар”, Г. Ибраһимовның “Алмачуар”. әсәрләрендә сабантуй вакыйгасының бирелеше. | 1 |
| 11 | **Проект эше: Татар халкының йолалары һәм гореф-гадәтләре.** | 1 |
| 12 | Н. Думави иҗаты. | 1 |
| 13 | Ф. Хөсни әсәрләренә сәяхәт. | 1 |
| 14 | Хатлар яздым утырып... | 1 |
| 15 | М.Җәлил музеена сәяхәт. | 1 |
| 16 | М. Мәһдиев әсәрләренә сәяхәт. | 1 |
| 17 | М. Җәлил – патриот шагыйрь. | 1 |
| 18 | М. Әгъләмов иҗаты. | 1 |
| 19 | Р. Харис иҗаты. | 1 |
| 20 | **Проект эше: Яраткан язучым.** | 1 |
| 21 | Исемең матур, кемнәр куйган? | 1 |
| 22 | Телебездәге матур сүзләр. | 1 |
| 23 | Мин яраткан әдәби герой. | 1 |
| 24 | Укыган әдәби әсәр героена хат язу. | 1 |
| 25 | Китап – якын сердәшең. | 1 |
| 26 | Мин яшәгән урамның тарихы. | 1 |
| 27 | Кол Шәриф мәчете. | 1 |
| 28 | **Проект эше: “Казаным -башкалам”.** | 1 |
| 29 | Шигырьләр языйм әле... | 1 |
| 30 | Г. Тукай – татар халкының яраткан шагыйре. | 1 |
| 31 | Табигатькә сәяхәт. | 1 |
| 32 | **Проект эше: Туган ягым – гөлләр иле.** | 1 |
| 33 | Бүгенге көн шагыйрьләре. | 1 |
| 34 | Эш кәгазьләре. | 1 |
| 35 | Еллык эшкә йомгак ясау. | 1 |

# 9 НЧЫ СЫЙНЫФ ӨЧЕН ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Эш төре, дәрес темасы | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | Туган телем – иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем. | 1 |
| 2 | Телебездәге афоризмнар. | 1 |
| 3 | Татар халкының танылган драматурглары. | 1 |
| 4 | Драматургия. | 1 |
| 5 | Театрга сәяхәт. | 1 |
| 6 | Ф. Халиди “Рәдде бичара кыз.” | 1 |
| 7 | Г. Камал “Банкрот”. | 1 |
| 8 | **Проект эше: Татар театрлары.** | 1 |
| 9 | Ф. Кәрим “Фәтхулла хәзрәт”. | 1 |
| 10 | Г. Ибраһимов хикәяләре. | 1 |
| 11 | Ә. Еники “Туган туфрак”. | 1 |
| 12 | Ә. Еники “Бер генә сәгатькә”. | 1 |
| 13 | А. Гыйләҗев – танылган шәхес. | 1 |
| 14 | **Проект эше: Татар халкының танылган шәхесләре.** | 1 |
| 15 | Юмор һәм сатира. | 1 |
| 16 | Г. Афзалның юмористик шигырьләре. | 1 |
| 17 | М. Җәлил – яраткан шагыйребез (М. Җәлил иҗатында юмор). | 1 |
| 18 | Ш. Галиев – юмористик шигырьләр остасы. | 1 |
| 19 | Бүгенге көн юмор осталары. | 1 |
| 20 | Юмористик видеолар белән танышу. | 1 |
| 21 | **Проект эше: “Юмор һәм сатира осталары”.** | 1 |
| 22 | Бүгенге көн шагыйрьләре. | 1 |
| 23 | Бүгенге көн язучылары. | 1 |
| 24 | Укыган әдәби әсәр героена хат язу. | 1 |
| 25 | Һөнәрләр илендә. | 1 |
| 26 | Төзүчеләр турындагы әдәби әсәрләр. | 1 |
| 27 | Табиблар турындагы әдәби әсәрләр. | 1 |
| 28 | Юристлар турындагы әдәби әсәрләр. | 1 |
| 29 | Укытучылар турындагы әдәби әсәрләр. | 1 |
| 30 | Хикәяләр яздым әле... | 1 |
| 31 | Г. Тукай – татар халкының яраткан шагыйре. | 1 |
| 32 | Эш кәгазьләре. | 1 |
| 33 | Табигатькә сәяхәт. | 1 |
| 34 | Еллык эшкә йомгак ясау. | 1 |

# Дәрестән тыш эшчәнлек программасы
# “Бәллүр каләм” җыены
# (Укучыны гомуммәдәни яктан үстерү юнәлеше)

## (5-7 сыйныф укучылары өчен)

*Җәләлиева Ләйсән Равил кызы, Макарова Ирина Александр кызы, Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең югары квалификацион категорияле туган тел укытучылары*

**Аңлатма язуы.**

Матур әдәбиятның шәхес үстерүдә тоткан урыны һәм роле бик зур. Балалар өчен язылган китаплар акыл, әхлак, эстетик тәрбия чаралары булып тора. В.А. Сухомлинский әйткәнчә: «Китап уку – ул бала йөрәгенә юл табу». Матур әдәбият сөйләм үстерү методикасында мөһим урын алып тора, чөнки ул балаларны әдәби тел дөньясына алып керә. Сүзләрнең төрле яңгырашы, аһәңе аша туган телгә мәхәббәт тәрбияли, шул телдә кыенсынмый теләп сөйләшергә өйрәтә.

Урта гомуми белем баскычында укучыларны рухи-әхлакый, гомуммәдәни үстерү һәм тәрбияләү программасының норматив-хокукый һәм документлар нигезе булып «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Законы, Россия гражданины шәхесен рухи-әхлакый, гомуммәдәни үстерү һәм тәрбияләү концепциясе, федераль дәүләт белем стандарты тора.

Матур әдәбиятны яратучылар тормышка икенче күз белән карыйлар, яхшы белән яманны, актан караны аералар, ул тел байлыгын үстерә. Нинди генә шигырьне, әкиятне укысаң да, алар күңелне баета, бу гүзәл дөньяның серләрен ача. Китап укыган кеше, гомумән, бу дөньяны икенче яктан күрә, тормышның кадерен белергә өйрәнә. Шуңа күрә барлык балаларны да китап укырга өндисем килә. Үз телен, әдәбиятын белгән кеше беркайчан да югалмас, тормышында үз урынын таба алыр. "Китап − белем чишмәсе" дигән халык. Чыннан да, китап биргән белемне бернәрсә дә алыштыра алмый. Анда безнең тарихыбыз, милләтебез, безнең бүгенге һәм киләчәк көнебез!

Мәктәпләрдә әдәбият дәресләре чикле. Әдәбиятта яңа исемнәр, аларның иҗаты белән танышу; туган ягыбызның әдәбият һәм журналистика әһелләрен, аларның иҗатын киңрәк өйрәнү һәм укучыларның иҗади сәләтләрен ачуны күздә тотып, дәрестән тыш эшчәнлек алып барырга булдык. Ул эшчәнлекне «Бәллүр каләм» җыены дип атадык.

Эшчәнлек планын төзегәндә һәр классның әдәбият программасы, укучыларның теләкләре һәм кызыксынулары искә алынды.

“Бәллүр каләм” җыены сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади сәләтен үстерү буенча класстан тыш эшләрнең нәтиҗәле формаларыннан берсе.

Утырышларда язучы, шагыйрь, драматургларыбыз иҗатын өйрәнеп, укучы күңеле туган як, аның хезмәт сөюче халкы, тормыш-көнкүреш вакыйгаларыннан алган тәэсирләр белән байый, горурлык хисләре арта. Бу эшчәнлек өстәмә белем бирү чыганагы буларак та файдалы дип саныйм. Өйрәнү өчен халык күңелендә лаеклы урын алган, мөһим эчтәлекле, бүгенге көндә актуаль булган, эстетик-социаль ихтыяҗларны

кәнәгатьләндерә алырлык яхшы әсәрләр сайлап алынды. Шуның белән бергә программага укучыларны мөмкин кадәр күбрәк язучылар белән таныштыру максатыннан әлегә әз таныш булган яшь язучыларның әсәрләре дә тәкъдим ителә.Укучыга әсәрләрне сайлап алу мөмкинлеге дә тудырыла.

Программада төрле конкурслар, очрашулар да каралган.

Бәйләнешле сөйләм үстерү, сәнгатьлелек, культуралы сөйләм кебек проблемалы мәсьәләләр дә программада урын алган. Шулай ук түгәрәктә шигырь, хикәя язу серләре белән танышкан укучы, дәрестә әсәрләргә анализ ясаганда, үз көченә ышанып, язма эшләр вакытында тел-сүрәтләү чараларыннан иркен файдаланып, иҗади фикерләү сәләтенә бай булуын күрсәтә.

**Максат:**

Татар әдәбиятының матур үрнәкләре ярдәмендә үз-үзенә ышанган, мөстәкыйль эш итә торган, конкурентлыкка сәләтле, дөрес аралашу серләрен белүче, рухи дөньясы бай, иң матур кешелек сыйфатларына ия булган укучылар тәрбияләү.

**Төп бурычлар:**

- татар әдәбиятыннан өстәмә мәгълүматлар бирү;
- олимпиада, бәйгеләргә әзерлек эше алып бару;
- укучыларны иҗат эше белән кызыксындыру, иҗади сәләтен үстерүгә шартлар тудыру;
- әдәби әсәрләр укуга тарту;
- әдәбиятны аңларга, яратырга өйрәнергә ярдәм итү, эстетик зәвык тәрбияләү;
- укучыга үзе теләгән әсәрләр белән эшләргә, эзләнергә, иҗат итәргә юл ачу;
- мәстәкыйль эзләнүгә этәргеч ясау;
- якташ язучылар иҗатын өйрәнү;
- сценарийлар язарга өйрәтү;
- укучыларда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, дине, татар халкының язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистлары, гомумән, күренекле шәхесләрен өйрәнү аркылы туган телгә һәм халкыбызга мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Программаның актуальлеге.**

Күп язучыларның иҗатлары, әсәрләрен өйрәнү мәктәп программаларында урын алмаган яки бик аз бирелгән. Шуны исәпкә алып, “Бәллүр каләм” җыены берләшмәсендә укучыларга өстәмә белем алу мөмкинлеге тудырылды. Бу дәрестән тыш эшчәнлек укучыларга төрле язучыларга багышланган кичәләр үткәрергә ярдәм итә.

Укучыларда бердәмлек, иптәшеңә карата ышаныч һәм хөрмәт үсеш ала. Ә бу исә укучыларга шәхси авырлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм итә, чыгыш ясаганда җаваплылык хисе арта һәм һәр эштә иҗади якын килүне үстерә. Балада үзбәя арта, ул үзен һәркайда иркен хис итә башлый.

**Программаның яңалыгы** шунда: бу берләшмәдә укытучының укучыларга фронталь йогынтысы белән индивидуаль якын килүе, берләшмәдәге һәр укучыга йогынты ясый алуы ярашалар. Һәр бала үз көчен коллектив эшләр белән беррәттән берүзе генә катнашып та сыный ала.

**Үз белемеңне күтәрү формалары:**

- мәдәният яңалыклары белән танышып бару;
- язучылар белән очрашулар оештыру;
- вакытлы матбугат белән даими танышып бару;
- театр, төрле кичәләргә йөрү;
- конференцияләрдә катнашу һәм чыгыш ясау;
- тәҗрибә уртаклашу.

**Ата-аналар белән эш**

Ата-аналар белән элемтәдә тору.

Бәйрәмнәр үткәрү, аларга әзерләнү.

Консультацияләр.

Концертлар.

***Планлаштырылган нәтиҗәләр:***

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- сөйләмнең матурлыгын һәм сәнгатьлелеген сизә алуы – үз сөйләмен камилләштерүгә омтылуы;
- туган иленә, анын теленә, мәдәниятенә мәхәббәт һәм хөрмәт белән карау;
- уку, текст авторы белән диалог коруга кызыксыну;
- әхлакый норма һәм кыйммәтләр системасында ориентлаша алуы, аларны үзендә булдыру;
- үз фикерен белдерә алуга ихтыяж;
- уку эшчәнлегендә үз-үзеңә дөрес бәя бирә алу, үзара дуслык хисен тәрбияләү;
- иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү;
- фикереңне дәллили белү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

***Регулятив УУГ:***

- эшчәнлекнең максатын таба һәм формалаштыра алу, үзеңнең эшчәнлегеңне куелган максатка нигезләнеп төзи алу;
- эшчәнлек барышында гамәлләрнең эзлеклелеген әйтә алу;
- китап белән эшләгәндә үз фаразыңны әйтергә өйрәнү;
- укытучы тәкъдим иткән план белән эшләргә өйрәнү.

***Коммуникатив УУГ:***

- җибәрелгән хаталарны булган белемнәргә нигезләнеп төзәтә алу, башкаларның сөйләмен тыңлый, аңлый алу;
- үз фикерләрен язма һәм телдән рәсмиләштерә алу;
- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый алу;
- текстны сәнгатьле итеп укый алу һәм сөйли белү;
- укучылар һәм укытучы белән һәр эштә килешә алу;
- сөйләмнең диалогик формасы белән эш итә белү;
- хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;
- үз фикереңне һәм карашыңны формалаштыру;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

***Танып белү УУГ:***

- укучыларның укытучы һәм сыйныфташлары белән эшчәнлеккә йогынты ясавы;
- проблемалы биремнәр ярдәмендә укучыларда телне өйрәнүгә кызыксыну уяту;
- китапта (исеме, шартлы билгеләр) ориентлашу;
- китаптан, рәсемнәрдән җаваплар таба алу;
- эшчәнлеккә нәтиҗә ясый алу;
- мәгълүматны эшкәртә, үзгәртә алуы;
- куелган мәсьәләне чишүдә алгоритмны куллана белү;
- язма һәм телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү;
- тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу;
- өлешләрдән бербөтенне төзи, гомумиләштерә белү.

**Курсның уку планындагы урыны**

Бу программа 5-7 сыйныф укучылары өчен төзелде. Дәрестән тыш эшчәнлек атнага бер тапкыр 40 минутлы дәрес итеп үткәрелә. Елга 34 дәрес үткәрү каралган.

**Эшчәнлекнең төрләре:**

- Уен эшчәнлеге
- Танып-белү эшчәнлеге
- Әдәби иҗади эшчәнлек
- Туган якны өйрәнү, туризм юнәлеше

**Кулланыла торган төп метод һәм технологияләр:**

- коммуникатив;
- үстерелешле;
- хезмәттәшлек итү;
- иҗади үсеш;
- проблемалы;
- проект һәм эзләнү технологияләре.

**Эшчәнлекне үткәрү формалары һәм алымнары**

- түгәрәк
- лекцияләр;
- уен элементлары кергән практик дәресләр;
- текстларны уку һәм анализлау;
- мөстәкыйль эшләү;
- сәхнәләштерү;
- проект яклау;
- әңгәмә;
- презентация;
- экскурсия;
- КВН;
- рольле уеннар;
- дискуссия;
- индивидуаль эш;
- группаларда эш;
- иҗади чыгышлар;

- концерт;
- репетиция.

**Һәр дәрес өч бүлектән тора:**

- уен;
- теория;
- практика.

**Балаларның эшчәнлек дәрәҗәсе методлары:**

- *иллюстратив-аңлатмалы* – балалар әзер материалны кабул итәләр һәм үзләштерәләр;
- *репродуктив* – укучылар алган белем һәм күнекмәләрне яңадан кабатлыйлар;
- *өлешчә-эзләнүле* – укучыларның коллектив эзләнүдә катнашулары, куелган бурычны укытучы белән бергәләп чишүләре;
- *тикшеренү* – укучыларның мөстәкыйль иҗади эшләре.

**Эшчәнлек оештыру методлары:**

- *фронталь* – барлык балалар белән берьюлы эшләү;
- *коллектив* – барлык балалар арасында да проблемалы – эзләнү яки иҗади үзара бәйләнеш оештыру;
- *индивидуаль-фронталь* - индивидуаль һәм фронталь эш формаларын аралаштыру;
- *төркемләп* – кечкенә төркемнәрдә эш оештыру ( 2- 7 кеше);
- *парлы* – парларда эш оештыру;
- *индивидуаль* – биремнәрне, проблемаларны индивидуаль рәвештә үтәү.

**Программаның материаль-методик яктан тәэмин ителүе**

Программаны уңышлы итеп тормышка ашыру өчен уңайлы, җиһазландырылган кабинет булуы зарур, (дәресләрне башка аудиторияләрдә дә, мәйданчыкларда да үткәрергә мөмкин).

Рәсемнәр беркетү өчен сыйныф тактасы.

Диапроектор.

Мультимедиа проектор.

Компьютер.

Экран.

Сканер.

Принтер.

Видеокамера.

**Дидактик материал:** картиналар, фотографияләр, портретлар, белешмәләр, фәнни һәм матур әдәбият, таратма материаллар.

**Йомгак ясау формалары:** сорашу, чыгыш ясау, конкурс, эшләрне коллектив анализлау, үзанализ.

**Программаның эчтәлеге**

**1 тема. Бәллүр каләм. Кереш дәрес. (1 сәг.)**

Укучыларны “Бәллүр каләм” утырышларының планы, режимы белән таныштыру. Еллык план кабул итү. Инструктаж үткәрү.

**2 тема. Дәшми торган затлы дусларыбыз.** (1 сәг.)

Нинди китаплар, әсәрләр белән кызыксынуларын ачыклау. Китапларның мөһим урын алып торулары турында әңгәмә. Китап, әсәрләр уку һәм анализлау - ул кабул итү, хәтер, күзаллау, фикер йөртү һәм кичерешләрнең бертуктаусыз хәрәкәтен таләп итүче эш булуы турында диспут.

**3 тема. Без – булачак журналистлар, артистлар.** (1 сәг.)

Истәлекле һәм онытылмас даталарны билгеләү, белешмә бирү. Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, кассетадан чыгышлар карау.

**4 тема. Мәкалә язу осталыгы.** (1 сәг.)

Язучыларның канатлы сүзләрен эзләп табу. Укучыларны мәкалә төрләреннән түбәндәгеләр белән таныштыру: мәкалә - информация, мәкалә - бәяләмә, мәкалә – рәхмәт, мәкалә - сорау, мәкалә - үтенеч. Гипербола, метафора, метонимия, сынландыру кебек төшенчәләрнең теориясен бирү. Мәктәп тормышы турында мәкалә язып карау.

**5-6 тема. Сәхнә серләре.(2 сәг.)**

Сәхнә теленең үзенчәлекләре. Без булачак яшь артистлар.Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Индивидуаль рәвештә җырлар, шигырьләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү. Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар сөйләп карау. Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую.

**7 тема. Татар язучылары белән танышу.(1 сәг.)**

Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Әңгәмә, төрле язучыларның китапларыннан күргәзмә. Сөйләм осталыгын үстерү, сүзлек байлыгын арттыру. Презентацияләр карау.

**8-10 тема. (3 сәг.) Без – Тукай оныклары. Әкияттә кунакта. Проект эше “Әкиятчеләр”.**

Шагыйрь турында белешмә. Виртуаль музейга сәяхәт. Мультфильмнар карау. Тукайның әкиятләр китабын уку. Тукай геройлары катнашында яңа ел бәйрәменә сценарий төзү, әзерлек эшләре алып бару. Мәктәп күләмендә чыгыш ясау.

**11-14 тема. (4 сәг.) Сугыш чоры язучылары: Алиш белән Җәлил. Фатих Кәрим. “Онытырга мөмкин түгел....” сценарий әзерләү.**

Язучы һәм шагыйрьләребезнең иҗатын өйрәнү. Алар турында презентацияләр карау, әсәрләрен аудиоязмаларда тыңлау, анализлау. Әдәбияттагы тоткан урыннарын ачыклау. Сугыш турында язылган әсәрләрне анализлап, дәһшәтле елларның фаҗигасын бар ачысы белән тоемларга омтылу. Сугыш фаҗигасен сурәтләп, Җиңү көненә багышланган сценарий язу. Сценарийны мәктәп сәхнәсендә күрсәтү. Район һәм республика дәрәҗәсендә үткәрелгән конкурсларда катнашу.

**15-16 тема.(2 сәг.) Туган ягымның көчле улы – Фәнис Яруллин. Фәнис Яруллин әсәрләрен өйрәнү.**

Ф. Яруллинның әсәрләрен укып, тел-стиль чараларына бәя бирү, анализлау, гомумиләштерү, әдипнең әсәрләрендә аларның нинди урын алып торуларын күрсәтү. Балалар өчен язган әсәрләрендәге җитди проблемаларны ачыклау. Аның турында мәкалә язу. Хикәя язып карау.

**17-19 тема. (3 сәг.) Нәкый ага Исәнбәт һәм аның олы мирасы. Проект эше “Фольклор”**

XX йөз татар әдәбияты классигы, Татарстанның халык язучысы, драматург, шагыйрь, тел-әдәбият галиме, күренекле фольклорчы Нәкый Исәнбәтнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү. Аның олы мирасы булган фольклор әсәрләренә анализ ясау. “Фольклор” темасына проект эше әзерләү. Аны мәктәп күләмендә яклау.

**20-21 тема. (2 сәг.) Язучыларның кичәләренә әзерлек сценарийлар әзерләү.**

Укучыларны төркемнәргә бүлеп, язучылар белән очрашу кичәләренә сценарийлар төзергә бирү. Һәр төркемгә ярдәм күрсәтү. Мәгълүмат табарга, тапкан материалны бәйләнешле итәргә булышу. Иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү, эшнең нәтиҗәсен күреп шатлану.

**22-23 тема. (2 сәг.) Шәүкәт Галиев һәм Шәвәлидә кунакта.**

Шәүкәт Галиевнең иҗаты белән танышу. Аның шигырьләрен уку, анализлау. И.Юзеев әйткән өч ягын ачыклау. “Беренчесе – кыска формада зур фикерле, уйландыра торган, үзеннән-үзе җыр сораган шигырьләр язучы уйчан, моңлы Шәүкәт; икенчесе – үзенең геройларын йомшак җәеп катыга утыртучы изге ниятле усал Шәүкәт һәм, ниһаять, балаларның шаян табигатен һич тә ясамыйча-нитмичә бирә белгән шаян Шәүкәт.” Аның шигырьләрен сәхнәләштерү.

**24-25 тема. (2 сәг.) Роберт Миңнуллин - замана әдибе.**

Р.Миңнуллин иҗаты белән якыннан танышу. Балалар өчен язган шигырьләрен өйрәнү, уку, анализлау. Шигырь уку конкурсына әзерләнү. Аның иҗаты әдәбиятыбызны көтелмәгән яңа ачышлар белән баетты, өр-яңа образлар, шигъри табышлар, өр-яңа шигъри алымнар алып килде. Балалар шигырендә беренче булып өлкәннәр һәм балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы четерекле проблемаларны калку итеп чагылдыра алды. Моңа кадәр балаларныкы саналмаган темаларны да нәниләр поэзиясенә Р.Миңнуллин кертте. Боларның барысын да укучыларыбызга җиткерә алу.

**26-27 тема. (2 сәг.) Дәрес-проект. Замана шагыйрьләренең шигырьләреннән сценарийлар төзү.**

Бу дәресләрдә алдагы сәгатьләрдә өйрәнелгән шагыйрьләребезнең иҗатын кулланып, укучыларның теләкләре буенча: төркемнәрдә яки берәмләп сценарийлар төзү. Укытучы һәр төркем һәм балага методик ярдәм күрсәтә, юнәлеш бирә. Мөмкин кадәр күбрәк әдәбият кулланыла.

**28-30 тема. (2 сәг.) Туфан Миңнуллин эзләреннән.**

Туфан Миңнуллин иҗаты белән якыннан танышу. Аның әсәрләре нигезендә куелган спектакльләрне карау, сәхнә әсәрләрен уку, анализлау. Театрга бару.

**31-32 тема. (2 сәг.) Яшь язучы Алмаз Гыймадиев һәм аның мавыктыргыч хикәяләре.**

Алмаз Гыймадиевның хикәяләре укып, композицион яктан җыйнак, сюжетлары маҗаралы хәлләргә корылган булуын, аларда балаларның көндәлек тормышта — мәктәптә, шәһәр урамында, авыл болын-кырларында бер-берсенә карата эчкерсез мөнәсәбәтләре, шаянлыклары, характер үзенчәлекләре кызыклы детальләр, тормышчан ва-

кыйга-эпизодлар аша сурәтләнүен ачыклау. Укучылар белән хикәяләрне укып анализлау. Хикәя язып карау.

**33-34 тема. (2 сәг.) Проект-дәрес. Сценарийлар кичәсе.**

Укучылар язган сценарийларны берләшмәдә карау, тикшерү, бәяләү. Йомгаклау дәресе - сценарийларны проект яклау кичәсе итеп мәктәп күләмендә үткәрү. Яхшы дип табылган эшкәртмә-сценарийларны район, республика конференция-конкурсларына тәкъдим итү.

**“Бәллүр каләм” җыены берләшмәсенең календарь-тематик планы**

| № | Тема | Уку эшчәнлеген оештыру формалары һәм алымнары, материаллар | Планлаштырылган нәтиҗә | | Сәгать саны | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Шәхси | Метапредмет | Барлыгы | Теория | Практика |
| 1 | “Бәллүр каләм”. Кереш дәрес. | Әңгәмә, лекция, презентация. | Әңгәмәдә катнашу, сорауларга төгәл җавап бирә белү | Тормышта кулланунын файдасына төшенү | 1 | 1 | |
| 2 | “Дәшми торган затлы дусларыбыз” | Презентация, аудиоязмалар тыңлау. | Матур уку күнекмәләре үстерү | Тыңлау күнекмәләре үстерү | 1 | | 1 |
| 3 | Без – булачак журналистлар. | Лекция. | Фикерләү сәләтен үстерүгә омтылыш | Сөйләм телен баету | 1 | 1 | |
| 4 | Мәкалә язу осталыгы. | Язучыларның канатлы сүзләре | Иҗадилыкка омтылу теләге тудыру | Эш башкару ысулларына һәм шартларына анализ ясау | 1 | | 1 |
| 5-6 | Сәхнә серләре:<br>1.Сәхнә теленең үзенчәлекләре.<br>2. Без булачак яшь артистлар. | Театрлардан өзекләр, презентация | Сәхнә кагыйдәләрен өйрәнү, сөйләм этикеты | Сөйләм телен баету | 2 | 1 | 1 |
| 7 | Татар язучылары белән танышу | Әңгәмә, төрле язучыларның китапларыннан күргәзмә | Әхлакый кагыйдәләргә ориентлаша белү, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | Сөйләм осталыгын үстерү, сүзлек байлыгын арттыру | 1 | 1 | |
| 8 | “Без – Тукай оныклары” | Презентация, видео, әңгәмә; язучы әсәрләре | Уку эшчәнлегендә үз-үзеңә дөрес бәя бирә | Күренекле кешеләр белән танышу, | 1 | | 1 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | алу, горурлану хисен тәрбияләү. | кызыклы фактлар туплау | | | |
| 9 | “Әкияттә кунакта” | Мультфильмнар, Тукайның әкиятләр китабы | Үз фикереңне әйтә белү, төркемнәрдә килешеп эшли белү, иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү, фикереңне дәлилли белү | Сөйләм телен үстерү | 1 | | 1 |
| 10 | Проект эше “Әкиятчеләр” | Сәхнәләштерү сәләрен аңлату | Иҗадилыкка омтылыш тудыру | Әкият | 1 | | 1 |
| 11 | Сугыш чоры язучылары: Алиш белән Җәлил | Теоретик материал, аудиоязмалар тыңлау, әңгәмә. | Тарихка хөрмәт белән карау | Сөйләм осталыгын үстерү, сүзлек байлыгын арттыру | 1 | 1 | |
| 12 | Фатих Кәрим | Кызыклы материаллар, видео. | Сугыш чоры язучыларын барлау | Сөйләм телен үстерү | 1 | | 1 |
| 13-14 | “Онытырга мөмкин түгел....” сценарий әзерләү | Сугыш чоры язучыларының әсәрләре һәм шигырьләре | Күрше белән хезмәттәшлек итү, үзара ихтирам хисләре тәрбияләү | Эш башкару ысулларын һәм шартларын анализлау | 2 | 1 | 1 |
| 15 | “Туган ягымның көчле улы – Фәнис Яруллин” | Материал, презентация | Язучы иҗатын мөмкин кадәр мөстәкыйль анализлау, чор белән бәйләү өчен кирәкле булган тарихи, сәяси һ.б. мәгълүматлар алу | Автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау | 1 | | 1 |
| 16 | Фәнис Яруллин әсәрләрен өйрәнү | Язучының китаплары, әсәрләре | Әхлакый кагыйдәләргә орентлаша белү, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | Сөйләм осталыгын үстерү, сүзлек байлыгын арттыру | 1 | | 1 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17-18 | Нәкый ага Исәнбәт һәм аның олы мирасы | Презентация, китаплар | Язучы иҗатын мөмкин кадәр мөстәкыйль анализлау, чор белән бәйләү өчен кирәкле булган тарихи, сәяси һ.б. мәгъ-лүматлар алу | Тыңлау күнекмәләре үстерү | 2 | 1 | 1 |
| 19 | Проект эше “Фольклор” | Проектның максатын аңлату | Иҗадилыкка омтылу теләге тудыру | Укытучы-ның сорау-ларын аңлап җавап бирә белү | 1 | | 1 |
| 20-21 | Язучыларның кичәләренә әзерлек сценарияләр әзерләү | Китаплар, материаллар | Иҗадилыкка омтылыш тәр-бияләү, эшнең нәтиҗәсен күреп шатлану | Эшләгән эшнең нәтиҗәсе булуга төшенү | 2 | 1 | 1 |
| 22-23 | Шәүкәт Галиев һәм Шәвәлидә кунакта | Әңгәмә | Шәхеснең әх-лакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, әдәбиятка ихти-рамлы мөнә-сәбәт тәрбияләү | | 2 | 1 | 1 |
| 24-25 | Роберт Миңнуллин - замана әдибе | Язучының китаплары, әсәрләре, инстаграм бите | Язучы иҗатын мөмкин кадәр мөстәкыйль анализлау, чор белән бәйле мәгълүматлар алу | | 2 | 1 | 1 |
| 26-27 | Дәрес-проект. Замана шагый-рьләренең ши-гырьләреннән сценарийлар төзү | Туплаган материаллар һәм язучыларның әсәрләре | Иҗадилыкка омтылыш тәр-бияләү, эшнең нәтиҗәсен күреп шатлану | | 2 | 1 | 1 |
| 28-29 | Туфан Миңнуллин эзләреннән | Презентация, видео, әсәрләр | Активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, | | 2 | 1 | 1 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | акыл эшчәнлегенә һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү | | | | |
| 30 | Сәхнә әсәрләрендә кунакта | Видео спектакльләр | Иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү, эшнең нәтиҗәсен күреп шатлану | | 1 | | 1 |
| 31-32 | Яшь язучы Алмаз Гыймадиев һәм аның мавыктыргыч хикәяләре | Презентация, әңгәмә | Шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, әдәбиятка ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү | | 2 | 1 | 1 |
| 33-34 | Проект-дәрес. Сценарийлар кичәсе | Балаларның бер-берсенең чыгышларын тыңлавы, бәяләү | Башкаларның фикерен ишетә һәм аңлый белү | | 2 | 1 | 1 |
| Барлыгы: | | | | | 34 | 14 | 20 |

**Эшчәнлек нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү**

| **Үткәрү вакыты** | **Эшчәнлек төрләре** | **Тикшерү формалары** |
|---|---|---|
| Беренче яртыеллык | Татарстанның күренекле кешеләре, әдәбият белән таныштыру. Әкият һәм Яңа ел кичәсен әзерләү. Конференцияләргә әзерләү һәм аларда катнашу.<br>“Шигырь бәйрәмендә катнашу.<br>Бәйрәм сценарийлары төзү, балалар иҗаты, театр, музейларга сәяхәт. | Эшләрнең күргәзмәләре, ата-аналар, мәктәп коллективы алдында чыгыш ясау, рефератлар конкурсы, КВН, конкурсларда катнашу.<br>Район, республика конференция-конкурсларында чыгыш ясау. |
| Икенче яртыеллык | Бер язучының әсәрен сәхнәгә кую, укучыларның үз иҗатлары, Тинчурин театрына, Г.Тукай музеена сәяхәт, артистлар белән очрашу, спектакльләр карау. Бәйрәм сценарийлары төзү, балалар иҗаты, театр, музейларга сәяхәт. | Төрле дәрәҗәдәге кичә һәм конкурсларда катнашу. Укучылар эшләгән эшләр күргәзмәсе, рефератлар конкурсы, спектакль күрсәтү, конкурсларда катнашу.<br>Район, республика конференция-конкурсларында чыгыш ясау. |

**Нәтиҗәләрне тикшерү өчен түбәндәге формаларны куллану күздә тотыла:**

- программаны үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү картасы (*Кушымта 1*) - 1 яртыеллык һәм 2 яртыеллыкта;
- йомгаклау – һәр бүлекне тәмамлаганнан соң (уен-конкурс, КВН, практик эш, презентация, концерт, сәхнәдә чаралар күрсәтү, конференцияләрдә катнашу һ.б.).

**Программа белән эшләүнең нәтиҗәләре 3 дәрәҗәдә тикшерелә:**

1) Нәтиҗәләрнең беренче дәрәҗәсе — укучының берләшмәдә актив катнашуы.

2) Нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсе — укучының мәктәп күләмендә үткәрелгән чараларда актив катнашуы.

3) Нәтиҗәнең өченче дәрәҗәсе — укучының җәмгыятьтә мөстәкыйль эш итү тәҗрибәсенә ия булуы. (Район, шәһәр, республика күләмендә үткәрелгән чараларда катнаша алуы).

**Кулланылган әдәбият**

Г.Тукай, А.Алиш, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ф.Яруллин, Н.Исәнбәт, Ш.Галиев, Р.Миңнуллин, Т.Миңнуллин, А.Гыймадиевларның басылган китаплары, электрон китапханәдәге, Интернет челтәре сайтларындагы материаллар кулланылды.

**Интернет ресурслар**

http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем полрталы
http://www.mon.tatar.ru
http://pedsovet.org Бөтенроссия интернет-педкиңәшмәсе
http://www.bytik.ru Мәгариф системасында яңа технологияләр куллану – халыкара конференция
http://www.shoolexpo.ru
http://www.it-n.ru
http://. belem.ru
http://. intertat.ruТР электрон газетасы
http://. vatantat.ru “Ватаным Татарстан” газетасы
http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ruon- line русча сүзлеге
http://. Tugan-tel.at.ru Шрифтлар һәм IT- технологияләр
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар
http://. tataroved.ru Татар тарихы: төрки – татар дөньясы
http://. selet.ru “Сәләт” яшьләр үзәге
http://anatele.ef.com/
http://www.balarf.ru/

*Кушымта 1*

**Берләшмәнең нәтиҗәләре_ группа**

| № | Баланың Ф.И. | Программаны үзләштерү дәрәҗәсе | | | | | | | | | | | | | | | | Уңышлары | | | | | Гомуми балл |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Бәяләү критерийлары | | | | | | | | | | | | | | | | Федераль | Республика | Шәһәр | Район | Берләшмә | |
| | | Грамматика | | | | Фонетика | | | | Осталыгы | | | | Шәхси үсеш дәрәҗәсе | | | | | | | | | |
| | | Бик | Югары | Уртача | Түбән | Бик | Югары | Уртача | Түбән | Бик | Югары | Уртача | Түбән | Бик | Югары | Уртача | Түбән | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Бик югары - 4 б федераль уңышлары – 4б берләшмә – 0,5б
Югары - 3 б республика – 3б
Уртача - 2 б шәһәр – 2б
Түбән - 1 б район – 1б

**Берләшмәнең нәтиҗәләре**

Берләшмә исеме ______________________________________________________
Укытучының ФИО ____________________________________________________
Үткәрү вакыты_______________________________________________________
Уткәрелү
урыны_____________________________________________________________
Үткәрү формасы______________________________________________________
Кайсы сыйныф_______________________________________________________
Уку елы____________________________________________________________
Берләшмәдәге бала саны______________________________________________
Диагностика үткәрү вакытында катнашучыларның саны __________________
Диагностика нәтиҗәләре буенча:
Бик югары БОК (ЗУН) (13-16 баллов)__________________(балалар саны)______
Югары БОК (ЗУН) (9-12 баллов)______________________( балалар саны)______
Уртача БОК (ЗУН) (6-8 баллов)_______________________ (балалар саны )_____
Түбән БОК (ЗУН) (4-5 баллов)_________________________( балалар саны)______
Мониторинг __________________________________________
Алардан:
Авыру сәбәпле_______________________________________________________
Китүчеләр___________________________________________________________
Укытучы _______________________________________

## “Милли мирас” дәрестән тыш эшчәнлек программасы (1-4 сыйныф укучылары өчен)

*Галиева Гөлназ Шамил кызы, Казан шәһәре Совет районы Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең беренче категорияле укытучысы.*

Бу авторлык программасы мәктәпләрдә эшләүче башлангыч, татар теле һәм әдәбияты, өстәмә белем бирү укытучыларына тәкъдим ителә.

«Милли мирас» программасы гомуммәдәни юнәлешкә карый.

Программа “Россия Федерациясендә мәгариф турында” федераль законга (29.12.2012 № 273-ФЗ «Об образовании в РФ»), башлангыч белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартларына (Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации 06.10.2009 № 373), Шәхеснең рухи-әхлакый үсеш концепциясенә, Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең гомуми белем бирү программасына нигезләнеп төзелде.

**Аңлатма язуы.**

«Үткәнен белмәгән, милли тәрбия алмаган кешенең киләчәге юк».

Ш.Мәрҗани.

Хәзерге вакытта, мәктәп һәм гаилә алдына, укучыларны тормышта үз урыннарын таба алырга сәләтле итеп тәрбияләү бурычы куела. Югары әхлаклы,

иҗади, эзләнүчән бала гына тормышта үз урынын табып, җәмгыяткә файда китерүче булып формалаша. Танышу, эзләнү, өйрәнү нәтиҗәсендә иҗат итү, сәләтләрне, әдәплелекне үстерү программада милли мирас юнәлешендә корылган.

Бала аңына үз халкының үсеш тарихын, мәдәниятен, милли үзенчәлекләрен, хәзерге көндәге халәтен, дөнья халыклары арасында тоткан урынын, зыялылары, галимнәре, үз төбәгенең тарихы һәм күренекле шәхесләре турындагы мәгълүматны, гаиләсенең «нәсел агачы»н, гореф – гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен үз туган телендә сеңдергәндә генә анда үз милләтенә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләнә, әхлагы ныгый.

“Милли мирас”программасы эшчәнлеге нәтиҗәсендә укучыларның туган телендә сөйләме камилләшә, фәнни-эзләнү эше җайга салына, дәрестә алган белемнәрне гамәлдә куллануы үсә.

Программабыз түбәндәге максат- бурычларны тормышка ашыруны күздә тотабыз.

**Максат:**

Үз милләтенең киләчәген кайгыртучы, тормышта үз урынын таба алырлык, белемле, югары әхлак сыйфатларына ия булган шәхес тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Декоратив-гамәли иҗатның традицион төрләрен, халкыбызның гамәли сәнгатен, кул эшләрен үзләштерү аша милли узаң формалаштыру, буыннар бәйләнешен тәэмин итү;
2. Милли мирасыбызның үзенчәлекләрен өйрәнү аша укучыларны фәнни-тикшеренү эшенә сәләтле һәрьяктан камил шәхес итеп тәрбияләү;
3. Иҗади омтылыш, театр аша милли мирасыбызга хөрмәт, милли горурлык, әхлакый хисләр тәрбияләү, сөйләм телен камилләштерү.

**Төп принциплары:**

- сыйныфта гуманлылык мөнәсәбәтләре урнаштыру;
- халыкчанлык;
- иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү;
- иҗтимагый активлыкны үстерүгә башлангыч юнәлеш бирү;
- эстетик зәвык тәрбияләү;
- ватанпәрвәрлек;
- гомумкультуралылык;
- эзләнүчәнлек, проектлылык.

Программа 4 елга исәпләнгән. 1-4 сыйныф укучылары өчен билгеләнгән сәгатьләр саны 270, атнага 2 сәгать.

**Тематик планда сәгатьләр бүленеше.**

| № | Бүлекләр | Сәгатьләр саны | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | 1 класс | | 2 класс | | 3 класс | | 4 класс | |
| | | | Теория | Практика | Теория | Практика | Теория | Практика | Теория | Практика |
| I | 1.Кереш: куркынычсызлык кагыйдәләре. | 37\|46 | 1<br>13 | 17 | 1<br>10 | 15 | 1<br>9 | 9 | 1<br>5 | 5 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Милли ядкарьләр. (Татар фольклоры. Милли бизәкле кул эшләре. Күренекле кешеләр һәм урыннар.) | | | | | | | | |
| II | Белергә телим! (Эзләнү-тикшеренү, проект эшчәнлеге) | 18\|34 | 1 | 2 | *2* | 5 | 10 | 20 | 5 | 7 |
| III | Иҗат аланы (Иҗади эшчәнлек) | 18\|32 | 1 | 3 | 3 | 6 | 1 | 2 | 13 | 21 |
| IV | Тәүге адымнар (Балалар театры эшчәнлеге) | 25\|56 | 10 | 18 | 7 | 19 | 5 | 11 | 3 | 8 |
| | **Барлыгы:** | **270** | **66** | | **68** | | **68** | | **68** | |

**ФДБС таләбе буенча планлаштырылган нәтиҗәләр.**

**Шәхескә кагылышлы планлаштырылган нәтиҗәләр:**

- татар теленең, татар халкының милли мәдәни кыйммәтләренең шәхеснең һәрьяклы үсешендә ролен, башкарган гамәлеңнең тормышта кирәклеген аңлау;
- милли мирасны милләтнең киләчәген саклаучы чара буларак саклау, өйрәнү, баетуга омтылыш булдыру;
- ана телендә аралашып, нәтиҗәле эшләү, үзгәрешләр кертү; иптәшләреңне тыңлап, үз фикерләреңне җиткерү өчен күзәтеп бәя бирергә сәләт булдыру;
- баланың, алган белемнәрен, гамәлләрен аңлап эш итүе, әдәплелеген арттыруы;
- укучының, башка милләтләр мәдәниятенә хөрмәт, толерантлык сыфатларын аңлы үстерүе;

**Регулятив универсаль уку гамәлләре :**

- үз эш урыныңны, эшчәнлегеңне оештыра белү;
- эшчәнлегеңне планлаштыру, контрольдә тоту, кимчелекләрен төзәтү, үзгәртә алу;
- уңыш-уңышсызлыкларның сәбәбен анализлау, үзбәя;
-иҗади, декоратив - гамәли эшчәнлекне отышлы итергә булышучы җайланмалардан, ысул, алымнардан файдалана белү;

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре :**

- кирәкле мәгълүматны кирәкле чыганаклардан аерып алу;
- кирәкле мәгълүматны эзли белү, аны кирәгенчә үзгәртә алу, шуңа нигезләнеп үзеңнекен булдыру;
- эзләнү эшчәнлеге аша мирасны тулырак аңлау, баету,саклау;

- эшчәнлеген өлге, карта, модель, схемаларны кулланып оештыру, чагыштырып эш алымнарын өйрәнү;
- милли мирасның төрләре белән танышып, белемнәрне кулланып карау нәтиҗәсендә эстетик зәвыкны, милли культураны үстерү;
- милли кием, милли бизәк, кул эшләре, милли ризык үзенчәлекләрен, осталарның эшчәнлеген өйрәнү, үзләштерү аша, сөйләмне камилләштерү. Максатчанлык, төгәллек, хезмәт сөючәнлек сыйфатларын үстерү;
- чараларда, очрашуларда катнашып, театрда төрле образларны уйнап яхшы һәм начар сыйфатларны , гамәлләрне аерырга өйрәнү;
- хәтер, уйлау, тоемлау, хыяллану, уйлап табу күнекмәләрен үстерү;

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- парда, төркемдә, күмәк эшләрдә аңлашып эшләү күнекмәсен үстерү;
- сөйләгәнне аңлап, үз фикереңне аңлаешлы итеп җиткерү;
- сорау куя һәм сорауга җавап бирә белү, эшләгән эшең хакында кызыклы итеп туган телдә иркен сөйли алу;
- ярдәм итү һәм ярдәм сорый алу;
- төрле фикерләрне түземлек белән тыңлый, үз карашыңны җиткерә, хөрмәт белән аралаша белү;
- аралашу процессында аралашу максатын аңлап сөйләм төзү;
- иҗади һәм эзләнү эше нәтиҗәләрен иптәшләреңә тәкъдим итү, яклау, дәлилләү күнекмәсен үстерү;
- театрда төрле образларның аралашуын күзәтеп, ягымлы сөйләм күнекмәләрен формалаштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү өчен тәкъдим ителгән эшчәнлек төрләре һәм формалары.**

<table>
<tr><td></td><td colspan="3">Класстан тыш эшчәнлек нәтиҗәләре</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек төрләре</td><td>Беренче дәрәҗә</td><td>Икенче дәрәҗә</td><td>Өченче дәрәҗә</td></tr>
<tr><td></td><td>Белем һәм тәрбия бирү формалары</td><td>Белем һәм тәрбия бирү формалары</td><td>Белем һәм тәрбия бирү формалары</td></tr>
<tr><td rowspan="3">1. Танып белү</td><td>Танып белүгә корылган утырыш-лар, әңгәмәләр, викториналар. Экс-курсия, очрашу.Укытучы оештыр-ган гади эзләнүләрдә катнашу.</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Түгәрәк өстәл, диспут, (төркемле, парлы, рольле ) фикер алышу, анкеталар уздыру.Укытучы җитәкчелегендә күмәк эзләнү эше.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Баларның эзләнү проектлары, конференцияләр, олимпиада”Без булдырабыз”,”Алиш варислары” мәктәп-музее, ”Милли мирас” класс – музей клубы.</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| ***2. Уен*** | Балалар уеннары, укытучы оештырган милли уеннар Санамыш, такмак әйтү. Парлы, күмәк җырлы-биюле уеннар, ”Зәлидә” уеннары. Йола уеннары. | | |
| | Анкета алу, мәгълүмат туплау, иҗади сәләтне үстерүгә юнәлгән, укытучы оештырган эшлекле уен. “Май канаты нишли белә?”,” Нигә, нилектән?”һ.б | | |
| | Укучыларның милли уеннарны заманча төсмерләр белән баетуы. (Уеннарга яңа бирем, җәза, ярыш төрләре өстәүләре) Башка класс укучылары, әти-әниләр белән күңел ачу, таныту, белү өчен балалар бергәләп оештырган милли түгәрәк уеннары. Чыгышны сыйфатлы итү өчен балалар куллана алган театраль уен-күнегүләр. | | |
| ***3. Хезмәт эшчәнлеге*** | Татар халкының һөнрчелегенә караган кайбер эш юнәлешләрен: өлге ясау, төшерү, кисү, ябыштыру, әвәләү,тоташтыру, тегү,чигү, кырып-көйдерү күнекмәләренә өйрәтү дәресләре. | | |
| | Бердәм күмәк эшләр. Башка балаларга, әти-әниләргә чыгыш күрсәтү өчен кирәк булган инвентарьларны (Укытучы җитәкчелегендә үзен һәм үзенә кирәкле курчакны киендерү, казлар тегү,агачлар ясау, иске киемнәрне ямау, кыскарту Һ.б.) әзерләү. | | |
| | Ятим балалararга ярдәм акциясе, ярминкәләр , туганнарга бүләк өчен өйрәнгән алымнардан файдаланып кул эшләре ясау. | | |
| ***4. Иҗади эшчәнлек*** | Сәләтләрне күрсәтү өчен бәйрәм, бәйге, кичәләр.<br>Милли бизәкне тану, башка милләт бизәкләреннән аеру, төс сайлау, кием предметларны үзеңчә бизәү күнекмәләрен үстерү.<br>Каллиграфия, композиция, буяү кагыйдәләрен өйрәнү. Рифмалы-рифмасыз әсәрләр иҗат итү, мәкалә язу, сценарий төзү алымнары белән танышу дәресләре. | | |
| | Күргәзмәләр, татарның күренекле кешеләре белән очрашулар, осталардан мастер-класслар.”Халыклар дуслыгы йорты”ндагы чыгышка укытучы җитәкчелегендә милли иҗади эшләрне туплау, темасына карап яклауга әзерләнү.Укытучы җитәкчелегендә әсәр, | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мәкалә, пьеса язып карау.<br>“Туган як чишмәләре” күмәк ясалган иҗади картина.<br>“Тәүге адымнар” балалар театры эшчәнлеге. | | |
| | “Яшь дизайнерлар” күргәзмәсе. ”Яшь иҗатчылар” әсәр, мәкаләләрен газеталарда бастыру, ”Яшь журналистлар”ның радио-телевидениядә чыгыш ясаулары. ”Илһам”бәйгесендә, конференция, олимпиадаларда катнашулары.<br>“Сәйәр” балалар театрлары, ”Түгәрәк уен” фольклор фестивальләрендә,”Мин татарча сөйләшәм” социаль проектта катнашу. Башлангыч сыйныфларга, эти-әниләргә спектакльләр кую . | | |
| ***5.Туган якны өйрәнү, социаль эшчәнлеге.*** | Экскурсия, поход. Экспонат белән танышу дәресе. | | |
| | Фәнни эзләнү, сораштыру, чагыштыру, анализлау, (“Чишмәләр коелар тарихы”,”Нәселемнең чигүле мендәрләре”,”Шәҗәрә,”Каз өмәсе”,”Гаиләмдә сугышта катнашучылар”,”Татарның батыр уллары” һ.б.) | | |
| | Социаль проектларда катнашу, экспонатлар туплау ”Табылдык” акциясе. Чемоданда сугыш темасына “Татарның батырлары” музее төзү. ”Милли мирас“ музеен ачу. ”Алиш варислары” музееннан файдалану. Альбомнар, видеоязмалар, чыганаклар каталогы төзү. | | |

**Отчет формалары:** күргәзмә, конкурс, бәйрәм, спектакльләр, конференцияләр, социаль һәм иҗади проектлар, портфолио.

**Программаның эчтәлеге**

Программа дүрт бүлектән тора. Эш төре, оештыру формалары, юнәлешләре белән аерылып торган дүрт бүлек бер максатка юнәлгән. Бүлекләр эчтәлеге ягыннан бер берсенә бәйләнеп, бер-берсен тулылындырып кызыксыну уята.Танышу, өйрәнү, ныгыту, күбрәк белергә теләү, эзләнү, табышың турында сөйләү, балаларга эшләү өчен этәргеч бирсә, күмәк тырышлык белән туган соңгы нәтиҗә канәгатьлек хисен тудыра.Уку елы азагында белгәннәрне, ачышларны, иҗади эшләрне кулланып бердәм иҗат ителгән театраль чыгыш елдан ел камилләшә бара, ата-аналарга, башка класс укучыларына да бик ошый.Укучылар белгән, аңлаган табышларын, фикерләрен теләп сәхнә аша башкаларга җиткерә.

**“Милли мирас”**

1 нче сыйныф программасының эчтәлеге.

Шөгыльләнүнең беренче елында эшчәнлек укучыларны кызыксындыруга, гади эш кораллары, эш алымнары куллануга, эш урыныңны оештыра, тәртиптә тота белергә өйрәтүгә, татар халкының милли мирасы белән таныштыра башлауга юнәлтелә. Милли мирасның нигезен тәшкил итүче халык авыз иҗаты әсәрләре турында белемнәр халык уеннарында ныгытыла, фольклор юнәлешендә эшләүчеләр белән очрашуларда укучыларда кызыксыну арта, сорауларга җавап эзләүгә, үзеңнең сәләтеңне күрсәтүгә теләк уяна. Милли бизәккә нигезләнгән иҗади хезмәт һәм театраль чыгыш- ал-

ган белемнәр нәтиҗәсе булып балаларда милли горурлык, ватанпәрвәрлек, әхлакый сыйфатлар тәрбияләнүгә җирлек тудыра.

**Кереш: куркынычсызлык кагыйдәләре -1сәгать**

Музейның милли бер экспонатына бәйле проблемалы сорауны чишү барышында, эш юнәлеше, кирәкле материал, эш кораллары, чыганаклар белән танышу, куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәнү.

**Милли ядкарьләр -30 сәгать**

*1. Халык авыз ижатына хас төп үзенчәлекләр.*

Теория. Халык авыз иҗаты турында төшенчә бирү. Халык әдәбияты, халык авыз иҗаты, фольклор терминнарын аңлату.

Практика. Коллектив иҗат нәтиҗәсе булуга төшенү. Телдән бергәләп “Мәктәп кыңгыравы” әкиятен уйлап чыгару.

*2. Санамышлар һәм сынамышлар.*

Теория. Санамышлар һәм сынамышлар белән танышу. Аларның уртаклыгы һәм аермасы. Куллану урынын ачыклау. Презентация буенча фикер алышу.

Практика. Санамышларны яттан сөйләп карау (кече төркемдә). Аларны файдаланып татар балалары уеннары өйрәнү (күмәк).

*3. Такмаклар, такмазалар*

Теория. Такмак һәм такмазалар белән танышу. Татар телендә такмак һәм такмазаларның тоткан урынын ачыклау.

Практика. Гаилә әгъзаларыннан, туганнардан такмаклар өйрәнеп килеп сыйныфта сөйләү.Такмаклы уеннар өйрәнү.

*4. Табышмаклар һәм тизәйткечләр .*

Теория.Табышмаклар һәм тизәйткечләр белән танышу. Аларның әһәмиятен ачыклау. Аермаларын табу.

Практика.Тизәйткечләр әйтү ярышы. Бирелгән предметка телдән табышмак уйлап чыгару, башкаларга әйтү, аларның җавабын кабул итү, төзәтү, дәлилләү (парлы иҗади эш).

*5. Мәкаль-әйтемнәр иле.*

Теория. Мәкаль һәм әйтемнәргә билгеләмә. Мәкаль-әйтемнәрнең тематик төркемнәре. Аларны өйрәнү.

Практика. Уен “Мәкаль-әйтемнәр иле” (төркемнәрдә). Күрсәтелгән темалар буенча мәкальләр әйтү. Мәкальләр буенча викторина сорауларына җавап бирү.

*6. Татар халык җырлары.*

Теория. Җырларның тематик төркемнәре. Җырлардагы традицион образлар. Бүгенге көндә дә популяр булган халык җырлары. Халык җырларының автор җырларыннан аермасы. Башка халыкларның җырлары белән охшашлыгы.

Практика.Татар, рус, чуваш, инглиз телендә бишек җырлары тыңлау, видео карау. Шаян җырлар, җырлы уеннар өйрәнү (кара-каршы).

*7. Халыкчан юнәлештә иҗат итүчеләр.*

Теория. Халыкчан юнәлештә иҗат итүчеләр белән танышу-очрашу. (А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор халык авыз иҗаты төркеме белән аралашу.) Чыгышларын карау. Халык җырлары , уен кораллары, киемнәре тарихын тыңлау.

Практика. Татар халык уен кораллары белән якыннанрак танышу, тотып, уйнап карау. Музыкаль белем алу түгәрәкләре белән танышу, язылу.

*8. ”Зәлидә” уеннары.*

Теория.Уеннарның төрләре.Уенны оештыру урыны, әһәмияте.Уен кагыйдәләре.

Практика.Уеннарны өйрәнү. Алган белемнәрне (санамыш, сынамыш, такмак, такмаза, мәкаль-әйтем, уен җырларын) уен барышында куллану, бию элементларын башкару (күмәк).

*9. Милли бизәкләр.*

Теория. Татар халкының киемнәрендә милли бизәкләр. Милли бизәкләр белән танышу. Аларның килеп чыгышы, әһәмияте, кулланылышы. Орнамент төшенчәсе.

Практика. Төс сайлау, бизәкләрдән композиция ясау. (Төркемдә) Куркынычсызлык кагыйдәләрен кабатлап бизәкне төшерү, буяу, әвәләү (парда). Төшерү ысуллары. Буяу төрләре. Яссылыкта күпертмәле, яссы элементларны беркетү алымы.Тулы милли бизәк җыю. Күргәзмә ясау.

*10. Картоннан түбәтәй ясау.*

Теория. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Эш кораллары, күрсәтмә карта, түбәтәй үрнәкләре, таблицалар белән эшләү алымнары. Математика дәресләрендә алган белемнәрне куллана белү, игътибарлылык, төгәллек күнекмәләренең кирәклеген аңлату. Төшерү, кисү, ябыштыру кагыйдәләрен искәртү. Композициядә симметрия и асимметрия төшенчәсе.

Практика. Түбәтәйне эзлекле рәвештә ысул кулланып ясау, бизәкләрне композиция таләпләренә туры китереп сайлау, төшерү, кисү, ябыштыру.Түбәтәйләрне этиләр көненә бүләк итү.

**Белергә телим! - 3 сәгать**

Татар исемнәре.

Проблемалы ситуация тудыру: Кәгазь курчакка кәгазьдән милли киемнәр кидерү. (“Салават күпере” журналы)

Аңа нинди исем кушарга? Теория.Татар исемнәре. Аңлатмасы. Хәзер һәм элеккеге татар исемнәре .

Практика. Курчакка исем кушу. Нигә кушканыңны аңлатып сөйләү. (шәхси, теләк буенча)

**Иҗат аланы - 4 сәгать**

*1. Мин - татар баласы!*

Иҗади эш. “Туган телемдә сөйләшәм, туган телемдә җырлыйм. Әдәпле дә, инсафлы да - татар баласы бит мин!” темасына эти-әниләр ярдәме белән, өйрәнгәннәрне, алган белемнәрне кулланып чыгышлар әзерләү. (Бәйге, концерт, бәйрәм, газета-журнал чыгаручылар белән очрашу һ.б формада проектны йомгаклау.) Туган телдә бәйләнешле сөйләмне үстерү, сүзлек байлыгын арттыру.

**“Тәүге адымнар” театр коллективы - 28 сәгать**

*1. Күркәм сыйфатлар.*

Теория.Татар халкының күркәм сыйфатлары. Әдәплелек темасына әңгәмә.

Практика. Хайваннарның тавышын тыңлау, сыйфатларын билгеләү. Хайваннар турында татар мультфильмнарын карау. Фикер алышу.

*2. Сөйләшә торган йомшак уенчыклар.*

Теория. Сөйләм төрләре: диалог һәм монолог. Күмәк күренешләр.

Практика. Төрле хайваннарны –йомшак уенчыкларны татарча әдәплелек темасына сөйләштерү. Театраль уен.

*3. Әкият-пьеса .*

Теория.А.Алишның”Сертотмас үрдәк” әкиятен уку. “Сертотмас үрдәк”спектаклен карау .Әкият һәм пьеса.

Фикер алышу.

*4. Курчаклар театры .*

Теория. “Тәртипсез тиен” әсәре белән танышу. Төп фикерне аңлау. Рольләр бүлешү. Сөйләм культурасы. Тизәйткечләрнең роле.

Практика. Курчак театры чыгышына әзерлек:

-курчакларны табу, киендерү;

-репликаларны өйрәнү;

-милли биюле уеннарны, җырларны кабатлау, айлап алу, ирекле яңаларын өйрәнү, спектакльгә кертү;

-музыкаль бизәлеш;

-сәхнәне бизәү, урман аланы ясау, куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерү (Ясау, кисү, ябыштыру);

-сәхнә арты, суфлер;

-чыгышның видеосын карау. Театрдагы кимчелекләр, җитешсезлекләр, охшамаган урыннарны төзәтү, үзгәртү. Үзбәя;

-“Тәртипсез тиен”не башлангыч сыйныф укучыларына, әти-әниләргә күрсәтү. Конкурсларда чыгыш ясау. Күмәк эшләү күнекмәсен ныгыту.

Йомгаклау. Балаларның әдәплелек һәм өйрәнгәннәренә кызыксынулары дәрәҗәсен билгеләүче анкета нәтиҗәләре буенча әңгәмә. Коллектив уңышларыннан портфолио төзү.

## Тематик план.

| № | Бүлекләр һәм темалар. | Сәг.саны. | Теория | Практика |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес.Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 1 | 1 | |
| 2 | **Милли ядкарьләр.** Санамышлар һәм сынамышлар. | 2 | 1 | 1 |
| 3 | Татар балалары уеннары. | 1 | | 1 |
| 4 | Такмаклар, такмазалар. | 2 | 1 | 1 |
| 5 | Такмаклы уеннар. | 1 | | 1 |
| 6 | Табышмаклар һәм тизәйткечләр. | 2 | 1 | 1 |
| 7 | Уен “Мәкаль-әйтемнәр иле”. | 2 | 1 | 1 |
| 8 | Татар халык җырлары. | 3 | 1 | 2 |
| 9 | Халыкчан юнәлештә иҗат итүчеләр. (А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге дәүләт | 3 | 2 | 1 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | фольклор ансамбле,”Сорнай” фольклор төркеме һ.б.) | | | |
| 10 | “Зәлидә” уены. | 3 | 1 | 2 |
| 11 | Татар халкының киемнәрендә милли бизәкләр. | 1 | 1 | |
| 12 | Милли бизәкләр.<br>Төс сайлау, бизәкләрдән композиция ясау. | 4 | 2 | 2 |
| 13 | Милли бизәкләрне буяу, төшерү, әвәләү.<br>Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 2 | 1 | 1 |
| 14 | Композициядә симметрия и асимметрия төшенчәсе. | 1 | 1 | |
| 15 | Картоннан түбәтәй ясау, бизәү.<br>Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 3 | | 3 |
| 16 | **Белергә телим!**<br>Кәгазь курчакта да милли киемнәр.<br>Татар курчагына нинди исем кушарга? | 3 | 1 | 2 |
| 17 | **Иҗат аланы**.<br>Туган телемдә сөйләшәм, туган телемдә җырлыйм,<br>Әдәпле дә, инсафлы да- татар баласы бит мин! | 4 | 1 | 3 |
| 18 | **“Тәүге адымнар”балалар театры.**<br>Татар халкының күркәм сыйфатлары | 2 | 1 | 1 |
| 19 | Сөйләшә торган йомшак уенчыклар. | 2 | 1 | 1 |
| 20 | “Серле сәхнә”<br>Курчак театры артисты белән очрашу. | 4 | 2 | 2 |
| 21 | “Без - курчак театры артистлары”<br>Курчак театры чыгышына әзерләнү. | 16 | 5 | 11 |
| 22 | “Тәртипсез тиен” спектаклен кую.<br>”Тәүге адымнар” портфолиосын төзү. Йомгаклау. | 4 | 1 | 3 |
| | **Барлыгы** | **66** | **25** | **41** |

## “Милли мирас”

2 нче сыйныф программасының эчтәлеге

Шөгыльләнүнең икенче елында эшчәнлек укучыларны өйрәнгән күнекмәләрне ныгыту, белемнәрне куллана белүгә, катлаулырак схема-модельләрне, үрнәк өлгеләрне төзеп, яңа эш алымнарын үзләштерүгә, татар кул эшләре өйрәнелә, яңа халык уеннарында ныгытыла. Милли бизәккә нигезләнгән иҗади хезмәт зләнү эшчәнлегендә мөстәкыйльлек артуга китерсә, театраль чыгыш - милли театр сәнгатенең ролен, актер, режессер, сәхнә культурасы, иҗат коллективлары дигән төшенчәләрне аңлап тормышка ашырылган сыйфатлы күмәк эшчәнлек күрсәткеченә әйләнә.

**Кереш: куркынычсызлык кагыйдәләре - 1 сәгать**

Бу уку елында эш юнәлеше, кирәкле материал, эш кораллары, чыганаклар белән танышу, куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәнү.

## Милли ядкарьләр - 25 сәгать

***1.** Татар милләтендә матурлык, затлылык нурлары.*

Теория. Казан милли музеена сәяхәт. Татар халкының бизәнү әйберләре белән танышу. Яка чылбыры, йөзек, беләзек, хәситә, кылыч кыны һ.б.

Практика. Милли уен “Йөзек салыш”, ”Бу кемнеке?” (Кемнең беләзеге? Һ.б)

*2. Татарларның көндәлек киемнәре, аларны бизәү.*

Теория. Татар халкының көндәлек киемнәре белән танышу. Ак түбәтәй һәм ак яулыкка бизәк төшерү, атлатып чигү, гади төен ясау, бизәкне композиция таләпләренә туры китереп эшләү алымнары, моделе белән танышу. Куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерү.

Практика. Эш урынын оештыру. Милли бизәкләрне, төсләрне сайлап алу, композицияне үзеңчә тулылындыру, үзгәртү. Өлге ясау. Җеп, сәйләннәрне беркетү, чигү алымнарын карап, чагыштырып, әзер ак яулык һәм ак түбәтәйгә бизәкне төшерү, чигү. Эшне адымлап, эзлекле рәвештә башкару. «Орнамент» төшенчәсен аңлау. Бизәк элементларын дөрес тоташтыру, эстетик таләпләрне төгәл үтәү. Чиккән яулык, түбәтәйләрне киеп түгәрәкле уены ”Кульяулык”, “Гөлбану”ны өйрәнү. “Зәлидә” уеннарын балаларның заманча төсмерләр өстәп башкаруы.

*3. Татар халкының чисталыгын һәм пөхтәлеген чагылдыручылар.*

Теория. Чисталык, пөхтәлек ,көязлек, ”ыспайлык” төшенчәләре. Викторина. “Билбау һәм алъяпкыч нигә кирәк?”

Практика. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Билбау һәм алъяпкыч тегергә өйрәнү, бизәк төшерү, чигү. Тукыма төрләрен карау, сайлау. Тегү алымнары белән танышу. Кул белән тегү. Фасон сайлау. Үлчәм алу. Өлге сызу. Әзер өлешләрне тоташтыру, тегү. Милли бизәк төшерү, сәйләннәр белән чигү. (Өйрәнгәнне ныгыту) Әзер алъяпкыч, билбауларны киеп татар халкының парлы биюен өйрәнү. Хәрәкәт төрләре, көйгә карап хәрәкәт үзгәреше.

## Белергә телим! - 7 сәгать

“Минем шәҗәрәм”. Эзләнү проекты.

Проблемалы ситуация тудыру: Туганнарыгыз арасында танылган кешеләр бармы? Кем ягыннан туган? Сез аңа кем дип дәшәсез, ни өчен ? сорауларына җавап эзләү.

Теория. Шәҗәрә төшенчәсе белән танышу.Туганлык, нәсел сүзенең мәгънәсен аңлау. Шәҗәрә ясау алымнары, терәк схемалар, туганлык атамалары таблицасы.

Практика. Нәсел агачы ясау, бизәү, язу. Шәҗәрәңне яклау. Күренекле туганнар хакында сөйләү. Күргәзмә. Конференция.

## Иҗат аланы – 9 сәгать

Милли мирас сакчылары. Рәссамнар.

Теория. Милли рухлы иҗат. Татар рәссамы белән очрашу. Аппликация һәм рәсем ясау алымын берләштерү. Каллиграфия төшенчәсе.

Практика. Күмәк иҗат. Куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерү. Эш урынын, эш коралларын әзерләү. “Туган як чишмәләре” картинасын ясау. Төрле чишмәләрнең фотоларын карап архитектура, милли бизәкләр, симметрия үзенчәлеген саклап рәсем, оригами, аппликация алымнары белән яссы формадагы чишмәне ясау, кисеп алу. Зур кәгазьгә әзер

чишмәләрне ябыштыру, араларын сукмаклар белән тоташтыру, елга-күлләр ясау. Төс сайлау, буяу. Бизәү: суга үрдәк-казлар, сукмакларга су ташучы милли киемле, чиләкле кешеләр, печән чабучы егетләр, агач, куак,чәчәкләр, хайваннар һ.б. кисеп ябыштыру; каллиграфия хакындагы белемнәрне кулланып, һәр чишмәнең исемен язып кую, беркетү. ”Туган як чишмәләре” н күргәзмәгә кую, конкурсларга җибәрү. Теләгән сәләтле балалар өчен шәхси юнәлеш - ”Чишмәләр һәм коелар тарихы”эзләнүе, проектны яклау, конференциядә чыгыш ясау.

**“Тәүге адымнар” театр коллективы - 26 сәгать**

*1. Театраль коллективлар.*

Теория. Яшь тамашачылар театрында кунакта булу. Аларның исемнәре, афиша, чакыру кәгазьләре белән танышу.

Практика. Иҗади бәйге: ”Театраль коллектив исеме”, ”Иң кызыклы афиша”, ”Иң отышлы чакыру кәгазе”, ”Иң яхшы программа” Һ.б.

*2. Сәхнә серләре.*

Теория. Кеше образлары. Тискәре һәм уңай геройларны уйнау серләре.

Практика. Ритмопластика. Театраль уен, дикцияне яхшыртуга күнегүләр.

*3. Спектакль куюга әзерлек.*

Теория. ”Кара чишмә буенда”әсәре белән танышу. Төп фикерне аңлау. Рольләр бүлешү. Репликаларны өйрәнү. Сөйләм культурасы. Мимика. Жест. Хәрәкәт. Ел дәвамында алган белемнәрне кулланып театрның эчтәлеген, музыкаль бизәлешен үзгәртү, тулылындыру. Курчак һәм кеше образларын уйнау алымнарын берләштерү.

Практика. Репетицияләр. Сәхнәне куркынычсызлык кагыйдәләрен белеп эшләнгән бизәлеш белән тулылындыру. Арткы-алгы план төшенчәсен аңлап, хәрәкәт юнәлешен сайларга өйрәнү. Сәхнә артындагы тәртипнең мөһимлеген тану. Узара ярдәмләшүне ныгыту. Чыгышның видеосын карау. Театрдагы кимчелекләр, җитешсезлекләр, охшамаган урыннарны төзәтү, үзгәртү һ.б. Үзбәя. Спектакльне башлангыч сыйныф укучыларына, эти-әниләргә күрсәтү. ”Сәйәр “ татар балалар театр фестивалендә катнашу. Башка коллективларның эшчәнлеген күзәтү. Чагыштыру, анализлау. Портфолионы тулылындыру.

**Тематик план**

| № | Бүлекләр һәм темалар. | Сәг.саны. | Теория | Практика |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш.Куркынычсызлык кагыйдәләре.. | 1 | 1 | |
| 2 | **Милли ядкарьләр.** Татар милләтендә матурлык, затлылык нурлары. Казанның Милли музеена сәяхәт. | 2 | 2 | |
| 3 | Татар халкының бизәнү әйберләре : хәситә,чулпы, яка чылбыры һ.б | 1 | 1 | |
| 4 | Милли уеннар: “Йөзек салыш”,”Бу кемнеке?” | 1 | | 1 |
| 5 | Татарларның көндәлек киемнәре, аларны бизәү. | 1 | 1 | |
| 6 | Түбәтәй һәм яулыкларны бизәк төшереп, сәйлән мәрҗән белән чигү. | 6 | 2 | 4 |
| 7 | Чиккән яулык, түбәтәйләрне киеп түгәрәкле уены ”Кулъяулык”, .“Гөлбану”ны өйрәнү. | 1 | | 1 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Татар халкының чисталыгын һәм пөхтәлеген чагылдыручылар.<br>“Билбау һәм алъяпкыч нигә кирәк?”, викторина. | 1 | 1 | |
| 9 | Билбау һәм алъяпкыч тегәргә өйрәнү. | 5 | 2 | 3 |
| 10 | Билбау һәм алъяпкычка бизәк төшерү, чигү.<br>“Без булдырабыз!” мәктәп, район, шәһәр олимпиадасында катнашу. | 5 | 1 | 4 |
| 11 | Үзләре милли киемнәрдән татар халкының парлы биюләрен өйрәнү. | 1 | | 1 |
| 12 | “Зәлидә” уеннарын балаларның заманча төсмерләр өстәп башкаруы. | 1 | | 1 |
| 13 | **Белергә телим!**<br>“Минем шәҗәрәм”. Эзләнү эше. | 5 | 2 | 3 |
| 14 | Шәҗәрәне ясау, яклау. | 2 | | 2 |
| 15 | **Иҗат аланы**<br>“Милли рухлы иҗат” рәссамнар белән танышу, очрашу кичәсе. | 1 | 1 | |
| 16 | Аппликация һәм рәсем ясау алымын берләштерү. Каллиграфия. | 2 | 1 | 1 |
| 17 | “Туган як чишмәләре” картинасын ясау. Татарстандагы чишмәләрне күпертеп яссылыкта ясау, кисеп алу. | 3 | 1 | 2 |
| 18 | Зур кәгазьгә әзер чишмәләрне ябыштыру, буяу. | 1 | | 1 |
| 19 | Картинаны язу күрсәткечләр, чишмә исемнәре белән бизәү, яклау. | 2 | | 2 |
| 20 | **“Тәүге адымнар” балалар театры.**<br>Яшь тамашачылар театрына сәяхәт | 2 | | 2 |
| 21 | Театраль коллективларның тормыш-яшәеше. | 1 | 1 | |
| 22 | Иҗади бәйге: ”Театраль коллектив исеме”, ”Иң кызыклы афиша”,”Иң отышлы чакыру кәгазе”, ”Иң яхшы программа”. | 2 | | 2 |
| 23 | Кеше образлары. Тискәре һәм уңай геройларны уйнау серләре. Мимика, жест. | 3 | 1 | 2 |
| 24 | Ритмопластика.Театраль уен, дикцияне яхшыртуга күнегүләр. | 1 | | 1 |
| 25 | ”Кара чишмә буенда”пьесасы белән танышу. Курчак һәм кеше образлары. | 3 | 2 | 1 |
| 26 | Спектакль куюга әзерлек. | 9 | 2 | 7 |
| 27 | Спектакльне кую. ”Тәүге адымнар” портфолиосын тулылындыру. | 4 | | 4 |
| 28 | Йомгаклау. Башка балалар коллективлары | 1 | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эшчәнлеге. | | | |
| | Барлыгы | 68 | 23 | 45 |

**“Милли мирас”**

3 нче сыйныф программасының эчтәлеге.

Шөгыльләнүнең өченче елында эшчәнлек фәнни – эзләнү аша милли мирас белән танышуны дәвам итүгә юнәлгән. Проект эшенең асылын, этапларын, эш алымнарын аңлап башкарылган эзләнү эше халык авыз иҗатын, кул эшләрен үзе теләп өйрәнү, чыганаклардан файдалана белү, мөстәкыйль рәвештә сорауларга җавап табу, фикерне дәлилләү яки кире кагу кебек күнекмәләрне үстерергә булыша. 1-2 классларда өлкәннәр ярдәме белән башланган гади эзләнүләр эзлекле эшчәнлек-проектларга әйләнә, проект нәтиҗәсе театрда чагыла. Тәкъдим ителгән эш формалары, алган белемнәрне куллану белән бергә укучыларда аларны арттыру, хакыйкатьне табу, аңлы кызыксыну, күзәтүчәнлек, эзләнүчәнлек, материалны анализлау, бәяли белү, нәтиҗәле эшчәнлек алып баруны да ныгыта.

**1. Кереш: куркынычсызлык кагыйдәләре - 1 сәгать**

Бу уку елында эш юнәлеше, кирәкле материал, эш кораллары,чыганаклар белән танышу, куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәнү.

**Белергә телим! – 30 сәгать**

1. Проект эшчәнлегенә кереш.

Теория. 1-2 класста өйрәнгәннәрне искә төшерү. Милли йолалар, бәйрәмнәр, өмәләр.
Практика. ”Мин беләм” уены аша укучыларның йола-бәйрәмнәр белән танышлыгын тикшерү. Анкета уздыру. Күп укучыларга таныш булмаган яки исеме генә билгеле бәйрәм, өмәне сайлап алу.

2. Проект эшчәнлеге этаплары:

1 этап. Проблемалы ситуация, сорау тудыру.
Теория. Каз өмәсе нәрсә соң ул? Сорауга җавап табу эшенең максатын, бурычларын билгеләү. Шул максатка ирешү өчен эш юнәлешләрен, җаваплы кешеләрне, эш баш-карылу вакытын язып күрсәтмә таблица төзү. Укучыларга адымлап чишү юлларын, үтәлеш, нәтиҗәләрне язып баруның әһәмиятен аңлату.
Практика. “Каз өмәсе” турында видео карау. Хәзерге һәм элеккеге өмәләрне чагыш-тыру. Каз белән бәйле халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю. (1 нче төркем) Сораштыру, җыентыклар белән эшләү, интернет ресурслардан файдалану алымнарын өйрәнү. Өмә җырларын, уеннарны күмәк башкару. “Каурый алыш”, ”Канат сату” уеннарында халык ышанулары белән танышу. (2 нче төркем) Татарстанда “Каз өмәсе “үткәрелү турында өлкәннәрдән сораштыру, катнашу, яздыру, чыгыш ясау. (3 нче төркем) Күзәтү, яздыру, язып алу, сүрәткә төшерү алымнарын үстерү.
2 этап. Казның файдасы.
Теория. Татар халкының каз белән бәйле көнкүреш кирәк-яраклары: мендәр, ястык, юр-ган һ.б. кулланылышы. Төрле халыкларда каздан әзерләнгән милли ашлар белән танышу.

Практика. Май канаты бәйләргә өйрәнү (Парда.) “Каз канаты нишли беләʼ?” уены аша укучыларда элеккеге һәм хәзерге көн хезмәтен чагыштырып, кадерләү, тырышлык хисләрен тәрбияләү.

“Нәселемнең чигүле мендәрләре” иҗади күргәзмәсе өчен фото, видео, чиккән эшләр туплау. Күргәзмә оештыру.

3 этап. Нәтиҗә ясау.

Теория. Проектның үтәлешен тикшереп, тупланган материалларны тәртипкә салу. Үз эшчәнлегеңне башкаларга сөйләү, дәлилләү. ”Каз өмәсе нәрсә ул?” соравына тулы җавапны табу. Проект эшчәнлеге турында конференциядә чыгыш ясау.

Практика: Сыйныфта ”Каз өмәсен” уздыру.

**Тәүге адымнар – 16 сәгать**

*1. Фольклор әсәрне сәхнәгә кую.*

Теория. ”Каз өмәсе” проекты ачышларына нигезләнгән “Серле мендәр” пьесасы белән танышу. Төп фикерне аңлау. Рольләр бүлешү. Күп пәрдәле әсәрне кую үзенчәлекләре белән танышу.

Практика. Өмә уеннарын, җырларны, йолаларны кабатлау. Сайлап алу. Кирәклеләрен өйрәнү.

Костюмнарны табу, үзләре теккән, чиккән киемнәрне куллану. Сәхнә бизәлешендә проект нигезендә табылган күргәзмә материалны файдалану. Куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәп, картон, тукыма - мамыктан курчак-казлар ясау.

*2. Сәхнә серләре.*

Теория. Хәзерге һәм үткән тормышны чагыштырып, бәйләп күрсәтү алымнары.

Практика. Спектакльдә уен коралларын (баян, курай, думбрада уйнаучы укучыларны) һәм заманча музыка бизәлешен куллану. Репетицияләр.

*3. ”Серле мендәр” спектаклен кую.* “Халыклар дуслыгы“, ”Түгәрәк уен” фестивальләрендә катнашу. Горурлык, милли йолаларга хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Милли ядкарьләр - 18 сәгать**

*1. Милли ашлар.*

Теория. Милли ашлар турында мәгълүмат. Салкын, кайнар, беренче һәм икенче ашлар. Камыр ризыклары. Практика. Тозлы камырдан өчпочмак, вак бәлеш, кош теле ясау. Куркынычсызлык кагыйдәләре.Тозлы камырны ясау. Милли ашларны пешерү турында презентация карау. Яссы, рельефлы, күләмле бизәкне әвәләү, эчлек ясау, киптерү. Кипкән милли ашларны буяу, савытка урнаштыру.

*2 .Татар халкының савыт – сабалары.*

Теория. Табын бизәлеше. Элек һәм хәзер. Өстәл яны әдәбе. Ырымнар. Татар халкының савыт – сабалары.

Куна, уклау, иләк, бизмән.Һ.б

Практика. Бизәкне көйдереп һәм тамбур белән чигеп төшерү остасы белән очрашу. Төркемнәрдә куна (малайлар), тастымал (кызлар) бизәү.

Куналардагы бизәкләр. Көйдереп ясау техникасы. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Эш урыны, эш коралын булдыру. Кунага бизәкне төшерү.Үрнәк буенча көйдереп яки кырып ясау алымын өйрәнү. Бизәкне ясау, буяу.

Тамбур белән чигү. Тастымалга бизәк төшерү. Кызлар. (2 нче төркем) Куркынычсызлык кагыйдәләре. Эш урыны, эш коралын булдыру. Чигү төрләре. Тамбур белән чигү алымын өйрәнү, тастымал читен бизәү. Бизәкне төсле җепләр белән чигү.

**Иҗат аланы – 3 сәгать**

*1. Бәйрәм табыны.*

Теория. Бәйрәм табынының иртәнге, төшке, кичке ашлардан аермасы. Төрле бәйрәмдә табын бизәлеше үзенчәлекләре турында презентация карау. Савыт-саба, бизәлеш сайлау.

Практика. Гаилә көненә багышлап әти-әниләр белән бәйрәм оештыру.

Үзләре ясаган куна, тастымалларны кулланып бәйрәм табыны ясау. Еллык эшкә нәтиҗә чыгару, портфолионы тулылындыру. ”Табылдык” акциясен ачу. Милли музей өчен экспонатлар җыю үзенчәлекләре.

**Тематик план.**

| № | Бүлекләр һәм темалар. | Сәг.саны. | Теория | Практика |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш. Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 1 | 1 | |
| 2 | **Белергә телим!**<br>Проект эшчәнлеген оештыру. 1-2 нче класста өйрәнгәннәрне искә төшерү. Милли йолалар, бәйрәмнәр, өмәләр. | 2 | 1 | 1 |
| 3 | Проект эшчәнлеге этаплары, эзләнү алымнары, чыганаклар. | 2 | 1 | 1 |
| 4 | “Каз өмәсе”проектының эш планын төзү. | 1 | | 1 |
| 5 | Каз өмәсе турында видео карап, китаплардан, укып хәзерге һәм элеккеге өмәләрне чагыштыру. | 4 | 1 | 3 |
| 6 | Каз белән бәйле халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, танышу, мәгънәсен аңлату. | 3 | 1 | 2 |
| 7 | Өмә җырларын, уеннарын өйрәнү.<br>“Каурый алыш”,”Канат сату” | 2 | | 2 |
| 8 | Татарстанда “Каз өмәсе “үткәрелү турында өлкәннәрдән сораштыру, яздыру, чыгыш ясау. | 3 | 1 | 2 |
| 9 | Казның файдасы. Май канаты бәйләргә өйрәнү. | 2 | 1 | 1 |
| 10 | “Каз канаты нишли белә?” күрсәтмәле уены. | 1 | | 1 |
| 11 | Татар халкының көнкүреш кирәк яраклары: мендәр, ястык, юрган һ.б. кулланылышы. | 1 | 1 | |
| 12 | “Нәселемнең чигүле мендәрләре” Иҗади эш. | 2 | | 2 |
| 13 | Татар халкы кунакчылмы?<br>Каз итеннән татар халык ашлары. | 1 | 1 | |
| 14 | Проектның йомгаклау этабы. Эзләнү эше нәтиҗәләре. | 4 | 2 | 2 |
| 15 | Сыйныфта “Каз өмәсе” үздыру. | 2 | | 2 |
| 16 | **“Тәүге адымнар” балалар театры.**<br>“Серле мендәр” пьесасын җыйган материаллар | 6 | 2 | 4 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белән тулылындыру һәм уңышлы чыгыш өчен белгән күнекмәләрне кабатлау. | | | |
| 17 | “Сәхнә серләре”. Хәзерге һәм үткән тормышны бәйләп күрсәтү алымы. Җанлы музыка, әдәби һәм гади сөйләм үзенчәлекләре. | 2 | 2 | |
| 18 | Чара өчен картон, мамык, тукымадан казлар тегү. Инвентарьларны әзерләү. | 2 | | 2 |
| 19 | Сәхнә бизәү һәм репетицияләр ясау. | 3 | 1 | 2 |
| 20 | Спектакльне кую. | 3 | | 3 |
| 21 | **Милли ядкарьләр**<br>Милли ашлар. | 1 | 1 | |
| 22 | Тозлы камырдан өчпочмак, вак бәлеш, кош теле ясау. | 3 | 1 | 2 |
| 23 | Кипкән милли ашларны буяу, савытка урнаштыру. | 1 | | 1 |
| 24 | Өстәл яны әдәбе. Ырымнар. | 1 | 1 | |
| 25 | Табын бизәлеше. | 1 | 1 | |
| 26 | Татар халкының савыт – сабалары.<br>Куна, уклау, иләк, бизмән һ.б. | 1 | 1 | |
| 27 | Бизәкне көйдереп һәм тамбур белән чигеп төшерү осталары белән очрашу. | 1 | 1 | |
| 28 | Бизәк сайлау,төшерү. | 1 | | 1 |
| 29 | Куна – тастымал бизәү.<br>1.Куналардагы бизәкләр. Көйдереп ясау техникасы . Малайлар төркеме.<br>2. Тастымалдагы бизәкләр.Тамбур белән чигү. Кызлар төркеме. | 8 | 3 | 5 |
| 30 | **Иҗат аланы.**<br>Әти-әниләр белән табын бизәп “Гаилә бәйрәме” уздыру.<br>“Без булдырабыз!” мәктәп, район, шәһәр олимпиадасын оештыру. | 2 | | 2 |
| 31 | Йомгаклау.<br>”Табылдык”акциясен ачу. Милли музей өчен экспонатлар җыю үзенчәлекләре. | 1 | 1 | |
| | **Барлыгы** | **68** | **26** | **42** |

**“Милли мирас”**

4 нче сыйныф программасының эчтәлеге.

Шөгыльләнүнең дүртенче елында эшчәнлек иҗади эшләр аша милли мирасны өйрәнүне дәвам итүгә, аны башкаларга танытуга, саклауга, үстерүгә юнәлгән. Уеннар,

эзләнү эше, театраль эшчәнлек, күренекле осталардан мастер-класслар алдагы елларда алган белемнәрне мөстәкыйль файдаланып, иҗади эшчәнлекнең һәм күмәк социаль файдалы проекларның тормышка ашырылуына булыша. Татар культурасы, сәнгате, тарихы хакында иҗади эшләр башкарганда башка милләтләр мәдәниятенә дә хөрмәт, толерантлык, бердәмлек, дуслык, патриотлык хисләре тәрбияләүгә зур игътибар бирелә. Йомгаклау өлешендә укучыларга, дүрт ел эчендә туплаган күнекмәләрен теләкләренә, кызыксынуларына карап алга таба үстерү өчен, гимназиядә эшләп килүче түгәрәкләр, иҗади клублар, берләшмәләр хакында мәгълүмат җиткерелә.

**Кереш:куркынычсызлык кагыйдәләре – 1 сәгать**

Бу уку елында эш юнәлеше, кирәкле материал, эш кораллары, чыганаклар белән танышу, куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәнү.

**Милли ядкарьләр – 10 сәгать**

Музейларда сакланадыр милли җәүһәрләр.

Теория. Казан кремле музейларына сәяхәт.

Археологлар, тарихчылар, музей белгечләре һөнәре. Музейларның эшчәнлеге.

Практика. “Табылдык”эзләнү акциясе эшчәнлеген барлау: табылдыклар хакында чыгышларны тыңлау, охшашларын берләштерү, өстәмә материаллар белән тулыландыру. “Милли мирас” почмагы, музей-шкафны ясау. Экспонатлар исемлеген булдыру. Изге тарихи урыннарга виртуаль сәяхәт. Сәяхәтче журналын куллану, тутыру.

**Иҗат аланы - 34 сәгать**

*1. Яшь иҗатчылар.*

Теория. ”Салават күпере” редакциясенә сәяхәт. Экскурсовод, матбугатка мәкалә язу, китап чыгару эшчәнлеге, әһәмияте белән танышу. Мәгълүматны җиткерү үзенчәлекләре. Сөйләм төрләре. Газета ничек ясала? Редколлегия составы, аларның вазифасы һәм эшчәнлеге. Хәбәрчегә хас сыйфатлар. Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт. Хәбәр язарга өйрәнү. Газетадагы публицистик мәкалә белән бер әкиятне уку, чагыштыру, аерманы табу. Әкият төрләре, тылсым, арттыру төшенчәләре белән танышу.

Практика. “Яшь экскурсовод”конкурсы: милли почмак белән таныштыру. Монолог. Башка укучыларга сайлап алынган экспонат турында сөйләү. (Татарча, русча, инглизчә) Диалог. Сорауларга тулы җавап бирү. Төркемләп эшләү. “Каурый хат язарга ярый” конкурсы.

Мәктәп газетасына шкаф-музейдагы экспонат турында мәкалә язу. (“Сабантуй”, ”Салават күпере” журналына җибәрү) “Илһам” иҗади бәйгесендә катнашу. Милли предметлар турында әкият иҗат итү. Китапчык төзү. Җыентыкны тәкъдир итү.

*2. Яшь журналистлар.*

Теория. Балалар өчен татарча телетапшыруларны карау, фикер алышу. Интервью – иҗади гапләшү. Репортаж-күзәтче жанр. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар төшерү, язу үзенчәлекләре.

Практика. “Мин татарча сөйләшәм” проекты. Төрле һөнәр ияләренең, төрле яшьтәге кешеләрнең, төрле урыннарда татарча табышмакларга җавап табуын, мәкальне дәвам

итүен, аралашуы һ.б. турында видеолар туплап, бербөтен итеп җыю. (парлы, төркемле, күмәк эш). Теләк буенча сәләтле укучылар өчен шәхси бирем-видеоролик төшерү.

*3. Яшь дизайнерлар.*

1) Милли бизәк.

Теория. Дизайнер, милли киемнәр тегү остасы белән очрашу. Энҗе белән чигү һәм күн мозаикасы технологиясе. Остадан мастер-класста катнашу. Дизайн. Милли төсмерле заманча бизәк һәм фасон.

Практика. Төркемләп эшләү. Эшчәнлекне ысул кулланып эзлекле алып бару. 1 нче төркем.(Кызлар) Телефон савыты тегү, күпертеп энҗе белән чигү.

Куркынычсызлык кагыйдәләре, эш урынын әзерләү, эш кораллары белән танышу. Савыт өлгесен ясау. Бәрхет тукымадан өлгеләр кисү, бизәк төшерү. Бизәкне күпертеп һәм яссы итеп мәрҗәннәр белән чигү. Чигелгән өлешләрне тоташтыру, савытның эчлеген тегү. 2нче төркем. (Малайлар) Күн мозаикасы кулланып акча янчыгы тегү. Куркынычсызлык кагыйдәләре, эш урынын әзерләү, эш кораллары белән танышу. Янчык өлгесен ясау. Күнгә бизәк төшерү, кисү, читләренә тишемнәр ясау.

Төсле җепләр белән кисәкләрне тоташтырып акча янчыгын тегү.

2) Татар курчаклары.

Теория. Милли курчаклар иҗат итүче оста-дизайнер Ф.А.Калмурзина курчаклары белән танышу. Купшы Сөембикә, гади Мәйсәрә, заманча Сәкинә, Чулпан милли курчаклары тарихы. Курчак киендерү серләре.

Практика.Татар курчакларына исем бирү, күлмәк фасонын уйлап табу, букча, башлык камзул бизәкләре композициясен төзү.(парлы эш) “Заманча киенгән татар кызы һәм егете”рәсем конкурсы. Сәләтле балалар өчен бирем гади курчакны татар курчагы итеп киендерү. Кул эшләре һәм рәсемнәр коллекциясен тәкъдим итү. Ятим балалар өчен “Ярдәм” ярминкәсе оештыру. Конференция, конкурсларда катнашу.

**Беләсем килә! - 12 сәгать**

Проект. ”Милләт көче- бердәмлек һәм бирешмәс рух.”

Теория. Проект эзләнү эшен оештыру этапларын искә төшерү. Тема, эзләнү объекты, эш юнәлешләрен билгеләү. Сугыш темасын яктырткан документаль фильм карау. Әдәбият дәресләрендә алган белемнәрне, ”Алиш варислары” гимназия музеен кулланып фикер алышу.

Практика. “Гаиләмнең сугыш турында истәлекләре, ядкәрләре, иҗади эшләре”- эзләнү.

Төркемле эш. ”Яшь иҗатчылар” темага туры килгән иҗади эшләр; ”Яшь журналист” ветераннар белән очрашудан видеоязма, истәлек аудиоязма, фото, сугыш хатлары, сугыш чоры халык авыз иҗаты әсәрләре; ”Яшь дизайнер” ”Яшь экскурсовод” сугыш белән бәйле экспонатлар җыю. Чемоданда сугыш музеен ясау, башкаларны таныштыру. Сугыш темасына җыелган материалны берләштереп конференциядә катнашу.

**”Тәүге адымнар” балалар театры - 11 сәгать**

Теория. Балалар сөйләгәннәрдән яки фронтовик язучыларның берничә әсәрен берләштереп сценарий төзү. Төп фикерне аңлау. Рольләр бүлешү. ”Зәйнәп әби хәтирәләре” пьесасында батыр, кайгыручы, тырыш, бирешмәс кеше образлары.

Практика. Спектакль куюга әзерлек. Сугыш темасына язган авторлар һәм халык авыз иҗаты әсәрләрен карау, сайлап алу, өйрәнү. Театраль күнегүләр. Репетицияләр. Костюмнарны табу. Сәхнәне үзләре, 1-4 сыныфларда эшләгән кул эшләре файдаланып, кирәкләрен ясап бизәү. Сугыш темасына музыка табу, уен кораллары, бию элементларын кертү. Спектакльне кую. ”Рәхмәт сезгә, ветераннар!” акциясендә катнашу.

| № | Бүлекләр һәм темалар. | Сәг.саны. | Теория | Практика |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш. Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 1 | 1 | |
| 2 | **Милли ядкарьләр.**<br>3 нче сыйныфта ачылган “Табылдык”эзләнү акциясе нәтиҗәләре. | 2 | 1 | 1 |
| 3 | Казан кремле музейларына сәяхәт. | 2 | | 2 |
| 4 | Археологлар, тарихчылар, музей белгечләре һөнәре. | 1 | 1 | |
| 5 | Музейларда сакланадыр милли җәүһәрләр. Музейларның эшчәнлеге. | 2 | 1 | 1 |
| 6 | Сыйныфта “Милли мирас” музей- шкафны ясау. Экспонатлар исемлеген булдыру. | 2 | 1 | 1 |
| 7 | Изге тарихи урыннарга виртуаль сәяхәт. | 1 | 1 | |
| 8 | **Иҗат аланы.**<br>Экскурсовод, журналист, язучы һөнәрен нәрсә берләштерү? | 1 | 1 | |
| 9 | “Яшь экскурсовод”ларның милли почмак белән таныштыруы. | 2 | 1 | 1 |
| 10 | “Салават күпере” редакциясенә сәяхәт. | 2 | | 2 |
| 11 | “Каурый-хат язарга ярый.”<br>Мәктәп газетасына музейдагы экспонат турында мәкалә язу. | 2 | 1 | 1 |
| 12 | Газетада чыккан мәкалә белән әдәби әсәр, экиятнең уртак һәм аермалы яклары. | 1 | 1 | |
| 13 | Язучы һөнәре. Әкият язабыз. | 2 | 1 | 1 |
| 14 | “Илһам” Иҗади бәйгесен оештыру. | 1 | | 1 |
| 15 | Журналист һөнәре. Балалар өчен татарча телетапшыруларны карау, фикер алышу. | 2 | 1 | 1 |
| 16 | “Яшь журналист”<br>Интервью алу –иҗади гапләшү. | 1 | 1 | |
| 17 | Милли темага әңгәмә кору. | 1 | | 1 |
| 18 | “Мин татарча сөйләшәм”проекты. | 2 | 1 | 1 |
| 19 | “Яшь дизайнер”лар мәктәбе. | 1 | 1 | |
| 20 | Дизайнер, милли киемнәр тегү осталары Алсу Мосафирова очрашу, Ф.Калмурзина | 2 | | 2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | истәлекләре. | | | |
| 21 | Осталардан мастер - класста катнашу. | 2 | | 2 |
| 22 | Телефон савыты тегү, күпертеп энҗе белән чигү (Кызлар)<br>1.Куркынычсызлык кагыйдәләре: эш урынын әзерләү, эш кораллары белән танышу.<br>2.Калфак өлгесен ясау. Бәрхет тукымадан кече калфак өлгеләрен кисү, бизәк төшерү.<br>3.Бизәкне күпертеп һәм яссы итеп мәрҗәннәр белән чигү.<br>4.Чигелгән өлешләрне тоташтыру, калфакны тегү.<br>Күн мозаикасы кулланып акча янчыгы тегү. (Малайлар)<br>1. Куркынычсызлык кагыйдәләре: эш урынын әзерләү, эш кораллары белән танышу.<br>2. Янчык өлгесен ясау. Күнгә бизәк төшерү, кисү, читләренә тишемнәр ясау.<br>3.Төсле җепләр белән кисәкләрне тоташтырып акча янчыгын тегү. | 6 | 2 | 4 |
| 23 | “Татар курчаклары” тарихы. | 1 | 1 | |
| 24 | “Заманча киенгән татар кызы һәм егете” рәсеме конкурсы. Сәләтле балалар өчен иҗади бирем: курчакны тукымадан тегеп, чигеп , ябыштырып милли дизайн юнәлешендә киендерү. | 2 | 1 | 1 |
| 25 | Кул эшләреннән ятим балалар өчен “Ярдәм” ярминкәсе оештыру. | 1 | | 1 |
| 26 | **Беләсем килә!**<br>Проект ”Милләт көче - бердәмлек һәм бирешмәс рух”. Эзләнү эшен оештыру. | 1 | 1 | |
| 27 | Сугыш темасын яктырткан татарча документаль фильм, театр язмасын карау. | 2 | 1 | 1 |
| 28 | Сугыш елларында татар халык фольклоры. | 2 | 1 | 1 |
| 29 | ”Татарның батыр уллары һәм кызлары.” Сугышта катнашкан күренекле татар шәхесләре. | 1 | | 1 |
| 30 | “Гаиләмнең сугыш турында истәлекләре, ядкәрләре, иҗади эшләре”<br>Төркемле эш.<br>1.”Яшь иҗатчы”<br>2.”Яшь журналист”<br>4.”Яшь дизайнер” һәм “Яшь экскурсовод” | 4 | 2 | 2 |
| 31 | Проектны йомгаклау. Сугыш темасына җыелган материалны берләштереп чыгыш ясау. | 2 | | 2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 32 | **“Тәүге адымнар” балалар театры.** Театраль уен. Балалар сөйләгәннәрдән сценарий төзү. Рольләр бүлешү. | 2 | 1 | 1 |
| 33 | Табылган халык авыз иҗаты әсәрләрен карау, сайлап алу, өйрәнү. | 2 | 1 | 1 |
| 34 | Костюмнарны табу. Музыкаль бизәлеш. Театраль күнегүләр. Сәхнәне бизәү. | 4 | 1 | 3 |
| 35 | Чыгыш ясау. Үзбәя. ”Зәйнәп әби хәтирәләре” спектаклен видеога төшерү, ”Тәүге адымнар” портфолиосын тулылындыру. | 2 | | 2 |
| 36 | Йомгаклау. 5 нче класста кызыксындырган юнәлештә шөгыльләнергә мөмкин булган түгәрәкләр белән танышу. | 1 | | 1 |
| | **Барлыгы** | **68** | **27** | **41** |

**Кулланылган әдәбият**

Норматив документлар:

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» закон (№ 273, 29.12.2012ел**)**
- Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартлары (№ 373, 06.10.2009 ел)
- Башлангы гомуми белем бирүнең үрнәк белем бирү программалары (Протокол 8 апрель 2015 ел № 1/15)
- РФ Мәгариф министрлыгының методик хаты № 09-1672, 18.08.2017 ел


1. Журналлар:“Сабыйга”, “Салават күпере”,”Сәхнә”
2. Әхмәтҗанов Ю. Ә. Татар халык ашлары. – Казан: Татарстан китап нәшрияты.2013 – 151 б.
3. Саттар-Мулилле Г. Татар исемнәре ни сөйли? Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге. – Казан. 1998. – 487 б.
4. Баязитов Ф.С. “Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары.”- Казан , татар китап нәшрияты,2006 ел.
5. Чурилова Э.Т. Методика и организация театральной деятельности дошкольников и младших школьников.- Москва, 2001 год
6. Базанов В.В. Техника и технология сцены. Москва, -1976 год
7. Ращупкина С. Ю. «Выжигание по дереву»
8. Надиров И. Шифалы чишмә / Фәнни эзләнүләр юлында. – Казан: Фикер, 2000. – 218-234 б.
9. Исәнбәт Н. Балалар дөньясы: Такмак-такмазалар, җыр, мәкаль, табышмаклар, алдавыч экиятләр һәм башкалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1970.
10. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. (Җыеп төзүче һәм аңлатма мәкаләләр бирүче Н.Исәнбәт). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984.
11. Татарстан башкаласы буенча сәяхәт.-Казан:Титул,2002.-17 б.
12. Габдуллина Ф.Г.Үзебез чигәбез.-Казан:Тарих,2003.-112б.
13. Болгар һәм Свияжск.Балалар һәм ата-аналар өчен кызыклы юлкүрсәткеч.Казан.Татарское детское издательство(ТДИ),2016.-25б.

14. Уразман Р. Татар халык йолалары һәм бәйрәмнәре. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1992.-92б.
15. Газета”Darelfønyn” 26 сентябрь, 2013 ел, 29 нче сан.

Электрон чыганаклар:

1. Татар халык иҗаты. - Режим доступа: http://halik-ishati.ucoz.ru/
2. Ана теле http - Режим доступа: //anatele.ef.com/
3. Диброва А. «Поделки из соленого теста».Клуб семейного досуга. 2011. http://www.litres.ru/alina-dibrova/podelki-iz-solenogo-testa/
4. Рубцова Е. «Лучшие поделки из соленого теста»Владис. 2011г. http://www.litres.ru/elena-rubcova/luchshie-podelki-iz-solenogo-testa-2/
5. ”Родники мира” 7 халык һөнәрчесе хакында дисклар ,мастер класслар җыелмасы .2016 ел.
6. http://zig65zulya.fo.ru/file/6704 балалар җырлары.
7. https://edu.tatar.ru/page2593.htm/cors/ татарча мультфильмнар.
8. http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_125105.pdf әкиятләр.
9. http://tatardeti.blogspot.de/ әкиятләр.
10. http://tt.wikibooks.org/wiki/Wikibooks:

Җиһазлар:

1. Проектр
2. Компьютер
3. Такта
4. Өстәл

**Балаларга тәкъдим ителгән әдәбият:**

1.  Сабантуй. Шигырьләр. -Казан, 2006 ,-68 б.
2. Табышмаклар.-Казан, 2009, - 36 б.
3. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 нче китап.- Казан, 1977.-408б.; 2 нче китап.- Казан, 1978.-446б.; 3 нче китап.- Казан, 1981- 360 б.
4. Татар халык йолалары. –Казан,1986- 102 б.
5. Татар халык ижаты. Жырлар. –Казан, 1977-380 б.
6. Татар халык ижаты. Балалар фольклоры/Тоз. Р.Ягъфаров.- Казань, 1993.
7. Халык уеннары. –Казань, 1996.
8. “Салават күпере”журналы.

# Туган ягым

# Дәрестән тыш эшчәнлек программасы ( рухи – әхлакый юнәлеш буенча) (8 нче сыйныф)

*Тимершина Сания Госман кызы, Хәйдәрова Энҗе Якуб кызы, Казан шәһәре Киров районы 32 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Аңлатма язуы.

Балаларга патриотик тәрбия бирүнең иң беренче адымы - туган як тарихын өйрәнү. Патриотик тәрбия дигәндә, без балаларны Ватанның лаеклы уллары, кызлары итеп тәрбияләүне күз алдында тотабыз. Патриотлык – үз иленә, туган җиренә, аның

тарихына, мәдәниятенә , милли символларына, изге урыннарына хөрмәт белән карау, казанышлары белән кызыксыну ул.

Без бай тарихы булган татар илендә яшибез. Тарих ул – истәлек, ул – ата-анабыз, әби-бабаларыбыз, илебез, милләтебез хәтере... һәр кеше үз тарихын белергә, аның белән кызыксынырга тиеш. Татарлар гына түгел, Татарстанда яшәүче һәр милләт баласы татар телен, тарихын, мәдәниятын белергә һәм аны ихтирам итәргә тиеш дип саныйм.

Үткән, хәзерге һәм киләчәк бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнгән. Кеше үткәннән сабак алып киләчәккә карап яши.

Программада туган як, туган шәһәр тарихын өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Туган якны өйрәнү эше укучыларны эзләнү, танып – белү эшенә этәрә.

Балаларда туган якның матурлыгын күрә белергә, аны ярата, яклый, саклый белүне кечкенәдән үк тәрбияләүдә зур эшләр алып барыла. Дәрестән тыш, мәктәп, шәһәркүләм үткәрелгән чараларда балалар актив катнашалар.

Тәкъдим ителә торган программа үзенең актуальлеге, тормышчанлыгы белән аерылып тора. Ул туган як турында белемнәрне арттыру, эзләнүчәнлекне, интеллектлылыкны үстерү, иҗади сәләтне ачуны да үз эченә алган. Укучыларга бу дәресләрдә туган якның матурлыгын күрүгә, туган җиребезне яратуга, саклауга зур урын бирелә. Шушы нигездә дәрестән тыш эшчәнлектә укучыларга тарихның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында башлангыч мәгълүмат бирү бурычы куела. Шушы бурычны уңышлы хәл итү өчен «Без тарихта эзлебез» дигән программа кабул ителде. Укучылар туган шәһәребезнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү нигезендә туган як турында системалы белем һәм күнекмәләр ала. Программада белем һәм тәрбия бирүне этаплап алып бару күздә тотыла. Башта дәресләрдә (5 класста “Шәһәрем буйлап сәяхәт”, 6 нчы класста “Туган ягым” темаларына теоретик материал өйрәтелә, ул системага салына, ныгытыла, экскурсияләр оештырыла. Дәресләрдә шулай ук өлешчә эзләнү методлары да урын ала. Моның өчен укучылар газета, журнал, телевидение тапшыруларыннан алынган мәгълүматларны киң куллана. Үзләре фотокүргәзмәләр өчен материаллар әзерли. Бу эш нигезендә укучыларда төрле чыганаклар белән эшләү күнекмәләре барлыкка килә, алар анализларга, нәтиҗәләр ясарга өйрәнә.

Укучы кызыксынучан булырга, үзе яши торган әйләнә - тирәне танып белергә теиеш. Класстан класска балаларның танып белү мөмкинлекләре үсә һәм әйләнә тирә турында күзаллавы киңәя. Фәнне авыр үзләштерүче укучылар да туган якның кызыклы тарихын ишетеп, төрле риваятьләр, легендалар, информацияләр тыңлап үз фикерен әйтә алалар. Һәр экскурсиядә алган мәгълүматлар, күзәтүләр, фикерләү дәресе, акыл үстерү дәресе булып тора.

**Максат:**

- шәһәрнең тарихы һәм хәзерге торышы, халкы, мәдәнияте белән таныштыру, аның истәлекле урыннарын күрү.
- укучыларда фәнни-эзләнү күнекмәләре булдыру;
- үткән белән кызыксыну, туган шәһәрләре белән горурлану хисләре уяту. Ватанның лаеклы уллары, кызлары булырга теләк уяту.

**Бурычлар:**

- укучыларның танып-белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү;
- балаларда үз халкына, тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту, тарихына , яшәешенә битараф булмаска өндәү;
- үз мөнәсәбәтеңне белдереп сөйләргә, фикереңне исбатларга, нәтиҗәләр чыгарырга өйрәтү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Метапредмет

1. Яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, балаларның мөстәкыйльлеген үстерү.
2. Балаларның иҗади активлыгын, кызыксынучанлыгын күрү, аларны үстерү юлларын табу.
3. Предметара бәйләнешләр булдырып, фикерләү сәләтләрен үстерү, алынган белем – мәгълүматларны камилләштерү, киңәйтү, бер системага салу.
4. Өйрәнелә торган материалны анализлау, тарихи момент һәм фактларны аңлата һәм исбатлый белү. Акыл эшчәнлеген үстерү.

I. Шәхескә кагылышлы

1. Туган илгә, туган якка мәхәббәт хисләре уяту.
2. Үткәнебезгә хөрмәт, бүгенгебез белән горурлану хисләре уяту.
3. Эстетик тәрбия бирү. Сөйләм культурасына, үз – үзенә таләпчәнлек, намуслылык, зәвыклы балалар тәрбияләү.

Программаны тормышка ашыру шартлары:

- һәр балага индивидуаль якын килү, һәр балага шәхес итеп карау;
- дидактик материалдан һәм информацион - коммуникатив технология чараларыннан файдалану.

**Укучы үзләштерергә тиеш:**

- шәһәребезнең тарихын;
- шәһәребез турында риваятьләр, легендалар;
- шәһәребезнең үзенчәлекле урыннары турында;
- тарихны белүнең кирәклеге турында

**Укучы белергә тиеш:**

- туган якның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен;
- шәһәрнең истәлекле урыннарын;
- шәһәребез турында легендаларны, риваятьләрне;
- карта белән эшли белергә.

**Эшчәнлекнең нәтиҗәсе:**

- Укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә тартып, аларның активлыгын үстерү.
- Балалар арасындагы дуслык, бердәмлек, коллективта үз – үзеңне тотуның югары мөмкинлекләре.

**Эшчәнлекнең формалары:**

- укучылар белән әңгәмәләр;
- шәһәргә күзәтүләр, экскурсияләр;
- бәйрәмнәр;

- иҗади биремнәр үтәү: альбомга материаллар туплау, фотоальбом, реферат, сочинение, рәсем төрле темаларга зур булмаган телдән журнал әзерләү, газета чыгару;
- музей материаллары белән танышу;
- эзләнү-тикшеренү эшен оештыру (материал җыю);
- шәһәр картасы белән эшләү.

## Программаның эчтәлеге

*Тематик планлаштыру.*

**8 класс - 33сәгать.**

| № | Тема | Сәгать саны | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| | **Шәһәрем буйлап сәяхәт.** | | |
| 1 | "Туган ил", "Ватан"төшенчәләре. | 1 | |
| 2 | Дәүләт символлары. Татарстан гимнын өйрәнү. | 1 | |
| 3 | Минем туган шәһәрем - Казан. Татарстанның башкаласы. Татарстан картасы буенча эш | 1 | |
| 4 | Мин яшәгән район. Киров районы. | 1 | |
| 5 | Мин яши торган урам. | 1 | |
| 6 | Районыбыздагы күренекле кешеләр. | 1 | |
| 7 | Районыбызда күренекле кешеләр исемен йөрткән урамнар | 1 | |
| 8 | А.Матросов, М.Раскова урамнарына экскурсия | 1 | |
| 9 | Кем ул Гадел Кутуй? | | |
| 10 | Г.Кутуй урамына экскурсия. | 1 | |
| 11 | Конкурс «Туган урамыңны беләсеңме?” | 1 | |
| 12 | Җыйган материаллардан, тупланган фотолардан файдаланып альбом төзү. | 1 | |
| 13 | Минем мәктәбем. Мәктәп тарихы. | 1 | |
| 14 | Мин мәктәбем белән горурланам. Мәктәп гимнын өйрәнү. | 1 | |
| 15 | Мәктәбем ишегалды. Аның экологик торышы. Мин ничек ярдәм итә алам? | 1 | |
| 16 | Мәктәп ишегалдын яшелләндерү. Проект эше. | 1 | |
| 17 | Мәктәп музеена экскурсия. | 1 | |
| 18 | “Күршеләреңне беләсеңме?” . Күрше районнар. | 1 | |
| 19 | Шәһәрем урамнары. | 1 | |
| 20 | Бауман урамының килеп чыгышы. | 1 | |
| 21 | Бауман урамы – үзәк урам. | 1 | |
| 22 | Парклар. | 1 | |
| 23 | Горький паркына экскурсия. Мәңгелек ут. | 1 | |
| 24 | Һәйкәлләр. “Беркем дә онытылмый, бернәрсә дә онытылмый”. | | |
| 25 | Кырлай паркына сәяхәт. | 1 | |
| 26 | Җыйган материаллардан, тупланган фотолардан | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | файдаланып альбом төзү | | |
| 27 | Шәһәремдә күңел ачу үзәкләре. | 1 | |
| 28 | Казансу елгасы яры буе гөрләп тора! | 1 | |
| 29 | Данлы Идел елгасы. | 1 | |
| 30 | Казанда метро йөри башлады. | 1 | |
| 31 | Халыклар дуслыгы йорты. | 1 | |
| 32 | Милли китапханә. | 1 | |
| 33 | Түгәрәк өстәл артында. | 1 | |
| 34 | Казаным данлы шәһәр! Балаларның үз тойгылары нәтиҗәсендә рәсем ясау | 1 | |

**Кулланылган әдәбият:**


1. Краеведение в школе. – Педагогическая энциклопедия, т.2.М., Советская энциклопедия,1965, с. 518-520.
2. Краеведческая программа. “Литературное краеведение”, составлена С.С.Кулаковой.
3. А.С.Тайсин. Татарстан Республикасы географиясе. Гомуми урта белем мәктәбенең 8-9 класслары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002 ел. – 230 б.
4. Большая Советская Энциклопедия. – третье издание. – Москва: Издательство “Советская энциклопедия”, 1972. – стр. 606
5. “Мәйдан “журналы
6.”Мәгариф”журналлары
7. Музей материаллары.
8. Татарстан тарихы.Төп мәктәп өчен уку әсбабы. - Казан. - ТаРИХ, 2001
9. Хәтер.Татарстан Республикасы, Казан, Хәтер китабы нәшр., 1996.
10. Интернет –ресурслар.


## “Халык педагогикасы – акыл, рухи сафлык чишмәсе” Рус телендә урта (тулы) белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен туган (татар) телдән дәрестән тыш эшчәнлек программасы (Гомуминтеллектуаль юнәлеш)


*Мөкминова Әлфия Дамир кызы, Казан шәһәре “8 нче гимназия – Мәгариф үзәге” МББУ татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


### Аңлатма язуы

Туган (татар) телдән “Халык педагогикасы – акыл, рухи сафлык чишмәсе” гомуминтеллектуаль юнәлештәге дәрестән тыш эшчәнлек программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга нигезләнеп эшләнде:

1. “Кеше хокуклары турында Декларация”нең төп нигезләмәсе (БМО Генераль ассамблеясе тарафыннан 10.12.1948 кабул ителгән).
2. “Бала хокуклары турында Конвенция” (БМО Генераль Ассамблеясе тарафыннан 20.11.1989 кабул ителгән).
3. Россия Федерациясе законннары:

- «Россия Федерациясе халыклары телләре турында;
- «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль закон ( 2012нче елның 29нчы декабрендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан имзаланган 273 нче ФЗ; 2013нче елның 1нче сентябреннән гамәлдә);
4. Федераль дәүләт белем стандартлары:
5. Гомуми белем бирүнең үрнәк программалары.
6. Татарстан Республикасы законнары:
- «ТР дәүләт телләре һәм ТРсындагы башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы законы;
- «Мәгариф турында»гы Татарстан Республикасы законы (№ 68, 2013нче елның 22нче июле).

Дәрестән тыш эшчәнлек буенча эш программасы 6 нчы сыйныфлар өчен тәкъдим ителә. Программа "Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты"на нигезләнеп, атнага 1 сәгать исәбеннән төзелде. Курс 35 сәгатькә исәпләнгән.

6 нчы сыйныф өчен дәрестән тыш эшчәнлек программасы татар халык авыз иҗаты төрләрен, аларның яшь үзенчәлегенә туры килерлек үрнәкләрен үз эченә ала. Халык педагогикасы баланы сәнгать дөньясына җәлеп итү, халыкның традицияләре белән таныштыру өчен иң кулай материал булып кына калмый, образлы фикерләү үстерү, эстетик кыйммәтләргә уңай караш тудыруда да зур ярдәм итә, тормышны аңлауда һәм аңа яраклашуда зур ярдәм итә. Программаның максаты: халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен өйрәнеп, укучыларның интеллект дәрәҗәсен үстерү, тормышка яраклашкан (социальләшкән) шәхес тәрбияләү. Программаны тормышка ашыру барышында төркемдә һәм күмәк эшләү формалары кулланыла. Бу формалар аралашу сәләтен үстерү өчен файдалы.

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш.

**Программаның максаты**: укучыларны халык педагогикасы – халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру һәм татар халкының бай тарихына, традицияләренә, милли мирасына мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү.

Бу максатка бәйле рәвештә түбәндәге **бурычлар** куелды: халык авыз иҗаты үрнәкләрен гамәли үзләштерүгә ирешү, ягъни татар мәкальләрен, әкиятләрен, җырларын, табышмак, санамыш, сынамышларын аңлап һәм сәнгатьле итеп укырга, аларны кулланып төрле темаларга сөйләшергә өйрәтү һәм алар аша татар халкының гореф-гадәтләре, милли ризыклары, киемнәре турында күпкырлы мәгълүмат бирү.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы мәгариф сәясәтенең төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә дә иркен аралашучы шәхес тәрбияләү. Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 маддәсендә һәм "Татарстан Республикасы халыклары телләре

турында” Законында күрсәтелгәнчә, Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә.

Федераль дәүләт белем стандартлары да укучыларның аралаша белү осталыгына, билгеле күләмдә тел байлыгына ия булуына, эзлекле фикерли белү сәләтенә, сөйләм күнекмәләренә ия булуын таләп итә.

Бу таләпләрне тормышка ашыруда тел һәм әдәбият дәресләре генә түгел, ә дәрестән тыш эшчәнлек тә зур файда китерә. Әлеге укыту формасы белем бирү процессының бер өлеше булып тора. Федераль дәүләт стандартлары да бу эшчәнлекне тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Дәрестән тыш чараларның төп билгеләнеше – дәрестә каралган теоретик материалларны тирәнтен өйрәнү генә түгел, алган белемнәрен стандарт булмаган мәсьәләләр чишүдә куллана белү күнекмәләрен үстерү дә, мәсьәләләр белән эшләү культурасын тәрбияләү дә. Шулай ук балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелергә һәм үткәрү формасы буенча укытуның дәрес системасыннан аермалы булырга тиеш.

Татар теле буенча оештырыла торган эшчәнлек – бөтен укыту-тәрбия процессының аерылгысыз бер өлеше. Дидактик, методик һәм гамәли яктан дөрес оештырылган эш укучыларның белемнәрен киңәйтә. Программаның әһәмияте тагын шунда, укучылар тел буенча дәреслектә булмаган кызыклы материаллар белән танышалар, дәрестән тыш чараларда катнашу нәтиҗәсендә алган белемнәрен дәрестәге мөстәкыйль эш вакытында да файдалана алалар.

**Программның төп таләпләре:**

- төп мәгълүматны алу аркылы әңгәмәдә, проект эшендә катнаша алуы;
- алынган мәгълүматка карата мөнәсәбәт белдерергә;
- проблемалы сорау куелган билгеле бер тема буенча диалог төзи, ситуатив күнегүләрне үти белергә;
- кирәкле төшенчәләрне һәм терминнарны куллана белергә тиеш.

Программа 35 сәгатькә исәпләнгән. Дәрестән тыш эшчәнлек интеллектуаль клуб форматында үткәрелә. Эшчәнлек төрләре: уен эшчәнлеге, танып белү эшчәнлеге, иҗади эшчәнлек.

**Программаны тормышка ашыру этаплары:**

Укучыларда татар теленә, сәнгатенә, мәдәниятенә, тарихына хөрмәт хисе тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү максатыннан, “Сабыйга”, “Салават күпере” журналлары, “Сабантуй” газетасы, “Мәгариф” журналларындагы материаллардан файдалану да отышлы дип санала. Җырлар шулай ук эшчәнлекне төрләндереп җибәрә, балалар татарча җырларга, сыйныфтан тыш чараларда катнашырга бик теләп ризалашалар. Бу бәйрәмнәрдә алар үзләренең матур итеп җырлый, бии, сәнгатьле итеп сөйли белү осталыгына ия булуларнын күрсәтәләр.

Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, түбәндәге **алымнар** кулланыла:

**1. Мәгълүмат бирү алымнары:**

- укытучы сүзе;
- әсәргә иллюстрацияләр карау;
- укытучы укуы;

- аңлашылмаган сүзләрне аңлату;
- аңлатмалар бирү;
- чагыштыру;
- китап тәкъдим итү;
- китап күргәзмәсе.

**2. Анализ алымнары:**

- әсәрне өлешләргә бүлү;
- план төзү;
- чагыштыру;
- эчтәлек сөйләү;
- әңгәмә;
- эзләнү;
- проблемалар чишү.

**3. Иҗади эш алымнары:**

- иҗади биремнәр башкару;
- сөйләү;
- әсәрне сәхнәләштерү;
- иллюстрацияләргә исем кушу;
- текстның ахырын уйлау;
- хикәя, әкият, шигырь иҗат итү;
- рәсем ясау;
- проект эшен яклау;
- уеннар;
- экскурсияләр.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Шәхескә кагылышлы:***

- Туган илгә карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, татар халкының һәм Татарстанда яшәүче башка халыкларның тарихына, теленә, мәдәниятенә ихтирам хисләре булдыру;
- иҗтимагый, мәдәни, рухи үсешне истә тоткан, чорның фәнни үсешенә, гамәли эшчәнлеккә тәңгәл килгән кузаллау булдыру;
- Россиядә һәм бөтен дөньяда яшәүче халыкларның карашларына, теленә, мәдәниятенә, диненә, гражданлык позициясенә аңлы рәвештә хөрмәт белән карау;
- укучыларның үзлегеннән белем алуга, танып белүгә әзер булуы;
- күпмилләтле мохиттә уртак эшчәнлек алып бару күнекмәләре булдыру;
- гомумяшәеш нормаларын, кагыйдәләрен үзләштерү;
- иҗтимагый, белем алу, уку-тикшеренү, иҗади һәм башка эшчәнлек вакытында үз яшьтәшләрең, өлкәннәр һәм яшьләр белән аралашу компетентлыгы булдыру;
- җәмгыятьтәге барлык кешеләргә, шул исәптән гаилә әгъзаларына хөрмәт һәм ихтирам хисләре белән карау.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

**Универсаль уку гамәлләре:**

***регулятив универсаль уку гамәлләре***: эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү, укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү, эш сыйфатына бәя бирә белү;

***танып-белү универсаль уку гамәлләре:*** укучыларның һәм укытучының уртак эше буенча нәтиҗәләр ясау; укытучы сорауларына җавап бирү өчен тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлау;

***коммуникатив универсаль уку гамәлләре:*** парларда һәм төркемнәрдә эшли белү, башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау, иптәшеңнең җавабы белән килешү, бергә эшләү процессында, сыйныфташлар белән уртак фикергә килергә кирәклеген аңлау һәм алар белән хезмәттәшлек итү, татар телендә әкияттән өзекләр сәхнәләштерү.

**Эш программасының эчтәлеге**

**1. Халык педагогикасы.**

Халык педагогикасы турында төшенчә бирү. Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләре белән танышу. Халык педагогикасы – тәрбия өлкәсендә халыкта яшәп килгән карашлар, аның тәҗрибәгә нигезләнгән тәрбияләү, укыту алымнары һәм чаралары, буыннан буынга күчеп камилләшкән педагогик белемнәре, халык өйрәтүләре, кыскасы, аның тәрбия тәҗрибәсе. Халык педагогикасының нигез өлешен халык авыз иҗаты, ягъни фольклор алып тора.

**2. Татар халык әкиятләре.**

Татар халык әкиятләре белән танышу. Татар халык авыз иҗаты буларак әкият жанрының үзенчәлекләрен өйрәнү; әкиятләрне белүнең әһәмиятенә төшендерү. Әкиятләрне төрләре буенча бер-берсеннән аера белүгә ирешү. Әкиятләргә халык акылы, тапкырлыгы, зирәклеге, батырлыгы салынуын аңлату. Әкиятләр аша әхлак сыйфатлары тәрбияләү. “Әкият кайда яши?” – дигән сорауга җавап эзләү. Татар халык әкиятләрендә “Төлке” образы. Әкиятләрне сәхнәләштерү күнекмәләре булдыру.

**3. Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре.**

Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре турында мәгълүмат бирү. Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәренең сөйләмдә тоткан роле.

**4. Татар халык табышмаклары.**

Татар халык табышмаклары турында мәгълүмат бирү. Татар халык табышмакларының укучыларның сөйләм телен үзләштерүдә, фикерләү сәләтен үстерүдә йогынтысы. Балаларның логик фикерләү сәләтен, зиһен арттыру өстендә эшләү.

**5. Татар халык җырлары.**

Татар халык җырлары – иң кадерле мирас.

Татар халык җырларының үзенчәлекләрен ачыклау. Татар халык җырлары, көйләренең- татар музыка сәнгатенең бик бай һәм кызыклы төре булуына төшенү. Җырларның мәгънәле нәфис сүзләре, тылсымлы музыкасының халыкның рухи байлыгын күрсәтүдә һәм аның зур талант иясе булуын раслауда тоткан роле.

**6. Милли бәйрәмнәр.**

Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү. Балаларны милли бәйрәмнәр белән таныштыру. Бәйрәмнәрнең халык тормышының, культурасының аерылгысыз бер элементы булып торуы. Халык бәйрәмнәре –шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе.

**7. Милли киемнәр.**

Милли киемнәр турында мәгълүмат. Милли киемнәрнең матурлыгы, бизәкләренең төрлелеге. Өс киеменең борынгы төрләре. Бүгенге көндә безгә мәгълүм традиционгадәти өс киемнәре — эчке һәм тышкы киемнәр, баш һәм аяк киемнәре, хатынкызларның бизәнү әйберләре.

**8. Татар халык уеннары.**

Балаларны татар халык уенарының төрләре һәм үзенчәлекләре белән таныштыру. Татар халык уеннарының балаларга милли тәрбия бирүдә роле. Җырлы-биюле күңел ачу уеннары.

**9. Татар халкының милли ризыклары.**

Татар милли ризыклары — татар халкының тарихтан килгән милли ашлары, ашамлыклары. Татар халкының милли традицияләргә бай ашлар әзерләү осталыгы. Татар милли ризыкларының үзенчәлекләре.

**Тематик план**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Халык педагогикасы. | 3 |
| 2 | Татар халык әкиятләре. | 6 |
| 3 | Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре. | 3 |
| 4 | Татар халык табышмаклары. | 4 |
| 5 | Татар халык җырлары. | 3 |
| 6 | Милли бәйрәмнәр. | 4 |
| 7 | Милли киемнәр. | 5 |
| 8 | Татар халык уеннары. | 3 |
| 9 | Татар халкының милли ризыклары. | 4 |
| | Барлыгы: | 35 |

## Календарь-тематик планлаштыру

| № | Тема | Сәг. саны | Уку эшчәнлеген оештыру формалары һәм төрләре | Планлаштырылган нәтиҗә | | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | шәхси | метапредмет | |
| **Халык педагогикасы(3 сәг)** | | | | | | |
| 1 | Кереш. Халык педагогикасы турында төшенчә | 1 | Мәктәп китапханәсенә экскурсия, презентация, әңгәмә | Әңгәмәдә катнашу, башкаларны тыңлый белү | Халык педагогикасының асылына, тормышта куллануның файдасына төшенү | Сентябрь |
| 2 | Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләре | 1 | Презентация, әңгәмә, лекция | Уңай мотив тудыру, әдәп-әхлак нормаларын үзләштерүгә ирешү | Сөйләм берәмлекләрен аңлап куллана белү | Сентябрь |
| 3 | Халык педагогикасында сүз төркемнәренең кулланылышы | 1 | Презентация, әңгәмә, кроссворд | Фикерләү сәләтен үстерүгә омтылыш булдыру | Сөйләм телен баету, кирәкле мәгълүматны аерып алу; төрле белем чыганаклары белән үз эшчәнлеген оештыра белү | Сентябрь |
| **Татар халык әкиятләре (6 сәг)** | | | | | | |
| 4 | Татар халык әкиятләре турында мәгълүмат | 1 | Презентация, лекция; парлы, төркемнәрдә уку | Иҗадилыкка омтылу теләге тудыру | Сөйләм осталыгын үстерү, сүзлек байлыгын арттыру | Сентябрь |
| 5 | Татар халык авыз иҗаты буларак әкият жанрының үзенчәлекләре, төрләре | 1 | Презентация, аудиоязма тыңлау | Әкиятләрдәге төрле ситуацияләргә һәм геройларның гамәлләренә гомумешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү | Укучыларның татар әкиятләрен тыңларга өйрәнүләре белән бергә, гомумкешелек сыйфатларын аера белүләре | Октябрь |
| 6 | Әкият кайда яши? | 1 | Әңгәмә, видеоязма | Күршең белән хезмәттәшлек итү, үзара | Ана телендә ишетеп аңлау күнекмәсен үстерү, | Октябрь |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ихтирам хисләре тәрбияләү | сорауларга төгәл җавап бирү | |
| 7 | Татар халык әкиятләрендә “Төлке” образы | 1 | Әңгәмә, видеоязма, әкият иҗат итү | Иптәшләреңнең фикерен тыңлый, аңлый, хөрмәт итә белү | Әңгәмәдәшкә кыска һәм оста итеп җавап бирергә өйрәнү | Октябрь |
| 8 | Әкиятләрдә саннарның кулланылышы | 1 | Яраткан әкиятләр буенча китапчыклар төзү | Иҗадилыкка омтылу теләге тудыру | Өйрәнгәннәрне логик тәртипкә салу; мәсьәләне чишү өчен уңайлы ысул сайлау; төп һәм ярдәмчел билгеләрне аеру, анализлау, объектларны чагыштыру | Октябрь |
| 9 | Өйрәнгән әкиятләрне сәхнәләштерү | 1 | Төркемнәрдә эшләү | Әңгәмәдә катнашу, башкаларны тыңлый белү | Әкиятләрне сәхнәләштерү, персонажларның характерын интонация, хәрәкәт белән күрсәтү | Ноябрь |
| **Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре (3 сәг)** | | | | | | |
| 10 | Татар халык мәкальләре | 1 | Презентация, әңгәмә | Әңгәмәдәшеңне тыңлый белү, лидерлыкка омтылу | Татар халык мәкальләренең асылына, тормышта куллануның файдасына төшенү | Ноябрь |
| 11 | Татар халык әйтемнәре | 1 | Презентация, әңгәмә | Иптәшләреңнең фикерен тыңлый, аңлый, хөрмәт итә белү | Өйрәнгәннәрне логик тәртипкә салу; мәсьәләне чишү өчен уңайлы ысул сайлау; төп һәм ярдәмчел билгеләрне аеру, анализлау, объектларны чагыштыру | Ноябрь |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәренең сөйләмдә тоткан роле | 1 | Проект: Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәребуенча китапчыклар төзү | Әдәп-әхлак нормаларын үзләштерүгә ирешү | Мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү | Декабрь |
| **Татар халык табышмаклары (4 сәг)** | | | | | | |
| 13 | Татар халык табышмаклары | 1 | Презентация, әңгәмә | Татар халык табышмакларына ихтирам хисе тәрбияләү | Татар халык табышмакларының асылына, тормышта куллануның файдасына төшенү | Декабрь |
| 14 | Татар халык табышмакларының укучыларның сөйләм телен үзләштерүдә, фикерләү сәләтен үстерүдә йогынтысы | 1 | Парлы һәм төркемнәрдә эш | Әңгәмәдә катнашу, башкаларны тыңлый белү | Эш башкару ысулларына һәм шартларына анализ ясау,предметның билгесе аша җавабын табарга өйрәнү, җаваплардагы уртаклыкны ачыклау | Декабрь |
| 15 | Татар халык табышмакларында саннарның тоткан роле | 1 | Проект: Татар халык табышмаклары буенча буклетлар төзү | Иҗадилыкка омтылу теләге тудыру | Куелган сорауларга дөрес сөйләм чаралары кулланып җавап бирү | Декабрь |
| 16 | “Тапкырлар һәм зирәкләр” бәйгесе | 1 | Квест-уен | Укучыларның төрле типтагы күнегүләр, биремнәр эшли белүенә ирешү | Укучыларның биремнәр эшли белүләре, әйләнәтирәдәге мәгълүматны, күрсәтмәлелекне куллана белү, куелган сорауга эзлекле җавап эзләү | Январь |
| **Татар халык җырлары (3 сәг)** | | | | | | |
| 17 | Татар халык җырлары – кадерле мирас | 1 | Презентация, әңгәмә, видеоязма | Әхлакый кагыйдәләргә ориентлаша белү, | Укучыларның татар җырларын тыңларга | Январь |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | өйрәнүләре белән бергә, гомумкешелек сыйфатларын аера белүләре | |
| 18 | Татар халык җырларының үзенчәлекләре | 1 | Аудио һәм видеоязмалар тыңлау, кушылып җырлау, җыр сүзләрен өйрәнү | Әңгәмәдәшеңне тыңлый белү, лидерлыкка омтылу | Өйрәнгәннәрне логик тәртипкә салу; мәсьәләне чишү өчен уңайлы ысул сайлау; төп һәм ярдәмчел билгеләрне аеру, анализлау, объектларны чагыштыру | Январь |
| 19 | Бишек җырлары | 1 | Бишек җырларын тыңлау | Бишек җырлары җырларга өйрәнү | Укучыларның татар җырларын тыңларга өйрәнүләре белән бергә, гомумкешелек сыйфатларын аера белүләре | Февраль |
| **Милли бәйрәмнәр (4 сәг)** | | | | | | |
| 20 | Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат | 1 | Презентация, әңгәмә, видеоязма | Туган ил, гаилә, миллилекне һәм башка кыйммәтләрне аңлый белү | Татар һәм рус халык бәйрәмнәрен чагыштыра белү | Февраль |
| 21 | Нәүрүз | 1 | Презентация | Әхлакый кагыйдәләргә ориентлаша белү, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | Бәйрәмнәрнең тормыштагы ролен аңлата белү | Февраль |
| 22 | Карга боткасы | 1 | Презентация | Күмәк уеннарда үзүзеңне тиешенчә тотарга өйрәнү | Төрле ситуациядә сөйләм күнекмәсен булдыру, социаль рольләрне кабул итү | Февраль |
| 23 | Сабан туе | 1 | Презентация, бәйрәмнәр | Әхлакый кагыйдәләргә ориентлаша белү | Мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициа- | Март |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | турында буклет ясау | | тивасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү | |
| **Милли киемнәр (5 сәг)** | | | | | | |
| 24 | Милли киемнәр турында мәгълүмат. Татарларның яраткан төсләре, костюм фасоннары | 1 | Презентация, әңгәмә, видеоязма | Уңай мотив тудыру, кызыксыну теләге булдыру | Милли киемнәр белән таныштыру, сөйләм осталыгын үстерү, сүзлек байлыгын арттыру | Март |
| 25 | Хатын – кыз киеме үрнәкләре, ир – ат киеме үрнәкләре. Баш һәм аяк киемнәре | 1 | Презентация, әңгәмә, видеоязма | Татар халкының милли киемнәренә ихтирам, сакчыл караш тәрбияләү | Өйрәнгәннәрне системага салу күнекмәләрен камилләштерү | Март |
| 26 | Хатын-кызларның бизәнү әйберләре | 1 | Презентация | Уңай мотив тудыру, кызыксыну теләге булдыру | Татар халкының бизәнү әйберләре белән балаларны таныштыру. Хәзерге көндә дә әле бизәнү әйберләре милли колоритын югалтмавы турында ассызыклау | Март |
| 27 | Чигү үрнәкләре. Төрле чигелгән әйберләр | 1 | Күргәзмә, әңгәмә | Үзеңнең кул көчең кергәндә генә кием кадерле булуын аңлау | Чигү элементларын атый белү, милли орнаментларның нинди мәгънә аңлатуына төшенү | Апрель |
| 28 | “Әбиемнең серле сандыгы” | 1 | Күргәзмә, рәсемнәр ясау | Милли җәүһәрләргә сакчыл караш, ихтирам тәрбияләү | Эш барышында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшерү, мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Апрель |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Татар халык уеннары (3 сәг)** | | | | | | |
| 29 | Татар халык уенарының төрләре һәм узенчәлекләре | 1 | Әңгәмә, уеннар өйрәнү, уйнау | Әхлакый кагыйдәләргә ориентлаша белү, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | Рус һәм татар халык уеннарының охшашлыгын күрү, аңлау | Апрель |
| 30 | Җырлы-биюле күңел ачу уеннары | 1 | Шаян такмаклар әйтеп бию | Бер – береңә ихтирамлылык, игътибарлылык тәрбияләү | Җырлы-биюле күңел ачу уеннарын сәхнәләштереп, балаларның тел байлыгын арттыруларына ярдәм итү | Апрель |
| 31 | “Санап җибәр!” “Урманга бару”, “Буяу сатыш” уеннары | 1 | Татар халык уеннары турында проект эшләү | Татар халык уеннарына ихтирам тәрбияләү | Уен вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшерү | Апрель |
| **Татар халкының милли ризыклары (4 сәг)** | | | | | | |
| 32 | Татар милли ризыклары | 1 | Презентация, әңгәмә, видеоязма | Татар милли ризыклар ына хөрмәт хисе тәрбияләү | Татар халкының милли ризыклары белән таныш-тыру. Хәзерге көндә дә милли ризыкларның актуальлеген югалтмавы турында ассызыклау | Май |
| 33 | Татар халкының милли традицияләргә бай ашлар әзерләү осталыгы | 1 | Презентация, әң-гәмә, татар халкы-ның танылган аш-су осталары белән танышу | Бер – береңә ихтирамлылык, игътибарлылык тәрбияләү | Кирәкле мәгълүматны аерып алу; төрле белем чыганаклары белән үз эшчәнлеген оештыра белү | Май |
| 34 | Татар милли ризыклары: чәкчәк,гөбәдия,кош теле | 1 | Презентация, әңгәмә, рәсемнәр карау, рецептлар | Татар милли ризыкларын әзерләп карау теләген тудыру, | Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, | Май |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | белән танышу | милли аң тәрбияләү | аны чишү өчен алгоритм булдыру | |
| 35 | Проект. Милли ризыклы чәй өстәле әзерләү | 1 | Проект: Татар халкының милли ризыклары | Иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү, эшнең нәтиҗәсен күреп шатлану | Балаларның бер-берсенә ярдәм итеп эшләүләре, табын янында үзеңне дөрес тоту кагыйдәләренә төшенү | Май |

## Кулланылган әдәбият


1. Әхмәтов С., Уйныйбыз да, җырлыйбыз да... // Яр Чаллы: КамАЗ акционерлык җәмгыятенең газета – кит. нәшр., - 1991.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: “Дом печати” нәшрияты, 2001.
3. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти - әниләр өчен хрестоматия. — Казан: РИЦ, 2011.
4. Гыймадиева Н.С. Дәрестә һәм дәрестән соң. – Казан: “Яңалиф”, 2004.
5. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 1997
6. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984.
7. Күңел ачкычы: Мәзәкләр. – Казан: Мәгариф, 2004.
8. Татар халык әкиятләре. – Казан: Татарстан китап нашрияты. – 2011.
9. Харисов Ф.Ф. Милли мәдәниятнең белем бирү белән интеграцияләнүе. – Казан: Мәгариф, 1999.
10. Ягъфәров Р.И. Татар халык уеннары // Казан: Татар.кит. нәшр., - 1998.
11. http://clipiki.ru/video/6578/Multik-pro-Tatarstan.
12. http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_125105.pdf әкиятләр.
13. http://tt.wikibooks.org/wiki/Wikibooks: әкиятләр.
14. http://zig65zulya.fo.ru/file/6704 балалар җырлары.
15. https://edu.tatar.ru/page2593.htm/cors/ татарча мультфильмнар.

**Эчтәлек**

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру....................................................3

Җамалетдинова Зәлфирә Исхак кызы, "Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты"өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты

Дәрестән тыш эшчәнлекне гамәлгә ашыру.........................................................................5

Зиннәтуллин Раиф Кәримулла улы, Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Кол Гали исемендәге халыкара бүләк иясе

Бердәмлектә көч! (Дәрестән тыш эшчәнлекнең бер формасы буларак түгәрәк эше) (башлангыч сыйныф укучылары өчен).........................................................................9

Газизова Алсу Наил кызы, Муктат Флера Ислам кызы, Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 62 нче урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары

«Татар халкы мәдәнияте» дәрестән тыш эшчәнлек программасы (Укучыны рухи-әхлакый яктан үстерү юнәлеше) 5-6 сыйныф укучылары өчен ....................................12

Макарова Ирина Александр кызы, Корманова Айсылу Шәүкәт кызы, Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең югары квалификацион категорияле һәм беренче квалификацион категорияле туган тел укытучылары

"Халкыбызның күңел җәүһәрләре" дәрестән тыш эшчәнлек программасы (гомуммәдәни юнәлеш) 5 нче сыйныф ......................................................................27

Фәхриева Лилия Госмановна, Казан шәһәре Совет районы"108 нче төп гомуми белем мәктәбе"гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

"Татар халкының җырлы – уенлы иҗаты" Дәрестән тыш эшчәнлек программасы (1нче сыйныф өчен) ...........................................................................................34

Бикмөхәмәтова Ләйлә Зөлфәтовна, Казан шәһәре Идел буе районы «6 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Совет районы мәгариф бүлегенең милли мәсьәләләр методисты

«Музей фәннәре мәктәбе» дәрестән тыш эшчәнлек буенча эш программасы (5-9 нчы сыйныфлар).............................................................................................41

Фәттахова Гөлшат Шәйхетдин кызы, Әхмәтгалиева Алсу Әсхадулла кызы, Казан шәһәре Совет районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 171 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе»нең туган тел һәм әдәбият укытучылары

5-9 нчы сыйныфлар өчен гомуми интеллектуаль юнәлеш буенча "Без тарихта эзлебез" дигән дәрестән тыш эшчәнлек эш программасы .........................................................54

Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы, Казан шәһәре Яңа Савин районы 43 нче урта гомуми белем мәктәбенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дәрестән тыш эшчәнлек программасы “Бәллүр каләм” җыены (Укучыны гомуммәдәни яктан үстерү юнәлеше) ....................................................................61
Җәләлиева Ләйсән Равил кызы, Макарова Ирина Александр кызы, Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең югары квалификацион категорияле туган тел укытучылары
“Милли мирас” дәрестән тыш эшчәнлек программасы (1-4 сыйныф укучылары өчен)..........................................................................................................................74
Галиева Гөлназ Шамил кызы, Казан шәһәре Совет районы Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең беренче категорияле укытучысы.
"Туган ягым” дәрестән тыш эшчәнлек программасы ( рухи – әхлакый юнәлеш буенча) (8 нче сыйныф) .............................................................................................96
Тимершина Сания Госман кызы, Хәйдәрова Энҗе Якуб кызы, Казан шәһәре Киров районы 32 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары
“Халык педагогикасы – акыл, рухи сафлык чишмәсе” Рус телендә урта (тулы) белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен туган (татар) телдән дәрестән тыш эшчәнлек программасы (Гомуминтеллектуаль юнәлеш) ..........................................................100
Мөкминова Әлфия Дамир кызы, Казан шәһәре “8 нче гимназия – Мәгариф үзәге” МББУ татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Эчтәлек ..........................................................................................................................114

**Федераль дәүләт белем стандартлары кысаларында**
**дәрестән тыш эшчәнлекне программалар белән тәэмин итү**
**(милли мәгариф).**
**VI кисәк:**
**методик җыентык**

Тираж 200 экз.
Отпечатано в информационно-методическом отделе
Управления образования ИКМО г.Казани
420111, г.Казань, ул.Б.Красная, 1, тел.292-26-12